КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№2 (129)
9 гыйнвар
1998 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык гәзит

Бүгенге санда:

2 *Мәрди РАФИКОВ.* Лагерьдагы кырыс тормыш, ярым ач килеш эшләү һәрнәрсәгә аек карарга өйрәтте.

5 *Рифкат КАЮМОВ.* Азнакайда татарча туалар, татарча тәрбияләнәләр, татарча укыйлар, татарча яшиләр, вакыты җиткәч, татарча җирлиләр дә.

6 *Рашат САФИН.* Милли хәрәкәтнең иҗтимагый оешмалары, көндәлек вак-төяккә бирелеп, реаль тормыштан ерак булган мәсьәләләргә вакыт сарыф итәләр.

8 *Госман ГОМӘР.* Яңалиф мәсьәләсе җиде генә түгел, җитмеш җиде кат үлчәнде ләбаса, ә уңга-сулга сугылуны муеныңа элмәк салу дияргә мөмкин.

Тын кал, дөнья! Сыкранмасын беркем
Тавыш сыный яңа сабыйлар...

Мөхәррир мөнбәре

Элекке Советлар берлегендә яшәгән байтак кына халыклар инде хәзер үзләре „якындагы чит илләргә" әверелде. Димәк ки, „коры җирнең алтыдан бер өлеше"н биләгән хәзерге державада татарлар сан-исәп ягыннан икенче халык булып калды. Шагыйрь әйтмешли, „шул халыкныкмы хокукка хакы юк?.." Әйе, сан ягыннан икенче милләт, әмма „икенче сортлы" түгел! Кызганыч, бәгъзеләребез әлеге тарихи чынбарлыкны танырга ашыкмыйлар. Мондый хәлдә нишләмәк кирәк, безгә, татарларга, үзебезнең хәләл хокукыбызны яңа көч белән дауларга, башны югарырак күтәреп, горур рәвештә XXI гасырга таба атларга гына кала...

Зиннур МАНСУРОВ

Мин әйттем

Еллар кичкән кеше, хатирәләрен барлый-барлый, еш кына яшьлегенә кайта һәм моның белән үзен бик бәхетле саный. Бер көнне Мари урманнарына йомыш белән баручы дусларым сәяхәткә чакырдылар. Белсәгез иде шатлыгымны – азга гына булса да яшьлегемә кайтам ич!

Мари Иленең калын урманнарына безнең Яшел Үзән каласы аша чыктык. Бинииһая хозурлык дөньясына юлыккан сыман тоелды. Ялтырап торган асфальт юл. Ике якта очсыз-кырыйсыз яшел стена. Яшел дәрьядагы атаулар кебек, авыллар күренеп китә. Суслонгерны үтәбез, Йошкар-Ола шәһәре артта кала. Легендага бай һәм диңгездәй Өчъелга күленә таң калабыз. Урман юлы дистәләгән елга һәм сазлыклар аша үтә. Мари Иле һәм Киров өлкәсе арасында чик баганасыдай утырган Килемар бистәсенә җитәбез. Бу районның Кибеево авылында "Якты нур" хуҗалыгына җитәкчелек итүче, безнең Буа төбәге егете ветврач Владимир Малышев белән очрашабыз.Хуҗалыгына чакыра. Бу якларга институттан соң килеп адашып калган. Игене, урман биләмәләре бар. Аюлар белән талашып яшиләр икән. Ул килбәтсез ерткыч сәлам дә биреп тормый, алпан-тилпән атлап килә дә симез үгезне егып китә. Ә сакчылар мылтык тотып карап кала.

Ләкин бу сәяхәт күңелне бастырмады. Ничә йөз чакрым урман юлыннан үтеп, очлары күккә тигән, һәйкәл кеби элеккеге нарат-чыршыларны күреп булмады. Фәкыйрьләнә бугай Мари урманы. Бәлки, яшәртәләрдер? Һәрхәлдә, теге елларда – яшь чакта без күргән карурман юк булган!

Теге дигәнем – 1943 ел. Бер язгы көндә Мөхтәсиб белән икебезне авыл Советына чакырттылар. Бөтен торышы белән үтә кырыс табигатьле комитет рәисе Заһит абый каршысына бастырды да болай диде: "Сез иртәгә Мари урманына утын ташырга китәсез. Үзегезгә, атыгызга азык алыгыз. Арба күчәрләрен кичтән майлап куйсагыз да ярый. Юл ерак, дегет лагуннарына запас алыгыз. Район олаулары белән бергә китәсез". Хозыр-Ильясны эзләргә җибәрәмени, киңәшеп тә тормый. Әйтерсең лә бәдәнле егетләр тапкан, әйтерсең лә мускулларыбыз ташып тора. Уналтысы да тулып җитмәгән үсмерләр генә әле без. Мөхтәсиб авыл малае да саналмый, сугыш башлангач кына кайтты. Ләкин бәхәсләшер заман түгел, дәшмичә генә килештек.

Иртән атларны җигеп, авылның ике үсмере алда ни көтәсен дә белмичә атналык юлга чыктык. Башка авыллардан ат башында "сугыш яшен" узган, әмма дилбегә тотарлык бабайлар иде. Алар көенә барабыз. Юл авыр һәм мәшәкатьле. Татарстанда, шулай ук чуаш, мари авылларында, тилчә кебек авырулардан сакланыптыр, "карантин" игълан иткәннәр. Урамнарга кермичә, авылларны мең азап белән әйләнеп чокырлар һәм инешләр аша үтәбез. Агач ышыкларында, күпер асларында боегып төн кичәргә туры килә. Атларны тышаулап ашатабыз.

Иделне бәләкәй паромда бишенче көндә генә кичтек. Атлар алҗыды. Ә монда юл тагын да авыр. Арба көпчәге коры комга кайчак бүкәненнән бата. Кокшайски, Кокшамары авылларын, Зур һәм Кече Кокшага елгасы үзәннәрен җәфа белән үттек. Без инде караңгы һәм чиксез Мари урманында идек.

Сидельниково авылыннан биш-алты чакрымда яшәргә туктаттылар. Гаҗәп озын наратлар. Кояш нурлары үтеп керми. Аяк астында кыштырдап торган калын ылыс катламы. Яшел үләннең әсәре дә юк. Шунда лагерь корырга боердылар. Һәр авыл үзенә шалаш ясый. Мөхтәсиб белән без дә куыш әмәлләргә керештек. Ул ызба кыегын хәтерләтте. Түбәсен ылыс ботаклары белән ябарга туры килде. Эче иркен, сайгактан сәкеләр һәм өстәл ясадык. Атлар өчен куыш төзү кыенрак иде. Ул бүреләр керә алмаслык булырга тиеш. Утырма читән кебек итеп нарат бүрәнәләреннән эшләдек.

Ике көндә карурманда урамнар барлыкка килде. Апас районыннан 364 баш ат һәм кешеләр лагерьга шулай урнаштылар. Без инде ул чагында Суслонгер лагерендагы хәлләр турында ишетеп белә идек. Ә ул бездән ерак кына түгел. Кайтавазы монда килеп ирешмәсме? Гәрчә, чәнечкеле чыбык белән әйләндерелмәсә дә, сугыш елы лагере ич. Кайнар аш булмавын да белдек. Көнгә ярты кило чамасы икмәк белән канәгатьләнәләр икән. Атларга – 4 кило бурсыган печән. Бөтен паек шул. Ә эше каторжанныкы.

Иртән атларны җигеп диләнкегә китәбез. Гадәти әрдәнәләр юк. 30-35 метрлы наратларны егалар да икешәр метрга турыйлар. Төп буе кубометрдан артык була. Шул кискәне ат арбасына күтәрергә кирәк. Бер авылдан өч-дүрт кеше булганда җиңелрәк, олауларны әртил белән төйиләр. Ә без ике үсмер. Башта бик азаплана идек. Аннары мәлле эшләргә өйрәндек. Үрәчәгә сөзәкләтеп ике сайгак куябыз да кубометрлы утын кискәсен, камыт бавына дилбегә бәйләп, арбага атның үзеннән шудыртып менгезәбез. Мең бәла, мең җәфа белән Идел буена җиткәч, бушатыр өчен арба мендәрендәге кендекне генә уйнатып алабыз: арба арт көпчәген үзе күтәрә, авыр кискә елга ярыннан аска тәгәри. Ул утыннарны солдатлар тотып салга түшиләр. Аларның да эш тыгыз. Йөзләгән атлы олаудан тыш, утынны 15-20 чакрымнан пар атлы вагонеткаларда ташыйлар. Рельс дигәннәре йомры нарат сайгагыннан эшләнгән. Каршыга килүче транспортны үткәрү урыннары бар. Атлы вагонеткалар 5-6 кубометр утын төйи һәм билгеле график буенча йөри. Җилкәдә татып караганга әйтәм, авыр, бик авыр. Әмма ул чакта без – үсмерләрдә дә патриотизм каны бар иде.

Хәзерге заманда кайберәүләр бу сүзне йөз чөереп әйтәләр, кешене мыскыллау, җәберләү сүзе белән басымлап күрсәтмәк булалар. Юк инде, һәр нәрсәне үз исеме белән әйтергә кирәк. Сугыш вакытындагы Казанның хәлен күз алдына китерик. Дөм караңгы (маскировка) шәһәр, фатирлар суык. Тимер мичләргә дә утын таба алмыйлар. Ат җиккәндә булсын, сал төшәүчеләр янында булсын, Казанның хәлен безгә аңлаталар. "Түзегез! Утын, утын!" – дип ялваралар иде. Шул сүзләр канга үтеп керә, юк көчең барлап, казанлыларның хәлен җиңеләйтергә омтыласың. Бу, әлбәттә, кызгану түгел, ул чагында бу – патриотизм үрнәге иде. Бүген дә хәтердә, кар бураннары дулаганда да ылыс түбәле куышларда торып эшләдек, соңгы салны ноябрь ахырларында озаттык, ул Иделдәге кырпак бозны җимереп китте.

Сугыш вакытында без Казанны шулай җылыттык. Туган авылларыбызда сөрелми калган җирләр дә булды, әмма атлар кала өчен утын ташыдылар. Урманда бер без генә түгел идек. Пычкы буйламаслык гасырлык агачларны яшь хатыннар һәм кызлар аудара һәм турый иде. Кайчак бүгенге әбиләр авызыннан: "Әй күрдек инде нужаны, урманда утын турадык", – дигән сүзләрне ишетәсең. Зарлары: "Бүгенгеләр онытты инде безне, яшәрлек пенсия дә бирмиләр", – дип әйткән кебек тоела. Чыннан да, безнең татар хатыннары торф сазлыкларында чиреде, урманнарда җелекләрен суырдылар. Чәерле наратларны екканда пычкы башында беләге дә ныгымаган икешәр кыз бала күрә идең. Йөзләрендә хәсрәт, күзләре яшьле, бөтен кыяфәтләре белән сулган чәчәкне хәтерләтәләр иде. Казан кызлары утынсыз Казанны шулай үз егәрлеге, йөрәк мае белән җылытты. Һич югы аннан соң, һич югы бүген юандырсыннар иде үзләрен. Юк, онытабыз шул.

Юлда төрле уй-фикер килә. Без – малайлар да япь-яшь килеш, фронтка киткәнче, Мари урманнарында ир гомере үттек бугай. Лагерьдагы кырыс тормыш, ярымач килеш эшләү һәр нәрсәгә аек карарга өйрәтте. Шунда гөмбә белән таныштык, ашта ул ит урынына иде. Артыш һәм мүк җиләге, каен мәшкәсе, төрле үләннәр чиләктә кайнап чәйне алыштыра иде. Көлдә пешкән бәрәңге иң татлы ризык булды. Әле аны ничек юнәтәсең? Идел буенда бәрәңге басуларын мылтык белән каравыллыйлар иде ич. Әмма шундый азаплы чакта да малайлыктан арынмадык бугай. Кайнар комлы-көлле учакта көеп пешкән бәрәңгене учта өрә-өрә биетеп суытабыз да ирен ялый-ялый әрчергә керешәбез. Андый чакта учак янына тиеннәр җыела. Дуслашып беттек. Бәрәңге кабыгы белән сыйлыйбыз. Берсен тотып авылга алып кайтасы килә. Тере тиен күрсәтеп, малайларны сөендерәм, янәсе. Хәтта тозак куйган чаклар була. Ә тиен кусаен табынга килсә дә, койрыгын гына күрсәтә. Төнлә лагерь тирәсенә атка ымсынып бүреләр килә. Ә без – җилкенчәкләр аларның улауларын тыңларга җыелабыз. Кайчак, кайсы әйбәтрәк аваз сала дип, бәхәсләшеп тә китәсең әле. Бабайлар бил сызлаудан шалаш сәкесендә аунаганда, үсмерләр шулай үзләренчә ял итә, иртәгәгә көч туплый. Кайчак малайшалай янына, бер сөйләшеп кыен язмышларын җиңеләйтергә диптер, ат башында йөрүче бичара хатыннар да килә...

Ул еллар инде үткән. Мари урманнары буйлап җиңел машинада асфальт юлдан җилдертәм. Урман йөге төягән куәтле машиналар очрый, тимер юллар кичәбез. Ә мин гел як-якка карыйм, малайлыкны искә төшереп ботакта һич югы бер тиен күренмәсме, дим. Башка истәлек юк. Ул чагындагы кыргый урманнарда интеккән кешеләргә орден-медальләр өләшмәделәр, хезмәт хакы да түләмәделәр ич. Планны арттырып үтәүчегә бүләк итеп киндер битле агач башмак, йә берәр метр ситсы бирәләр иде. Алары тузган. Күңелләрдә ул елларның рухи газабы булып иңрәү генә калган. Колакта гел бер шау: "Казан, диләр, туңа". Көртле юлда көпчәкләр әйләнмәс булса да, утын төяп урманнан чыгабыз – үзең карлы шалашта өшесәң дә, каланы җылытырга кирәк. Көзге салкын дулкыннар чәчрәп, сал төшәүче солдатларны баштан коендыра – соңгы чиккә җитеп эшлиләр, чөнки фәрман бирелгән: "Казан, диләр, туңа..."

Бу хакта сөйләвемнең максаты изге. Мари урманнарында интеккән көчле кешеләрне искә төшерәм, аларга соклануым да, хезмәтләре белән горурлануым да арта. Байтагы бу якты дөньяда юк инде, хөрмәт, рәхмәт хисләрен белдерү беркайчан да соң һәм артык түгел. Ачлы-туклы эшләп кала куышын җылытучы авыл кешеләрен бүгенге казанлылар яшь буын өчен күңелләрендә яңартсыннар һәм рәхмәт иңдерсеннәр иде. Бу гыйбрәт өчен кирәк.

Мәрди РАФИКОВ

Без Казанны шулай җылыттык

ВАКЫЙГАЛАР
ХӘБӘРЛӘР
ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

1998 елның койрыклы саннары

Узган ел хәлләрен онытып бетермәгәнсездер әле. Русия хөкүмәте өч нульне сызып, халыкка яңа акча тәкъдим иткәч, ил җитәкчеләре ант кылып диярлек: "Валлаһи, бәяләр күтәрелми", – дип, вәгъдә иткәннәр иде.

Иншалла, 1998 елга аяк бастык. Аның бер атнасы үтеп тә китте. Халыкның Яңа ел каршыларга дип хәзерләгән азык-төлек запасы кимеде яки бетте һәм, ниһаять, ул сагаеп кына кибеткә юл алды. Һәм, ни гаҗәп, икмәк, сөт һәм башка азык-төлек бәяләренә эреле-ваклы саннар өстәлгән булып чыкты. Иске акча белән зур да түгел кебек, 1-2 мең, 500 сум. Унар меңгә үк күтәрергә җөрьәт итмәгәннәрдер инде. Ә болай күзгә әлләни ташланмый. Аннары бәйрәмнәрдән айнып бетмәгән халыкны язып алдадың ни дә, язмый гына аның кесәсенә кереп чыктың ни – барыбер ич. Хәзер шундый саннар язып куелган. Мәсәлән, 24445 сум, 2357сум... Шәп уйланылган. Мондый башваткычлар бары тик Русия мәмләкәтендә генә була ала торгандыр. Яңа акчалар әйләнешкә кермәгән, ә иске акчаларның андый берлекләре дә, унлыклары да күптән юк. Сәүдә өчен бик әйбәт нәрсә бу. Ләкин ул синең белән минем файдага гына түгел.

Яңа ел алдыннан гына телефоны булган татарстанлыларга бәйрәм "күчтәнәче" ясалган, түләү бәяләренең артачагы хәбәр ителгән иде. Фатирларны хосусыйлаштыруда да алга сикереш ясалды. Бәяләр өлкәсендә, дим. Хәзер фатирны хосусыйлаштырасың икән, аны рәсмиләштерү өчен эш хакының 75 процентын түлисең.

Ел башланды гына әле, ә халык өчен кылынган "изгелек" инде күз алдында. Юлбарыс елы да халыкның кесәсен каезлаудан, кимерүдән башланып китте бит әле. Ул юлбарыс дигәннәре дә хәерсез нәмәстә, күрәмсең.

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

Әйткән сүз – аткан ук

Разил ВӘЛИЕВ, шагыйрь, Республика Милли китапханәсе директоры, Татарстанның халык депутаты:

"Күптән түгел Казанга бер авылдашым килгән иде. Хәл сораша башлагач, ул, мактанып: "Әле менә авылда хан сарае шикелле сыер абзары салып куйдык", – диде. "Без дә тиздән Милли китапханәгә яңа бина сала башлаячакбыз", – дип әйтеп куйдым мин. "Булмас, юк белән хыялланма, заманалар авыр", – диде бу. "Нишләп булмасын, – мин әйтәм, – китапханә төзү турында хөкүмәтнең биш карары, Югары Советның бер карары чыкты. Әнә, үзең әйтәсең бит, сез хан сарае шикелле абзар төзегәнсез, заманалар авыр дип тормагансыз". "Сыерларга төзерләр, – диде авылдашым, – чөнки алар сөт бирә. Ә китапханә төземәячәкләр, чөнки сезнең китап, гәзит-журнал укучыларыгыздан сөт тә, ит тә, йон да юк. Сыерлар укый белсә, аларга инде күптән китапханә төзегән булырлар иде..."

Мәскәү татарларына – "Һилал" бүләге

Яңа ел бәйрәме көннәрендә Мәскәүдәге "Һилал" татар рухи мирасын үстерү хәйрия фондының яңа концерт залын ачу тантанасы үткәрелде.

Концерт залы 350 урынлы. Ул һәртөрле милли тамашаны бушлай үткәрү өчен, дип җиткезелгән. Моңа чаклы мондый чараларны үткәрү максатыннан арендаланган биналар өчен шактый акча тотыла иде.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә "Время и деньги" гәзитенең фән һәм мәгариф бүлеге мөхәррире **СИДОРОВА Татьяна Васильевнага "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Озак еллар нәтиҗәле фәнни эшчәнлек алып барган өчен Алабуга дәүләт педагогика институтының фәнни эш буенча проректоры **ВӘЛИЕВ Наил Мансур улына,** Казан дәүләт университетының функцияләр һәм якынлаштырмалар теориясе кафедрасы мөдире **ГАБДЕЛХӘЕВ Вилсур Габделхәй улына "Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе"** дигән мактаулы исем бирелде.

Мәдәниятне яратучылар бәйгесе

Бер ел элек "Литературная Россия" гәзите редакциясе Русия Федерациясе республикалары, өлкәләре һәм шәһәрләре хакимнәре, предприятие җитәкчеләре, финансистлар арасында "Мәдәнияткә һәм әдәбиятка ярдәм иткән өчен" дигән исем астында конкурс игълан иткән иде. Күптән түгел әлеге бәйгенең комиссиясе 1997 ел буенча йомгак ясады. Җиңүчеләр арасында Башкортстан Президенты Мортаза Гобәйдулла улы Рәхимов та бар. Бу мәртәбәгә ул Бөтенрусия Аксаков бүләген булдырганы, республикада Аксаковлар гаиләсе традицияләрен үстергәне, "Башкортстан" энциклопедиясен әзерләүдә һәм бастырып чыгаруда актив булышлык күрсәткәне өчен лаек булды.

Чаллының танылган кешеләре

Чаллы каласы үзенең 1997 елгы лауреатларын билгеләп узды. Ул ике юнәлештә үткәрелде – иң яхшы һөнәр остасы һәм иң яхшы җитәкче. Әлеге танылган кешеләргә бүләкләр тапшырылды, ә вице-мэр Й.Якубовка "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" орден-медале тапшырылды.

Ятимнәр өчен автобус

Мамадыш балалар йортына килгән кунаклар бу көннәрдә юмарт булдылар. Мәсәлән, эш һәм мәшгульлек буенча дәүләт комитеты рәисе Б.Захаров балалар йортына "Даймлер Бенц" автобусы бүләк итте.

Русия фильмнары карарбыз

Татарстан Кинематография дәүләт комитеты Мәскәүнең "НТВ-Профит", "Конус-фильм", "Викинг-фильм" кебек студияләре белән килешүләр төзеп, 1998 елда Татарстан тамашачысын Русия осталары тарафыннан эшләнгән яхшы фильмнар белән сөендерергә җыена.

Иман йортында үзгәрешләр көтелә

Санкт-Петербург каласындагы мәдәни мирасны саклау мәсьәләләре буенча гыйльми совет Җәмигъ мәчетенең ишегалдын реконструкцияләүнең эскиз проектын хуплады. Эшнең кыенлыгы шунда ки, XX гасыр башындагы мөселман дөньясының истәлекле һәм кабатланмас һәйкәлендәге үзгәртүләр аңа зыян китермәслек итеп башкарылырга тиеш. Иман йортының мәйданын киңәйтү һәм мәдрәсә өчен иркен заллар, шулай ук монда килгән кунакларны кабул итү өчен ишегалдында бер һәм ике катлы биналар җиткезү күздә тотыла.

Һәр җәмгыятьнең "Ока"сы бар

Чаллы шәһәрендә 20 милли җәмгыятьнең "Изге тугандашлык – иң зур байлык" дигән кичәсе узды. Анда Татарстан Президенты М.Шәймиевнең котлау телеграммасы укылды һәм һәр милли җәмгыятькә "Ока" автомобильләре ачкычы тапшырылды.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Федерация Советы Рәисе урынбасары В.Лихачев җитәкчелегендәге рәсми делегация Сыктывкарда Ю.Спиридоновның Коми Республикасы Президенты вазифасына керешү тантанасында катнашты.

1997 елның соңгы эш көнендә Президент М.Шәймиев Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге еллык Дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Халыкара гроссмейстер А.Галләмова Гронингенда үткәрелгән турнирда беренче урынны яулады, ә Казанда аңа ике бүлмәле фатир бирелде.

АКШның Джорджия штаты университетында сынау-күнегү узучы доцент А.Салагаев Казан технология университеты китапханәсе фондына Америкада басылган ике йөздән артык кыйммәтле, сирәк очрый торган китаплар бүләк итте.

Татарстан Дәүләт Советында республика шәһәрләреннән һәм авылларыннан килгән йөздән артык бала өчен Чыршы бәйрәме узды.

Түбән Кама шәһәрендә республикада беренчеләрдән булып Германия фирмасы "Фольксваген"ның автосалоны ачылды.

Татарстанның алтын фондына беренче тапкыр 49 килограмм авырлыктагы кисәкләп коелган алтын керде.

Чаллы шәһәренең "Энергетик" мәдәният сараенда "Алтын йөрәкле кеше" дип исемләнгән бәйгегә йомгак ясалды һәм аңа 7 кеше лаек булды.

Циркта, курчак театрында, А.Алиш исемендәге балалар иҗат үзәгендә инвалид балалар өчен бәйрәм кичәләре узды.

Мәскәүдә үткәрелгән XXXIII халыкара кино-телевидео базардан Татарстан киночылары нәфис фильмнар прокатлауга килешүләр төзеп кайтты.

Хәрабә хәлендәге торакларны бетерү өчен максатчан салым 1998 елның 1 гыйнварыннан 1 процент күләмендә салына.

Иң яхшы хакимнәр

Казан шәһәре мэры Камил Исхаков "Республиканың яхшы мэры" дигән мактаулы исемгә лаек булды. Шулай ук Казанның Совет районы, Теләче, Балык Бистәсе, Питрәч районнары хакимият башлыкларына да "Яхшы хакимият башлыгы" дигән исем бирелде.

...Иң яхшы спортчылар

Узган елда ирешелгән нәтиҗәләр буенча халыкара класслы спорт мастеры Денис Капустин, Түбән Камадан Италиядә Бөтендөнья универсиадасында җиңгән, елның иң яхшы спортчысы призына лаек булган Ирина Вострикова, халыкара гроссмейстер Алисә Галләмова, спорт мастеры Диана Чиняева Татарстанның иң яхшы спортчылары дип табылды.

Хөрмәтле укучылар!

"Мәдәни җомга"га язылырга өлгермәгән туганнарыгызга, күршеләрегезгә, танышларыгызга әйтсәгез икән: әгәр 15 гыйнварга кадәр почта бүлекләренә барып рәсмиләштерсәләр, аларга гәзитебез 1 февральдән килә башлар.

Биш айга язылу бәясе – 22 сум 50 тиен.

Сәхифәбездә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **В.МАРТИНКОВ** фотосы.

Җавап-савап

Мирас кемгә кала?

Бердәнбер улыма хосусыйлаштырылган фатирны васыять итеп йә бүләк (дарственный) рәвешендә калдыру артык мәшәкать кенә түгелме? Үземнән соң фатир болай да улыма мирас булып күчәргә тиеш бугай ич инде?

З.ГЫЙМАДИЕВА.
Казан.

РСФСРның гражданнар кодексы буенча мирас закон һәм васыять буларак рәсмиләштерелә. Закон буенча мирас васыять буенча үзгәреш кертелгән чакта (527 нче маддә) законлаштырыла. 532 нче маддә буенча, закон мирас тиешле кешеләр итеп түбәндәгеләрне таный: беренче чиратта балалар (уллыкка алган балага да тигез өлеш), никахлы ир һәм әти-әниләре (уллыкка алган бала үлсә, аның әти-әнисе), шулай ук үзе туганчы әтисе үлгән (әтисе үлгәч туган) бала тигез өлештә мирас алырга хокуклы. Югарыда саналган кешеләрдән соң, башка туганнары булмаган очракта, мирас турыдан-туры закон буенча беренче чираттагы варисларга кала. Сезнең очракта улыгыз мираска хокуклы.

* * *

Заводта эшләгәндә күзләрем кислота чәчрәп янды. Завод миңа килгән зыянны капларга тиешме?

К.ЗӘЙНЕТДИНОВ.
Менделеев шәһәре.

Хезмәткәр эш вакытында зыянга тарыса, гариплэнсә яки һөнәр китергән авырудан җәфаланса, РФ гражданнар кодексы һәм эш вакытында травма яки һөнәр авыруын каплату кагыйдәләре нигезендә сезнең мондый хокукларыгыз бар: а) әхлакый яктан рәнҗетелүне матди каплату, б) бер мәртәбә ярдәм акчасы алу, в) эшләү мөмкинлеген югалту дәрәҗәсе күләмендә акча алу һәм шулай ук өстәмә чыгымнар өчен акча түләтү. Тулырак мәгълүмат алу өчен "ОКО" юридик агентлыгына мөрәҗәгать итә аласыз.

* * *

Мин бер бүлмәле кооператив фатирда яшим. Минем янга кызым һәм оныгым теркәлгән, ләкин алар башка фатирда яшиләр. Оныгым һәм кызым өчен коммуналь хезмәтләргә ЖКУга акча түләргә тиешменме?

Р.БИЛАЛЕТДИНОВ.
Казан.

Торак йортта яшәгән өчен түләү кертү турындагы вакытлы положениенең 3 нче пунктына нигезләнеп, даими яшәү урыныннан китү очрагында (бер айдан артык срокка) коммуналь хезмәт өчен (җылыту һәм торак йортны наемга алган өчен түләүдән кала), лифттән файдаланган, көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен, фатир хуҗасыннан гариза кергән очракта, акча түләнми.

* * *

Апамның ире (җизни), үзенең өч ир туганын, мирастан мәхрүм итеп, фатирын башка кешегә васыять итте. Бу мөмкинме һәм аны ничек рәсмиләштерергә?

И.БАЙТИРӘКОВ.
Яшел Үзән.

Сораудан фатирның кем исеменә васыять ителгәне билгесез калды. Әгәр васыять сезнең исемгә язылса һәм васыятьтә сездән башка кеше исеме күрсәтелмәсә, җизнәгезнең туганнары мираска ия түгел. РФ гражданнар кодексының 532 нче маддәсе нигезендә җизнәгезнең ир туганнары мираска икенче чиратта гына ия. Мирас булгәндә беренче чиратта балалар, ир белән хатын, ата-ана иссә алына.

("ОКО" юридик агентлыгы).

К о т л ы й б ы з !



Татарстанның һәм СССРның халык рәссамы, Татарстан, РФ һәм СССР Дәүләт бүләкләре иясе **Харис Якуповка** Мәскәүдән куанычлы телеграмма килде. Анда мондый юллар бар:

"Яңа 1998 ел алдыннан Сәнгать академиясе җыены Сезне, Русия сынлы сәнгате һәм мәдәниятенең күренекле эшлеклесен, Русия Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлады. Президиум һәм шәхсән үз исемемнән Сезне әлеге шатлыклы вакыйга уңаеннан кайнар тәбриклим, ныклы сәламәтлек, тормышыгызда җитешлек, Русиянең чәчәк атуы өчен яңа иҗат казанышларына ирешүгезне телим. Яңа 1998 ел белән!

Президент Зураб Церетели".

"Мәдәни җомга" гәзите редакциясе Идел буе һәм Урал ягы төбәгендә сәнгатьнең шушы төре буенча әлегә бердәнбер булган академик Харис Габдрахман улы Якуповны үз укучылары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре исеменнән ихлас котлый, татар халкын дөнья алдында данлау хакына яңадан-яңа иҗат уңышлары тели.

Әй-һәй!..

Җәнҗал пәрдәсе артында

Татарстан прокуратурасында, югары урын биләүче бер чиновникның әйтүенчә, республикадагы хакимият органнары хокук саклау органнарыннан "КамАЗ" акционерлык җәмгыятендәге урлашу фактлары буенча киң масштаблы тикшерү эшләре көтәләр. Җирле матбугат чаралары хәбәр иткән, КамАЗда урта һәм югары власть эшелоннарында массакүләм кулга алынулар башланды, дигән сүзләр исә җәмәгатьчелек фикерене юнәлеш бирү өчен ясалма рәвештә оештырылган нәрсә генә, дип тә өсти ул. Мондый уйдырмалар асылда Татарстан хөкүмәтенең КамАЗдагы хәлне уңай якка үзгәртергә сәләтле булмавын җәмәгатьчелек алдында акларга тырышу гына. Президент Шәймиев КамАЗны банкротлыктан йолып алганнан һәм директорлар Советы республиканың беренче вице-премьеры Равил Моратов җитәкли башлаганнан соң КамАЗ финанс тупигына килеп керде. Конвейердан төшкән һәр автомобиль заводка 20–30 миллион сум зыян китерә. Фәннәр докторлыгына диссертация яклаган һәм халыкара үрнәктәге диплом иясе булган Равил Моратов КамАЗда төзелгән заводлар комплексын бары тик банкротлык кына коткара ала, дип исәпли. Ләкин мондый караш та автогигантның җитәкчелеге өстеннән компетентсыз дигән гаепне төшерә алмый. Менә шуңа күрә дә, күзгә төтен җибәрү өчен, заводтагы зур җинаятьләр, эре урлашу фактлары турындагы хәбәрләр куертыла. Шуңа күрә КамАЗ директорлар Советының яңа рәисе завод җитәкчелеге белән киңәшеп тә тормыйча, суд тикшерүчеләрен чакырды. КамАЗда республика прокуратурасы, МВД һәм КГБның берләштерелгән суд тикшеренүе төркеме эшли башлады. Бу төркем акционерлык җәмгыятенең эшен 1995 елдан башлап тикшерә, дип хәбәр итүе белән,"Время и деньги" гәзите КамАЗ трагикомедиясенең режиссерын фаш итте.

Чаллыда кузгатылган җинаять эшләре үткән елгылардан бер дә артык түгел, югыйсә. Билгеле фамилияләр тиресендәге шау-шулы суд эшләре дә әлегәчә күренми. Мәсәлән, КамАЗның элекке генераль директоры Николай Бехның коттеджы бар. Ул аны хосусыйлаштырды да, "КамАЗ" акционерлык җәмгыятенә 2 миллиардка сатып та җибәрде. Ләкин моннан перспективалы җинаять эше оештырып булмый, барысы да законга туры китереп эшләнгән. Тагын бер мисал: бүгенге КамАЗ директорлар советы рәисе Равил Моратовның коттеджы (өстәвенә, ул ике эшне бергә алып бара) 3 миллиард тора, ләкин беркем дә моннан шау-шулы җинаять эше кузгатырга җыенмый. Әлегә кадәр.

Бүгенгә завод җитәкчеләренең әле нибары берсе генә – "КамАЗ" акционерлык җәмгыятенең хисап-финанс үзәге директоры Юрий Авдеев кына кулга алынган. Аны 1997 елның февраленнән апреленәчә 3 миллиард сумлык "КамАЗ" автомобильләрен мошенникларча урлауда гаепләр, дәрәсәргә, шикләнәләр. Шулай ук суд тикшерүе тарафыннан әлегә кем булуы ачыкланмаган һәм В.И.Моратов исеменә ясалган ялган паспорт белән 78 миллион сум акча урланганы да мәгълүм. Бу ачыкланмаган кешене тикшерүчеләр ачыкладылар, һәм ул кулга алынды. Бу кеше – 1958 елда туган самаралы Сергей Амосов булып чыкты. Чаллыдан да бер кеше кулга алынды – 57 яшьлек Владимир Спирин. Ул хәйлә һәм алдау юлы белән микролитражлы двигательләр заводыннан 12 ВАЗ – 1111 машинасы алып чыккан. Ләкин КамАЗга аның бер катнашы да юк.

"Время и деньги" гәзитенең язуына караганда, Татарстан бу җинаятьләрне фарс-мажорга чыгарып, чуттан төшерү ягында түгел, ул конкрет гаепле кешеләрне ачыкларга тели. Моңа дәлил булып урта һәм югары җитәкчелек эшелоннарында башланып киткән кулга алулар тора.

Ул арада җирле хокук саклау органнарының эшчәнлеген координацияләүче Татарстан прокуратурасында, җирле хакимият даирәләре никадәр тырышмасыннар, шау-шулы җинаять эшләре кузгатылмаячак, дип катгый рәвештә белдерәләр.

("Независимая газета")

РЕФОРМАЛАР

безгә нәрсә бирде

- Илдә продукция җитештерү яртылаш кимеде.
- Җиңел һәм текстиль промышленностенда җитештерү 10 процентка калды.
- Хәрби промышленность комплексында җитештерү 94 процентка кимеде.
- 125 мең предприятиене нибары җидешәр миллионга саттылар (Бәяләр – 1997 елныкы).
- Русиянең "тышкы" бурычы 150 миллион доллар тәшкил итә.
- Мәгариф һәм фәнгә бюджеттан 2 миллиард доллар бирелсә, АКШта бу сан 170 миллиард доллар тәшкил итә.
- 31 миллион кеше хәерчелектә, тормыш төбендә яши.
- 15 миллион кешенең айлык кереме яшәү минимумыннан 2 тапкырга кимрәк.
- Өч елга 3 миллионнан ким бала туды, ел саен Курски өлкәсендә яшәгән кадәр кеше үлә.
- Илдә 4 миллион урам баласы яши.
- Картлык пенсияләре 2-3 тапкырга кимеде.
- Таланган вкладчылар саны 80 миллионнан артты.

("СР").

Иске һәм яңа акчалар

1998 елның 1 гыйнварыннан әйләнештә иске һәм яңа акчалар йөри. Сезгә җайлы булсын өчен иске акчаларның яңача ничек бәяләнүен исегезгә төшерәбез.

СУМНАРДАН	ТИЕН ҖЫЕЛА
1 сум – 0,1 тиен	
5 сум – 0,5 тиен	
10 сум – 1 тиен	
20 сум – 2 тиен	
50 сум – 5 тиен	
100 сум – 10 тиен	
500 сум – 50 тиен	
1 мең сум – 1 сум	
5 мең сум – 5 сум	
10 мең сум – 10 сум	
50 мең сум – 50 сум	
100 мең сум – 100 сум	
500 мең сум – 500 сум	

Азнакайда академиклар гына яши

Азнакайда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының күчмә утыры-

шы булып узды. Ул бик тә үзенчәлекле һәм гаять дәрәҗәдә әһәмиятле мәсьәләгә – татар авылларының милли йөзен саклап калу мәсьәләсенә багышланган иде.

Илдар Юзеевның бер мәгълүм шигыре искә төшә. Ул анда, хәтерем ялгышмаса, "татарча тугабыз, урысча укыйбыз, урысча тәрбияләнәбез, урысча эчәбез, урысча яратабыз, урысча сүгенәбез, татарча үлебез", дигән фикер үткәргән иде. Шагыйрь бик дөрес тотып алган бит, җәмәгать, татарның яшәешен. Татар анасыннан туган балаларыбыз урыс мәктәпләрендә ялган тарих укып тәрбияләнмиләрме? Дуңгыз урынына эчмиме татар? Башка милләт кызларына өйләнеп, бөтен дөньясыннан канәгать булып ятмыймыни татарыбыз? Болар барысы да, кызганычка, татарның яшәү рәвешенә әверелеп бара. Әйтелгән сүзләр статистика мәгълүматлары белән дә беркетелгән. Шулай итеп гасырлардан килгән асыл гореф-гадәтләребезгә, йолаларыбызга таянудан бигрәк, читләр арбасына утырып баруны хуп күрәбез. Дөрес, бу сүзләр халкыбызның күпчелегенә кагылмый, фәкать бер өлешенә һәм, әйтергә кирәк, шулай да саллы өлешенә кагыла. Ягъни мәсәлән, без, урысның үзе әйтмешли, "поезд ушел" чорына ук килеп җитмәгәнбез әле. Әлегә вакыт та, форсат та бар.

Күчмә утырышның нәкъ менә Азнакай районында узуы да юкка түгел. Гомер бакый, кояш үзенең шифалы нурларын иң беренче булып Азнакайга тарата. Шуңа күрә Азнакай халкы иртәрәк уяна, иртәрәк җиң сызганып эшкә керешә. Нәтиҗәләре дә күз алдында: үткән ел искиткеч зур уңыш үстереп, Азнакай районы янә Татарстан, Русия халкын шаккатырды.

Юк, хезмәт белән генә түгел, ә бәлки рухи яңарышның башында торуы белән дә мактаулы Азнакай ягы. Димәк, рухи кояш та Азнакайда иртәрәк чыга. Монда татарча туалар, татарча тәрбияләнәләр, татарча укыйлар, татарча яшиләр, вакыты җиткәч, татарча җирлиләр дә. Менә шушы милли яшәешне үз күзләребез белән күрер өчен тирә-юньдәге тугыз районнан җыелган идек без.

Район хакимияте башлыгы, Татарстанның халык депутаты Әнәс Исхаков барыбызны да автобуска утыртып авылларга алып китте. Ярты районны урап чыктык – Кәкре Елга, Илбәк, Урсай, Сарлы, Сөендек, Югары Әстәрле, Уразай авылларында булдык. Һәр авылда диярлек татар мәктәбе, мәчет, мәдәният йорты, профилакторий, кибетләр эшләп тора. Кәкре Елгада хәтта базар да бар. Кәкре Елга, димәктән, монда искиткеч матур милли архитектура нигезендә мәдрәсә-мәчет комплексы төзелеп килә. Бу авылның һөнәрчеләре дә осталарның остасы икән. Согуд Гарәбстаны, Төркия келәмнәре бер кырыйда торсын – Кәкре Елга уңганнары келәмнәре күз явыңны алырлык. Балага исем кушу, никах, туй, әрвахларны искә алу, вафат булганнарны күмү йолаларын җиренә җиткереп уздыралар. Җирле радиодан атнага ике мәртәбә "Мәхәллә" тапшыруын оештырганнар. Авыл музеен да дөньяга күрсәтерлек йөзгә кызыллык китермәслек итеп төзегәннәр.

Аннан соң Илбәк авылында булдык. Ун ел элек 49 морҗасыннан төтен чыккан бу авыл бетүгә йөз тоткан булган. Хәзер биредә 132 хуҗалык көн күрә. Нигездә алар – БДБ илләреннән кайткан качаклар – биредәге агрофирмада эшлиләр. Әмма Илбәк үзенең предприятиясе белән генә түгел, мәктәбе белән дә данлыклы икән. Кайчандыр, 2 баладан оешкан бу мәктәптә бүгенге көндә 62 укучы белем ала, 20 бала бакчада тәрбияләнә. Шунысы да күңелгә хуш килде – эшләп үсәләр мондагы балалар. Былтыр, мәсәлән, 130 миллион сумлык яшелчә, җиләк-җимеш үстереп сатканнар.

Илбәк мәктәбендә алты милләт баласы белем алса да, уку-укыту нигездә татарча оештырылган. Берәр авылда, әйтик, 100 баланың 5-6сы башка милләттән булса, уку, әлбәттә инде, урысча алып барыла иде. Монда, киресенчә, барысы да тырышып татарчасын да, урысчасын да, инглиз телен дә үзләштерәләр. Әнә, 3 нче сыйныф укучысы Роза Асатрянның әтисе әрмән, әнисе удмурт, ә үзе татар телен су урынына эчә, алай гына түгел, бернинди акцентсыз сөйләшә. Әрмәнчә, удмуртча, инглизчә сөйләп, шигырьләр укып Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзаларын, кунакларны шаккатырды ул. Аның сеңлесе, 2 нче сыйныфта укучы Синьоритта Асатрян да татарчаны камил белә.

Исеме җырларга кергән Урсай авылы Башкортстанның Бакалы һәм безнең Мөслим районнары чигендә, ямьле Ык буенда урнашкан. Монда да татарның бөтен гореф-гадәтләренә туры китереп яши бирәләр. Шулай да бераз үзенчәлеген дә сиздек. Монда татар халкына хас булганча, җир белән хуҗаларча эш итәләр. Соңгы биш елда һәр гектардан 50 центнердан ким уңыш алганнары юк икән. Ә узган елда бер гектардан 71 центнер икмәк алганнар! Терлек санын киметмәгәннәр. Басуларның җәгәрлеге дә җитәрлек икән. Боларны безгә Урсай авылы үзидарә Советы рәисе Шәүкәт Ихсанов сөйләде.

Аннары тагын бер үзенчәлеккә игътибар иттек: мондагы музей да башкалардан аеруча "татарча" төзелүе белән аерылып тора. Күпчелек музейлар Бөек Ватан сугышы, колхозның уңышлары, бишьеллык батырлары, съезд делегатлары һәм башка вакыйгалар белән кирәгеннән тыш мавыкса, Урсайда ата-бабаларыбызның борынгы тарихына, шәҗәрәләргә, кабер ташларына, гореф-гадәтенә күбрәк әһәмият биргәннәр. Кунаклар арасында кызыксынып йөргән Азнакай егете, хәзер Чаллыда яшәүче, барыбызга да мәгълүм эшмәкәр Рафис Кашапов:

– Менә бу чын татар халкы музее ичмасам, – дип бәяләде.

Гомумән, музейлар дигәннән, районда аларга игътибар зурдан икән. Бу турыда Әнәс Исхаков менә нәрсәләр сөйләде:

– 1990 елда ук район авыллары тарихын язу буенча программа төзедек. Барлык һәвәскәр тарихчыларны, укытучыларны, аксакалларны җыеп киңәш-табыш иттек. Бүгенге көндә 7 музей эшли, тиздән район үзәгендә дә музей ачылачак. Халкыбыз гореф-гадәтләренә, йолаларына таянып яшьләрне үстерү, тәрбияләү өчен кирәк ул музейлар.

Иң соңыннан без Уразай авылында булдык. Башкарма комитетның утырышы мәдәният йортында авыл халкы белән берлектә узды. Хәер, утырыш турында сөйләгәнче, Чатыр тау итәгендә урнашкан авылның үзе турында әйтү кирәктер. Монда 756 кеше яши икән. Мәчетле, урта мәктәпле авыл. Балалар бакчасында 65 сабый тәрбияләнә. Ренат Мөхәммәдьяров җитәкләгән күмәк предприятие һәр гектардан 58,3 центнер икмәк җыеп алган; чөгендер, бәрәңге уңышы да муллан чыккан; һәр сыердан 4740 килограмм сөт сауганнар. Күрәсез, уразайлылар эшли беләләр. Афәрин.

Менә шулай итеп район авыллары белән танышып, халык белән сөйләшеп, милли яшәешне үз күзләре белән күреп йөргән башкарма комитет әгъзаларына утырышны уздыру әллəни авыр булмады. Башкарма комитет әгъзалары һәм кунаклар, димәктән, аларны

атап китү дә урынлы булыр. Болар – академиклар Индус һәм Энгель Таһировлар, профессор Вәгыйз Фәтхуллин, язучылар Туфан Миңнуллин, Марсель Галиев, Разил Вәлиев, Рәшит Ягъфәров, Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Рәзим Вәлиуллин, халык депутаты Фәндәс Сафиуллин, эшмәкәр Рафис Кашапов һәм башкарма комитет секретаре Мәҗип Низамиев. Авылларда күргән-белгәннәр башка районнардан килгән хакимият башлыклары урынбасарларына, мәдәният, мәгариф бүлекләре хезмәткәрләренә, Бөтендөнья татар конгрессының район һәм шәһәр филиаллары җитәкчеләренә дә гаять дәрәҗәдә файдалы булды дип саныйм.

Утырышны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, академик Индус Таһиров алып барды. Анда шактый саллы, кызыклы һәм тәнкыйди фикерләр әйтелде. Төзелеш-архитектура академиясе деканы, профессор Вәгыйз Фәтхуллинны тыңлап карыйк:

– Ата-ана телеге белән дигән булып, Казан һәм башка шәһәр-районнардагы мәктәпләрдә, гимназияләрдә физика-математика фәннәрен урысча укытырга тырышалар. Янәсе, татарча укысалар, терминнарны белмиләр дә институтларга керә алмыйлар. Тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам: бу – ялгыш фикер. Балалар болай эшләгәндә надан калалар. Барлык югары уку йортларында диярлек татар төркемнәре оешты, китап-әсбаплар да чыкты, яңалары төзелә.

Разил Вәлиев тә татарча яшәешкә кагылышлы җитди фикерләр әйтте:

– Татарстанда 800ләп мәчет төзелде, дип мактанабыз, әмма алар күп очракта мунча кебек кенә төзелә. Иман йортларын авыл-шәһәрләребезнең күрке булырдай сәнгать әсәрләренә тиң итеп төзергә кирәк. Аларның 30-40 елга түгел, гасырлар өчен төзеләсен истән чыгармаска иде. Татар авылларында татар китабына, зиратларга игътибарны нык арттырасы бар.

Рәшит Ягъфәровның менә бу фикерләре белән дә ничек килешмәскә мөмкин:

– Милли архитектура буенча совет оештырырга иде. Югыйсә, мәктәпләр, клублар, мәдәният йортлары, балалар бакчалары проектлары Мәскәүдә төзелә. Ул проектта бернинди милли үзенчәлек, колорит юк. Азнакай авылларындагы кебек аксакаллар шурасы, туган як музейлары төзергә кирәк. Аннан соң милли гореф-гадәтләребезне, йолаларны мәдәният йорты сәхнәләреннән тормышка, яшәешкә-көнкүрешкә кертергә иде. Рухи мирасыбызны, диалекталь телне, милли мәгарифне торгызырга кирәк. Яшьләребездә милләтпәрвәрлек хисен тәрбияләү – олуг бурычыбыз.

Башкарма комитет Азнакай районы һәм шәһәр тәҗрибәсен татар халкы яшәгән төбәкләргә, башка районнарга да таратырга кирәк дигән резолюция кабул итте.

Утырыш ахырында Азнакай районы Русия Гуманитар академиясенә коллектив әгъза итеп, ә Әнәс Исхаков әгъза-мөхбир-академик итеп сайланды. Әгәр дә Азнакай районы хакимияте башлыгына "Академик" дигән кушамат тагылса, бер дә гаҗәпләнмәгез. Чыны да шулай: Азнакайның халкы да, аның хакиме дә академиклар. Үз эшләренең академиклары...

Рифат КАЮМОВ,
Бөтендөнья татар конгрессының Лениногорски филиалы рәисе, "Заман сулышы" гәзите мөхәррире.

● ***Утырыштан бер күренеш. Сулдан уңга – Ф.Сафиуллин, И.Таһиров, Ә.Исхаков.***

● ***Апалы-сеңелле Роза һәм Синьоритта Асатряннар.***

Автор фотосурәтләре.

Менә 1997 ел да тарихка теркәлде. Татарстан Хөкүмәте карары белән ул җөмһүриятебездә Мөхәммәдъяр елы дип игълан ителгән иде. Шагыйрьнең 500 еллык юбилее II Бөтендөнья татар конгрессы кысаларында уздырылуы һәм милләтебез язмышына кагылышлы башка вакыйгалар бу елны бөтен татар дөньясы өчен дә Мөхәммәдъяр елына әверелдерде дияргә була. Бу сүзләрне дәлилләү өчен Мөхәммәдъярның шигъри таланты гына түгел, аның безгә искиткеч зур әһәмияткә ия булган дәүләти мирас калдырган шәхес булуын һәм бу мирасның бүгенге актуальлеген искәртү дә җитәрдер. Берәү дә каршы килмәс дип уйлыйм, моның өчен нигез җитәрлек тә, иҗтимагый, сәяси вә мәдәни эшләтә алмавыбыз чираттагы чигенү булды. Бер генә мисал. Хәрби сәнәгать буенча килешү нигезендә Татарстанның оборона предприятиеләрендә конверсия уздыру өчен федераль бюджеттан 1995 елны 612,5 млрд. сум акча бирелергә тиеш булса, ә чынлыкта нибары 10,1 млрд. сум гына бирелә (ул вакыттагы бәяләр белән). Башка елларны да шундый ук хәл һәм башка килешүләрнең үтәлүе дә шул дәрәҗәдә.

Суверенитет игълан ителүгә җиде ел вакыт үтте. Җидееллык суверенитет нәтиҗәсендә социаль-экономик яктан һәм халыкның көнкүреше җәһәтеннән нәрсәгә ирештек соң? Угрыларның череп баюына, гаделләрнең һәм намуслыларның хәерчеләнүенә, тәмам комсызланган һәм шәфкатьсезләнгән түрәләрнең башбаштаклыгына, гади халыкның хокуксызлыгына, үлүчеләрнең артуына, туучыларның кимүенә...

Дөрес, читтән килгән тауар күп, ни телә югарылыгына күтәрә алмадык. Бу юнәлештә аерым адымнар бар, ә менә геосәясәткә нигезләнгән системалы милли хәрәкәт стратегиясе юк. Хакимият тә, стратегик уңышлар булмагач, җыр-бию, тамаша-шоу оештырып, шуны мөстәкыйльлегебез казанышы итеп күрсәтергә тырыша. Милли хәрәкәтнең иҗтимагый оешмалары да, кызыл чүпрәк артыннан чабучы үгез шикелле, көндәлек вак-төяккә бирелеп, милләтнең олы максат-бурычын оныта, йә булмаса, җил тегермәне белән сугышучы Дон Кихот сыман, реаль тормыштан ерак булган мәсьәләләргә вакытын сарыф итә.

Безнең ялгышлык нәрсәдә? Без һаман да Русияне реформалау чичәннәрдән һәм бездән генә тора дип уйлыйбыз бугай. Һәр хәлдә, иҗтимагый фикерләвебез шушы ике факторны чагыштырудан, һәм аларның үзара һәм Русия белән булган мөнәсәбәтләре тирәсеннән ерак китми. Аңлыйк, җәмәгать, империяне таркатучы төп көч без түгел, ә энергетика таләбе (эчтән) һәм геосәясәт ихтыяҗы гәл булганда гына милли максатка якынаю мөмкин икәнлеге – дәлилләүгә мохтаҗ булмаган аксиома икәнлеген беләбез. Бу уңайдан милли хәрәкәт өчен узган елның иң олы вакыйгасы итеп, һичшиксез, II Бөтендөнья татар конгрессын атарга кирәктер. Татар тарихына 1997 ел Бөтендөнья татар конгрессының икенче корылтае елы булып керердер дә. Конгресс, үзенең җитешсезлекләренә карамастан (иҗтимагый оешмалар үзләренең тәнкыйть сүзләрен җәмәгатьчелеккә җиткерделәр), татарны берләштерү, аны халыкара аренага чыгару, аның киңеленә бүгенгесе өчен горурлык һәм киләчәге өчен өмет уяту, милләтнең дәүләти мөстәкыйльлеккә ирешүгә һәм милли яшәешне саклауга булган ихтыярын дөнья җәмәгатьчелегенә күндерү, халкыбызның милли сәясәте геосәясәт кысаларында икәнлеген күрсәтү буенча милли хәрәкәтне югарырак баскычка күтәрде. Дөресрәге, күтәрү мөмкинлеген ачты. Бу мөмкинлек-

Милләтеңә хезмәт итү – Аллаһы сөйгән гамәл

ихтыяҗ да бар.

Милләтебез тарихының шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән чоры белән бүгенге көне арасында уртаклык гаять зур. XVI гасырның беренче яртысында да, хәзер дә дәүләтебездә бертөрлерәк сәяси вазгыять, халыкта бертөрлерәк психологик халәт: илнең икътисадый хәле авырая, түрәләр арасында хакимият өчен көрәш көчәя, хан белән морзалар каршылыгы арта, социаль гаделсезлек җәмгыятьтә киеренкелекне үстерә, күршеләр илдәге авырлыктан үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга тырыша...

Милләт өчен җан атып йөрүчеләрне 500 ел элек тә, хәзер дә дәүләт язмышына, аның иминлегенә кагылышлы сораулар борчый. Аерма тик шунда: элек аларда ничек итеп дәүләтчелегебезне саклап калу кайгысы булса, хәзер – ничек итеп аны аякка бастыру, аны ныгыту, үстерү, мөстәкыйль милли дәүләт төзүгә ирешү. Узган Мөхәммәдъяр елында да татар халкы алдындагы төп проблема шушы булды.

Татарга милли хәрәкәт кирәкме? Милли азатлык хәрәкәтенең бүгенге хәле милләтпәрвәрләрне канәгатьләндерә аламы? Милли сәясәтчеләр милләт алдындагы тарихи җаваплылыкларын һәм милләт мәнфәгатен тиешенчә аңлап эш итәләрме? Аларның ниятләре реальме? Милли хәрәкәттәге дәүләти һәм иҗтимагый оешмаларның гамәли сәясәте дөньядагы глобаль процессларга тәңгәл киләме?.. Милләт язмышына битараф булмаганнарны менә нинди сораулар татлы йокыдан мәхрүм итә бүген.

Сорауларга җавап бирү өчен үзебезнең соңгы ун еллык көрәш нәтиҗәләрен милли максат-бурыч күзлегеннән анализлап карыйк әле. Дәүләтчелек үсеше күзлегеннән караганда милли хәрәкәттә иң зур ихтыярый күтәрелеш 1990-92 елларда булды. Суверенитет турындагы Декларация кабул ителүе һәм аның референдумда халык тарафыннан раслануы шуның ачык дәлиле.

Аннан соң әкренләп артка чигенү башланды. Конституциядәге Русия белән ассоциацияләшкәнлек һәм шуңа тәңгәлләштерү өчен дәүләт атрибутларының чикләнгәнлеге. Декларация һәм референдумда күрсәтелгән халык ихтыярыннан беренче чигенү булса, Русия белән дәүләтара Шартнамә һәм хөкүмәтара килешүләр, юридик күзлектән караганда, Конституцияне күпмедер бозу иде. Инде килеп, аларны да тиешенчә сәң, шуны ал... Әгәр акчаң булса. Ә акча эшләргә бирмиләр. Халыкара танылу алган югары дәрәҗәле фәнни-техник, матди һәм кадрлар потенциалы булган республикада үз тауар җитештерүчеләребезгә, урта һәм вак бизнеска ирек җитми. Шунлыктан килеп туган эшсезлек һәм акчасызлык халыкның башын тагын да түбәнрәк идерде.

Урманга утын ташыган күк, нефтехимия производствосы белән дан тоткан Татарстанга вагонлап-вагонлап ерак илләрдән полиэтиленнан эшләнгән сыра, су шешәләре кайтарталар. Бу турыда бер чиновник, нигә читтән һава ташыттырасыз, дигән сорауга, без моның белән Татарстанның экологиясен яхшыртабыз, дип җавап бирде. Экологиясе ничектер, ә менә аның экономикасының тамырын корытабыз мондый гамәлләр белән.

Инде суверенитет нәтиҗәсенең сәяси-хокукый ягына тукталыйк. Мөстәкыйльлек ул иң әүвәл власть-хакимият дигән сүз. Конституциябезнең 2 нче статьясында: "Татарстан Республикасында бөтен хакимият халык кулында. Халык дәүләт хакимиятен шушы Конституция нигезендә турыдантуры, шул исәптән референдум юлы белән дә, дәүләт органнары системасы аша да гамәлгә ашыра", – диелә. Үтәләме бу конституцион хокукыбыз? Суверенитет халыкка хакимият бирдеме? Бүгенге дәүләти хакимияттә халык вәкилләреме, халык хезмәтчеләреме? Бездә сайлаулар тәртибе халык ихтыярын гамәлләштерүгә хезмәт итми. Шунлыктан халык хакимиятне, хакимият халыкны үз итми, алар икесе ике юлдан бара кебек. Димәк, суверенитет та халыкныкы түгел булып чыга. Менә ни өчен суверенитет идеясе хәзер халыкны артык дулкынландырмый – ул аңа хакимият тә, җитәрлек милли ирек тә бирмәде, көнкүрешен дә яхшыртмады.

Моннан нинди нәтиҗә ясарга тиеш булабыз соң? Берәүләр, моннан чыгып, дәүләти бәйсезлек өчен көрәш – ул ялгышлык, диләр, икенчеләре, моңа татар үзе түгел, башта аны үзерләргә кирәк, диләр, өченчеләре исә, гомумән, милли хәрәкәтнең кирәклеген шик астына куялар. Әйтергә кирәк, бу – ялгыш нәтиҗә, һәм ул сәяси карашның тарлыгыннан килә. Сәбәп суверенитетта түгел, аның юклыгында. Конституцияне эзлекле рәвештә гамәлләштерү булмаганлыктан, ул декларация генә булып кала бирә.

Ник алай соң? Аяныч ки, без милли сәясәтебезне геосәясәт (тыштан). Ә менә геосәясәт ихтыяҗын канәгатьләндерүдә татар милли хәрәкәтенең һәм Татарстанның роле зур.

Геосәясәтне Америка билгели һәм сәяси ихтыяҗлар уртаклыгы безне – дөньяның иң куәтле иле АКШны һәм кечкенә Татарстанны – союзниклар итә ала. Шикләнәм, мондый форсат барлыгы белән күпләр килешмәс, бу фикерне хыял җимеше дип кенә кабул итәр (1993 елны Брюссельдә НАТОның штаб-квартирасында сөйләшүләрдә Татарстанның рәсми булмаган делегациясе составында бу фикерне яклаучы табылмады). Ә менә Америка политологлары һәм сәяси экспертлар моңа бик җитди карый. Алар татар милли хәрәкәте белән нык кызыксыналар, аны өйрәнәләр һәм тиешенчә бәялиләр. (Хәер, алар гына түгел, Русиянекеләр дә битараф түгел безнең хәрәкәткә). Безгә, тыйнаклыкның коллык елларында формалашкан һәм үз-үзебезне богаулап торучы өлешеннән арынып, форсаттан дөрес файдалану зарур. Бу – бер.

Икенче яктан, геосәясәт ихтыяҗы империяне реформалауның глобаль конфликтсыз узуын таләп итә. Татарның холкы – менталитеты моңа да уңай җавап бирә.

Шуларны истә тотып, дәүләти мөстәкыйльлек мәсьәләсендә, сәяси инициативаны ирешелгәннәр белән чикләмичә, алга атлау максатка ярашлы булыр иде. Бу адымнарны мин болайрак күзаллыйм:

– Идел-Урал идеясенә гамәли юнәлеш бирү;

– җәдиди исламчылыкны таратуда активлашу ("Евроислам" сәясәте);

– "татарлар үзләре яшәгән урыннарда һәм Татарстан Идел-Урал төбәгендә – тынычлык гаранты һәм Русиядәге реформалар авангарды" ролен башкару;

– оешып килә торган милли-мәдәни ("тупраксыз") мөхтәриятләрне "тупраклы" итү чарасын күрү;

– Якын Көнчыгышта кан кардәшләребез (бүгенге яһүдләрнең 85 процентын хәзәрләр нәселеннән булган ашкенази токымы тәшкил итә) һәм дин кардәшләребез (ислам динле гарәпләр) арасында тынычлык урнаштыруда арадашчы булу...

Бу – милли сәясәтнең стратегик юнәлеше. Әлбәттә, агымдагы проблемаларны, тактик бурычларны да инкарь итәргә ярамый. Хәлбуки, аларның хәл ителү юнәлеше стратегик сызыкка тәң не гамәлләштерү Конгрессның үзеннән һәм милли хәрәкәтнең башка оешмаларыннан тора.

Башкаларның монда ни хаҗәте бар, диярсез. Мәсьәлә шунда ки, конгресс, ярым дәүләти оешма буларак, бөтен татар дөньясын үз канаты астына җыя алмый. Татарстанның үзендәге кебек, чит төбәкләрдә дә рәсми хакимияткә оппозициядә торучы оешмалар һәм төркемнәр бар. Аларның кайберләре августта үз делегацияләрен дә җибәргән иде, тик алар Конгресс корылтаена әләгә алмагач, алар белән сөйләшү ТИҮдә оештырылды. Милли мәсьәләләрне хәл итүдә Конгресс алган темп аларны канәгатьләндерми. Новосибирскидән килгән делегация, мәсәлән, бу темпны иномарканың газ педален идәненә терәп чабучы ассимиляция артыннан йөгерүче җәяүле белән чагыштырды.

Татар проблемалары күпкырлы. Милли хәрәкәттә катнашучылар да төрле яшьтәге, төрле караштагы, төрле холыклы һәм төрле һөнәр кешеләре. Алар төрле географик киңлекләрдә, төрле климатик һәм социаль шартларда яши. Аерым бер генә оешма да аларның ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерә алмый. Бүгенге оешмаларның һәркайсының милли хәрәкәттә үз урыны һәм үзенең социаль базасы бар. Шунлыктан Конгресс карарларының үтәлүе аның үзеннән генә тормый, бу – бөтен оешмалар эше. Менә шушы хакыйкатьне аңласак, бәлки арабыздагы таркаулык та бетәр иде. Һәм җиһанга сибелгән татар халкы Бөтендөнья татар конгрессы аркылы, бердәм һәм бербөтен булып, бер программа белән халыкара аренага чыгар һәм анда үз куышын таба алыр иде. Шәт, шулай булыр, чөнки безгә башка чара юк. Бу – Мөхәммәдъяр хәтере алдындагы бүгенге буыннар бурычы.

Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә, милләтеңә хезмәт итү – Аллаһы сөйгән гамәл, диелә. Без изге юлда. Аллаһының кодрәте вә рәхмәте илә морадыбызга ирешербез, иншалла.

Рашат САФИН,
Бөтентатар иҗтимагый үзәге рәистәше.

Әле генә кердек бит без Юлбарыс елына. Әле генә үз каләмдәшләребез-юлбарысларның берничәсе белән таныштырган идек сезне. Бактың исә – алар, шигъри юлбарыслар, арабызда шактый икән һәм менә янә аларның берсенә – Рәшит ШИҺАПка да 60 яшь тулган!

Рәшит Шиһапов – шагыйрьләр ягыннан, Балык Бистәсе районының Яншык авылында туган. Без аны әле кайчандыр Татарстан телевидениесендә хезмәткәр итеп тә белә идек. Казан педагогия институты (хәзер педагогия университеты) студенты булган елларында да шигырьләр-җырлар язганын беләбез.

Кайчандыр, ниндидер сәбәпләр аркасында, Рәшит Шиһапов әдәбияттан ераграк "китеп", югалыбрак торды. Әмма каләмдәшебез иҗаттан читләшмәгән. Инде хәзер ул даими рәвештә язган әсәрләрен җыентыклар итеп бастыра башлады. Аның 1992 елда дөнья күргән "Хисләр давылы", "Җырларымнан мине эзләгез" (1993), "Яратулар белән дөнья тулы" (1996) кебек китаплары шагыйрьнең иҗат активлыгын күрсәтә. 1997 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Заман белән бәхәс" кебек җыентыгы да шуны раслый.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Ш.Бикчурин исемендәге әдәби бүләк иясе Рәшит Шиһапны гомер һәм иҗат бәйрәме белән ихлас тәбриклибез!

Рәшит ШИҺАП

Туган җирен яратканнар гына Туган җирдә тамыр җибәрә...

Шигырь нечкәлек билгесе белән языла

Хаклы сорау

Шомыртның мөлдерәп пешкән
Җимешен күреп алып,
Берәү җыярга тотынды,
Кинәт кенә тукталып.
Ботарлады ботакларын,
Сындырды зур көүсәсен.
Канлы ярага батырды
Шомыртның тәз гәүдәсен.
Үзе өчен яшәүчедә -
Шәфкатьсезлек, сансызлык.
Һәр нәрсәгә ерткыч караш,
Сансызлыкта – кансызлык.
Шулчак агач телгә килде:
- И кеше диген бәндә!
Мин җәрәхәткә түзәрмен...
Синең намус ни хәлдә?
Аны югалттың мәллә?..

21 сентябрь, 1979.

Сагыну

И үткәннең оялчан, тыйнак сүзле
Һәм самими татар кызлары.
Алып кайтыр идем бу көннәргә
Сезне, әгәр булса юллары.

Хәзергеләр өчен үрнәк итеп
Чакырыр идем аулак өйләрдән,
Нәфис җанлы, саф татарча телле,
Гореф-гадәтләрне сөйгәннәр!

Шәҗәрәгез васыятен үтәп,
Йолабызга тугры булдыгыз.
Әдәпләрдән торган нигез ташлы
Күркәм гаиләләр дә кордыгыз.

Сез дөньяга биргән егетләрнең
Болытларга ашты даннары.
Халкы өчен, иле өчен типте
Тамырында кайнар каннары.

Чуарланды бүген милләт йөзе,
Чуарланды хисләр, иманнар.
Миләүшәдән туа Мариналар,
Галиядән туа Иваннар.

Вакытлыча назлар, катнаш никах,
Төрле телдә бала юату,
Гибрид алмашларның мәнсезлеге -
Милли киләчәккә ук ату.

И үткәннең керсез гүзәлләре,
Сез дә төшмәдегез һавадан.
Милләт канын савыктыру өчен,
Сезнең яшьлек чәчәк аткан чорны
Бер кабатлар идем яңадан.

8 ноябрь, 1997.

Милләтем балалары

И дөнья! Нигә син шулай
Каныктың милләтемә.
Азмы күз яше китердең
Мөхәммәт өммәтенә.
Мәмләкәтләргә сибелгән
Халкымның балалары.
Юк аларның туган иле,
Бар йөрәк яралары.
Әрнүле зарын ишетәм
Диңгезләр, таулар аша.
Өметләре, гозерләре
Безгә килеп тоташа.
Күңелләре белән йөри
Ватаным кырларында.
Сагыну, югалту елый
Агылган җырларында.
Сызгыра җил, дулый гына
Океан өсләрендә.
Җилләр булып кайтып китә
Күбесе төшләрендә.
Талкыды барын да язмыш,
Ташлады дулкыннарга.
Күпме милләттәшнең җаны
Адашкан упкыннарда.
Кайта алмас инде алар
Шәҗәрә калган якка.
Ләкин яши алар читтә
Милләтнең данын хаклап.

29 август, 1997.

Имәннәрнең җыры колагымда

Атлар утарына киртә кордың,
Казыкларын
Кактың кемдер кискән туйрадан.
Туйраларың яфрак ярыр диеп,
Ул вакытта кем соң уйлаган?

Бүген алар авыл кырыенда
Буй урмандай җилдә тирбәлә.
Туган җире яратканның гына
Казыклары тамыр җибәрә.

Денсезлектән изаланган чорның
Михнәтләрен салып иңеңә,
Бәхет эзләп киттең, тик кайтмадың
Үскән туфрагың көткән иленә.

Узган мәнсез тормыш эргәседәй,
Киртәләрең күптән ишелде.
Ә имәннәр калды, орлыгыннан
Күпме яшь туйралар тишелде.

Язларында шул имәннәр шавы,
Әйтерсең лә, калган сүзләрең:
"Бәхет бер килмәсә, бер килә ул,
Елмайса да салкын күзләрең".

Имәннәрнең җыры колагымда,
Колагымда чыңлый көн туса:
- Кеше онытылмый, әгәр сиңа
Сүнеп барган чакта җан өрсә.

1 ноябрь, 1997.

Җырлы Татарстан

Милләттәшем авыр юллар үткән,
Елгыр атта кичкән карурман.
Өметләре кая ташламасын,
Юлдашы гел моңлы җыр булган.

Җырлап кергән изге көрәшләргә,
Җиңү даулап йөргән иленә.
Батырларча ауган,
Әмма җыры калган
Гомере булып туган җирендә.

Мондый гомер чәчкән орлыклардан
Шытып чыкты җырлы буыннар.
Бер кайда юк, газиз Татарстан,
Синең кебек җырлы урыннар.

Зәңгәр күкләрең дә, кояшың да,
Аең, йолдызларың җырлылар.
Әльтаир*дан милли бер моң килә,
"Казан кичләре"н, ахры, җырлыйлар.
Җырлы якның туфрагы да җылы,
Шаулап үсә мулдан ашлыклар.
Татарстан дигән зур төбәктә
Татар дигән җырлы халык бар.

20 ноябрь, 1997.

* Әльтаир – ерак йолдызлык.

Хәтерләү

Чатнама кыш...
Әрсез зыкы суык
Тәрәз пыяласын чартлата.
Өйдә утырганнар юлаучының
Исән калганына шакката.
Очар кошлар туңып егылып төшә,
Бүрәнәләр шартлап ярыла.
Салкын төрдә бер-берсенә елышып
Чүңкәйгәнбез, әнкәй, яныңа.
Күзләреңдә сагыш, авыр уйлар,
Утын беткән мичкә ягарга.
Шул вакытта бер карарга килдең:
Урмангамы менеп карарга.
Яу кырында йөргән әтинең дә
Инде күпме килми хәбәре.
Их, җылытыр иде өебезне,
Әгәр килсә кайнар сәламе...
Ыңгырашып шыгырдады юллар,
Онытканбыз, ахры, чаманы.
Авыр йөктән юлга ябышып килә
Чананың да тимер табаны.
Өстерибез икәү тормыш белән
Агач ботакларын... җигелеп.
Тәмуг газаплары кысканда да,
Син калмадың, әнкәй, чигенеп.
Кайтып җиткәч, күрше хатыны иңнән
Каткан чана бавын салышты.
Яшең тамды... юк, таммады, әни,
Алар синең матур керфегеңә
Боз кисәге булып ябышты.
Кинәт кенә үз-үзеңне онытып,
Онытып дөньясының җәберен,
Өйгә алып кердең һәм аһ ордың:
- Битең өшегән, улым-бәгырем!
Син каз маен сөрттең, ә аннары
Төреп салдың әти тунына.
Әйтерсең лә, әти җылысыннан
Изрәп йоклап киттем тын гына.
Ул елларга кабат борылып карыйм,
Тәмуг иде гомер итүе...
... Йөрәгемне телә аналарның
Алжу тәәп җирдән китүе.

19 октябрь, 1997.

Җавап

Бәхәс китте. Күперәйде Сафа:
– Ну, яшисең Гата?!
Ачы таңнан бил бөгәсең,
Ясыйсың күп хата.

Көн-төн дөнья куалыйсың,
Андый тормыш – чүптер.
Син бит җиргә бер килгәнсең,
Рәхәтләнеп типтер.

Менә мин табам да кабам,
Йөрим әрлек кебек.
Ә син ачтан үлеп барган
Зәгыйфь сөлек кебек.

Әйтте Гата:
- Синдәй эштән генә түгел,
Үзеннән дә кача.
Ашау өчен яшәмә син,
Яшәү өчен аша.

2 ноябрь, 1997.

"Татар акылы төштән соң" дигән әйтем бар. Борынгы бабаларыбыз вакыт-вакыт шулайрак үкенгәннәрдер, күрәсең. Эш узып, туннар тузгач дигәндәй, тешләр терсәкләре ерагайгач сыктаганнар, мескенкәйләрем! Иң элек аларны мәгълүм залимнәр мәкер белән дә, вәхшилек белән дә төп башына утырта килгәннәр: җир-суларын, байлык-мөлкәтләрен басып-талап алганнар, үзләрен мәңге чыга алмаслык баткаклыкка сөреп керткәннәр. Соңра үз җирләреннән үк бер-ике дисәтинәсен кире кайтарып, "сай түбәтәйле" кайбер мөселманнарны чит-ят динне кабул итәргә күндергәннәр, бәгъзеләрен дегет чиләге асылган "тройка" арбасына "извозчик" итеп утыртканнар. Бүләкләре бер үк – татарны дененнән яздыру. Кыскасы, орыш-вәхшилек белән генә майтара алмагач, мәми, тәти белән алдаганнар безнең татарны. Акылына килгән- килүен соңыннан, әмма көн авышкан, "тройка" тәгәрәгән була инде ул чакта...

Алдануыбыз бүгенгәчә дәвам итә. Әле кайчан гына, алман яһүдләре әвәләгән Октябрь инкыйлабына ияреп, урысның үзе кебек, нык алдандык. Аннары баш очында кылыч айкап, Урта Азия чүлләренә барып чыктык, үзебезгә өстәмә дошманнар эзләдек. Бүген үкенәбез инде...

Госман ГОМӘР

кертмәкче булам, үзем зарарлы дип санаганнарына каршы чыгам.

Су язып май төшми

Халык фикере дигән сылтау белән "Шәһри Казан" гәзите бу төр мәкаләләргә аеруча күп урын бирә. Сүзем юк, әлеге гәзит республикада иң демократик басмалардан саналырга хаклы. Әмма ул соңгы вакытларда "качышлы" уены уйный сыман. Ни өчендер редакция коллективы бер үк авторның шул ук фикерләрен гәзит битләрендә әледән-әле басып чыгара. Беренче чиратта мин З.Мифтахов язмаларын ("Ш.К." 05.07.97, 02.08.97 һ.б.) күздә тотам.5 июльдәге мәкаләсенә, мәсәлән, латинчалап "Ке(җ) кенә зыянда зур кисәтү бар" дигән баш куеллык, дисез. Акыл сатуны анысы барыбыз да булдырабыз. Тик моннан милләтебезгә файда юк. Тагын кабатлыйм, кешеләрне ышандырырлык фикерең, аргумент-дәлилләрең юк икән, бер генә тапкыр дәшми калырга да мөмкин. Күбрәк галим-әдипләр сүзенә колак салырга кирәк безгә.

Русия латинга кайчан күчәр?

Мәкаләмдә һәр авторга "отпор" бирү максатын куймадым. Аллам сакласын! Ихластан язам. Нишлим соң? Гәзит битләрендәге мәкаләләрне укыгач, җан әрни, кайбер фикерләргә чәчләрем үрә тора. Сезнең ише мин дә элеккеге совет гражданы лабаса. Әл-хасил шундый икән, башкалар кебек мин дә үз фикеремне әйтә алам-

Күп үлчәдек -

Тәвәккәлдә тау күчә бар

Ярар, болары мәкаләмнең "прелюдиясе" иде. Үткәндәгеләргә үкенеп май кунмас, төп мәсьәләгә күчик.

Дөньяларның болайрак үзгәреп китүе без татарның да күзен ача бугай. Мәгариф, мәдәниятебезне үстерү зарурлыгы хакында иң элек галим-голәма чаң сукты. Ул шулай булырга тиеш тә! Кемлекләрен оныта башлаган маңкортларны милләт җанлы сәясәтчеләребез, әдип-галимнәребез дә уятмагач, якты киләчәккә әйдәп бармагач, тагын кемгә иярергә кала гади инсаннарга?! Татар язуын яңа имляга күчерү идеясе дә нәкъ менә шушы мохиттә туды, ул алдыбызга заман таләпләре куйган глобаль бурычлардан чыгып тәгаенләнде. "Татарстан халыклары телләре турында" Законны гамәлгә кертү концепциясе эшләнде. Бу проектның гамәли авторы – хөрмәтле академигыбыз Мирфатыйх әфәнде Зәкиев. Закон, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнеп, 1927-39 елларда кулланылган яңалифнең уңай якларына таянып, киң җәмәгатьчелекнең теләген исәпкә алып, татар әлифбасын халыкара әлифбалар системасына якынайтуга һәм шул юл белән республиканың дөньякүләм коммуникация системасына керүен җиңеләйтүгә, гомумән, республиканың һәрьяклап үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Бар да ап-ачык, һәммәсе дә аңлашыла. Яңалифкә күчәргәме, юкмы, дигән бәхәскә менә шушы урында нокта куелды. Рәхмәт академикка зур тырышлыгы өчен! Ләкин мин Мирфатыйх әфәнде белән бер мәсьәләдә һич килешә алмыйм. Ә матбугатта бу хакта, бәлки, башкалар искәртер, дип, сүз кузгатырга ашыкмадым.

1939 елда яңалифтән кириллицага күчкәндә галимнең үзенә дә 10-11 яшьләр тирәсе булгандыр, 2 нче, күп булса, 3 нче сыйныфта укыгандыр. Ул бу чорны яхшы хәтерләргә тиеш. Яшьрәк булсам да, мин дә хәтерлим. 5 яшьләремдә яңалиф белән басылган сунарчы турындагы китапларны шатырдатып укый идем. Мактанмыйм, хак-дөресе шулай, бу урында аны искә алмый ярамый. 1 нче сыйныфка кергәч, укуны кириллицадан башларга туры килде. Программада каралганча, өч ай дигәндә без инде әлифба белән эшне тәгәлләп, "Уку китабы"на күчтек. Ул хәзер дә шулайдыр дип беләм. Менә сиңа кайберәүләрнең латинга күчү ун елга сузылыр диюләренә җавап.

Хөрмәтле Мирфатыйх әфәнде! Сез дә шундыйрак караштa торасыз бит. Рәнҗетмәгез мине һәм минем ишеләрне. Кабатлап әйтәм, Сез татар теле гыйлемен үстерүгә күп хезмәт куйган шәхес. Инде хаталанмагыз, төптән-җирдән тагын бер кат уйлашыйк әле. Ә болай, үлчәнәсе үлчәнде инде, иншалла, яңалифкә кире кайтырбыз, кисүне дөрес чамалап кисәсе иде!

Ни өчен латин графикасына күчүне 1998 елдан башлап җибәрмибез, 1999 елга калдырабыз? Сез, укытучылар җитешмәс, дигән фикердә торасыз. Хата бит бу! Шул ук гамәлдәге мөгаллимнәр, 1939 елдагыча, укыту эшен, бигрәк тә хәзерге зур тәҗрибә белән бик тиз тормышка ашырачаклар. Моңа карап кайберәүләр, "куыра бу" дип елмаерга да мөмкин. Ашыкмагыз әле битәрләргә! Кабатлап әйтәм: күчү өчен ике ел бик җиткән, хәтта артып ашкан. Ә китаплар, дәреслекләр басыла торыр анысы. Кириллицада чыкканнарына килгәндә, алары нәкъ менә сигез-ун ел буе файдалануда булыр, минемчә. Тел белүчеләр бүген инглиз, француз, алман, төрек китапларын оригиналдан укыйлар лабаса. Сүз уңаеннан әйтим, барысы да латин графикасында болар. Бүгенге 3-5 нче сыйныф укучылары өстәмә рәвештә шушы графиканы (хәтта гарәпнекен дә) ай дигәндә үзләштерәләр.

Эш Мирфатыйх әфәнде проектына гына килеп терәлсә, фикеремне аңа телефоннан челтерәтеп яки турыдан-туры үзен күреп кенә әйткән булыр идем. Күчү-күченү мәсьләсендә инде Президентыбыз да анык фикергә килгәч, эшләр бөтенләй икенче юнәлеш алды бит, җәмәгать! Моңа кайбер гаммәви мәгълүмат чаралары да кушылып китте. Графика мәсьәләсендә баш очыбызга балта эленде. Бүген мин көндәлек матбугат битләрендә куертылган кайбер фикерләргә ачыклык кертмәкче булам, үзем зарарлы дип санаганнарына каршы чыгам.

ган. "Җ" белән "Ч"ны бутаганнар. Төрек алфавитындагыча киткән. Монысы чүп кенә! Автор нинди зыян турында кисәтә соң милләттәшләрен, шунысы аңлашылмый менә?! Карасаң-баксаң, үзе язганча, автор – гәзит хезмәткәре, татар теленең аңлатмалы сүзлеге һәм башкалар белән эш итә икән. Борчылуы шуңа: яңа имля белән язылган сүзлекләрдән кирәкле сүзне табу өчен 10-15 секундка күбрәк вакыт әрәм итеп, шуның өстенә өстәмә энергия сарыф итәрмен, дип шүрли ул. Ай-яй, малай, ничек фәнни яктан килеп шапылдаткан әфәндебез! Менә бөтен аргумент! Хәер, автор үзе үк: "Безнең заманда чыккан сүзлекләр дә әле бик озак кулланышта йөрер", – ди. Әлбәттә, әлбәттә йөрер! Тик сез генә каршы килмәгез, әфәндем! Югыйсә, "фәнни өлеш" кертеп (үз сүзләрегез), фараз кылуларыгыз бөтенләй кәефне җибәрде.

Кайберәүләр фикер әйтәм дип абсурдка барып җиттеләр. Берәүсе 1991 елдан башлап икмәк бәяләрен, элемтә чыгымнарын анализлый. Белмим, белмим, икмәк белән яңалифнең нинди уртаклыгы бардыр? Аның: "Әлифба алмаштыруның, асылда, төп максаты һәм нәтиҗәсе нәкъ шулдыр", – дигән сүзләрен бернинди академик та төшендереп бирә алмас. Автор уенча, яңалифкә күчеп без җирсез-сусыз, икмәксез, итсез-сөтсез калабыз, имеш. Милләтнең киләчәген билгели, олы бер вәзгыятьне хәл кыла торган әлеге мөһим мәсьәләне әнә кайсы якка таба борып җибәрергә азапланалар кайберәүләр. Суд карары чыгарылмастан, берәүне син карак, дип тамгалауга тиң бу. Авторларның берсе "бүгенге көн өчен мөһим булмаган эшләр белән шөгыльләнүебезне" гаепли, аныңча, "кечкенә яки ярымҗимерек йортларда яшәүчеләр белән сөйләшергә онытмыйк, графика үзгәртүнең кирәкме, юкмы икәнен алар бик яхшы беләләр" икән ич. Рәхмәт, агайне, алтын киңәшләрең өчен! Хәер, "мин тел галиме түгел", дисез диюен, әмма тел мәсьәләсендә аяк терәп сөйләшәсез. Фикерләрегезнең милләт мәнфәгатьләренә ни дәрәҗәдә хезмәт итүе хакында уйлап карамыйсыз. Бик тә кызганыч!..

Әлеге авторга аваздаш тагын берәүсенә тукталасы килә. Хөрмәтле хезмәт ветераныбыз М.Шакирҗанова апаем, "ликбез заманына кайтабыз" дип, юкка борчыласыз бит. Бу эшне иртәрәк башкару мөмкин булмады шул безгә. Ни үкенеч! "Хәзер татар алфавиты латинга күчерелсә, мин гомерем буе диярлек (39 ел) укыткан укучыларым тоташ надан калачак" диюегез, мантыйксыз афиша гына лабаса. Алфавит алмаштыруны Сез, зур акылсыздыр. Әнә, Чүпрәледән А.Әмирханов әфәндебез язып җибәргән бит. Ул – яңа имляга каршы кеше. Аргументлары саллы: беренчедән, чыгым күп кирәк (әлбәттә), икенчедән, китапларны латинчага күчерәсе була (билгеле, яңадан басылыр), өченчедән, 60-70 яшьлек картларга, хат укытыр өчен бер тавык кыстырып, авылның икенче башына барасы була, имеш. Нәйтергә инде сезгә?! Аптыраш, валлаһи!.. Дүртенчедән, Русия үзе, башка дәүләтләр күчәргә телиләрме икән соң латин графикасына, дигән сорауны да куясыз. Монысы бит, агайне, Русиянең үз эше. Минемчә, бик ихтимал вариант. Дөньясы шулайрак китереп кысса – кая барасың. Күчми хәлең юк. Бүгенге көндә кириллицада Русия белән Балкан Болгарстаны гына яза. Менә сезгә тагын бер яңалык: хәзер Латвиядән Русиягә җибәрелә торган телеграммалар бары тик латинча гына язылырга тиеш. Бу ил хөкүмәте шундый карар кабул иткән. Ничава! Укырлар. Урыс җырын күп җырладылар, җитәр, бәлки? Иң якын елларда Мәскәүгә депешалар, сәнәд-документлар диюем, Әзәрбәйҗан, Үзбәкстан, Таҗикстан һәм башка күп дәүләтләрдән дә латин имлясында гына очачак. Ышаныгыз моңа, йөз проценты белән. Дөньяви мохитнең (Гөрҗестан, Кытай, Япония һәм Гарәп илләрен искә алмаганда) гел генә дә латин алфавитында эш итүен онытмаска кирәк. Хәтта югарыда саналган дәүләтләр дә халыкара сәнәд-документларны латин белән тутыралар. Яңа имляга күчүнең иң зур һәм котылгысыз аргументы – кампитрлаштыру дәверенең башлануы. Русия күчәрме соң, дигән сорауга җавапны шуннан эзләргә кирәктер.

Иң кирәкле шәйдер

Кампитр дип авыз ачканмын икән, шунысын да әйтим: латин хәрефле бу могҗиза хәзер завод һәм оешмаларга гына түгел, барлык уку йортларына, мәктәпләргә, хәтта шәхси өйләргә дә үтеп керде. Ышанасызмы, юкмы, дусларымнан берничә гаилә йорт эшләрен, шул исәптән, аш-су хәзерләүне дә, киләчәктәге барлык мәсьәләләрне шушы "җен машинасы" ярдәмендә хәл итә. Балалары дәрес хәзерли, катлаулы математик-геометрик мәсьәләләрне чишә, тегe яки бу кануннардагы үзенә кирәкле маддәләрне секундлар эчендә эзләп таба. Дөнья белән элемтә тотуда да кампитр иң кирәкле шәйдер. Боларны сөйләп тору үзе артык, минемчә. Чүпрәледән А.Әмирханов, Яшел Үзән шәһәреннән гәзиттән мәхрүм калабыз, дип уфтанучы Г.Фәсхетдинова,

латинга күчеп "җәберләнәчәк татар-ны" йолып калырга тырышучы мөгаллимә Н.Гобәйдуллина (Казан), ни сәбәптәндер, мирас югалудан шүрләүче Х.Исмәгыйлев (Лениногорски) ханым һәм әфәнделәргә менә шуларны төшендерәсе иде. Әнә бит, Минзәлә районының Хуҗамәт авылы мәктәбендә, язып эшләгәч, гарәп алфавитын да балалар бер атна эчендә үзләштергәннәр. Ә бит гарәпләрдә Г", "К", "З" һәм башка кайбер хәрефләр әйтелешенә карап өчәр төрле языла һәм укыла. Башлары да бар икән кеп-кечкенә малай-кызларның! Ә менә кайбер ата-аналарга, хәтта мөгаллимнәргә дә шушы нәрсә һич барып җитми.

Ни гаҗәп, Казан каласыннан гади эшче А.Сафин әфәнде бүгенге вәзгыятьне бөтен тулылыгы, җитдилеге белән аңлый. "Латин алфавитын өйрәнү өчен 2-3 көн җитә", - ди ул. Ун ел һәм ике-өч көн?! Гаҗәп бит, ә? Шәхсән, мин үзем моның шу-

дигән мәгънәсез сорауны куеп торырга да кирәкми, югыйсә. Ел башыннан ул хәзерлек эшләренә керешү муафыйк. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә ниндидер күләмдә эш башланса, тагын да яхшырак булыр иде. Ә инде гәзит-журналларыбыз мәкаләләрнең бер өлешен һичшиксез яңалифтә бассын. Хәреф хаталары да җибәрелергә мөмкин. Укуын да авыррак укырбыз баштарак. Күнегербез. Татар башын чукындыру түгел ләбаса. Асылыбызга кайтабыз – шунысы ифрат мөһим.

Инде сүз соңында бу мәкаләне язарга этәргән тагын ике очракка тукталасым килә. Аның беренчесе – Флорид Әгъзамовның "Мәгърифәт" гәзитендәге мәкаләсе. Яшьлек дустым, хезмәттәшем, ут күршем ул минем. Журналистларның үзләрен әзерләүче галим. Ә яңалиф мәсьәләсендә ялгыша, минемчә. Ничектер шикләнебрәк карый кебек ул бу эшкә. Бәлки, анда барган гамәли авырлыкларга күбрәк

инде кисик!

лай икәненә тамчы да шикләнмим. Үзебезнең баштан үткән хәлләр. Заманында француз, алман, чуаш телләрен су кебек эчкән, диплом язган, оригинал белән эш иткән һәм тагын кайбер телләрне шактый дәрәҗәдә үзләштергән мәрхүм шагыйребез Шәрәф Мөдәррис бервакыт әйтә шулай: теге атнада мари теленә тотынам, өч ай җитәрдер, ди. Без елмаешып куйдык, янәсе, мөмкинме бу хәл? Ышанасызмы, әнә, хатыны Ләбибә апа Ихсанова шаһит, әйтсен, ике ай дигәндә күренекле шагыйребез күп телләр белүе өстенә мари телен дә үзләштерде. Ә бит ул гыйльми сәркәтип (фәнни яктан барлык мәкаләләрне укып баручы) булып эшләде, төннәрен шигырь дә язган. Теләге булгач, тел дә өйрәнгән. Теләк кирәк. Юк, җәмәгать, бармак белән санарлык 20-30 хәрефне ("А" – "А" инде ул!) ун ел буе ятласак, безнең барыбызны да Арча кырына илтеп тыгачаклар. Адәм көлдермик, зинһар! Булыр гәзите дә, китабы да, кассетасы да. Ә тормыштагы ярты эшебезне кампитрлар башкарыр.

Күп вакыт узмас, без дә, латышлар шикелле, "чын суверенлык" алырбыз, иншалла! Чөнки Җир йөзендәге империяләрнең таркалу чоры галимнәр тарафыннан төп-төгәл исәпләп чыгарылган, ул сан матбугатта күп тапкырлар чагылып узды. Әле генә урыс матбугаты тагын чаң сукты: урыслар кими, ә татар үсә, берничә елдан барысына да "түбәтәйлеләр" хуҗа булачак икән ич. Бирсен Ходай!

Ә бит гоман кылуларында дереслек юк түгел. 1913 елда шул ук урыс галимнәре, алар белән бергә чит илләрнеке дә, тагын 50 елдан, димәк, 1963-65 нче елларда Русиянең бөтен сәнәгате – завод-фабрикалары, нефть промыселлары тулысынча татарлар кулына күчәчәк, дип фараз иткән. Һәм шулай буласы икән дә! Моңа Үктәбер инкыйлабы комачаулады. Безнең авангард тарих сәхнәсеннән бәреп төшерелде, илдә-җирдә социалистик система урнашты. Чамалыйлар, Мәскәүдә җилнең кайсы тарафка исүен. Шуңа күрә дә Татарстан икътисады һәм сәясәтенә аяк чалу бара да инде. Әлегә яңа имля мәсьәләсе аларны өркетми, ә безгә җиң сызганып тотынырга кирәк. Кичектерү – чыннан да үлемгә тиң, аннары мондый форсат булмаячак. Әнә бит, суд, прокуратура һәм көч министрлыкларын үз юрисдикциябезгә күчерә алмыйча калдык. Имля мәсьәләсендә дә шундый хәлдә калмаска иде безгә. Югалган акылны төштән соң эзләп йөрүдән куркам мин. Файдасыз гамәл булачак ул.

Безгә бүген күчәргәме-күчмәскәме игътибар бирәдер. Ансыз гына булмый инде ул, Флорид дускай! Синең әле матбугатыбызны үстерүгә ярдәм итәрдәй бик күп белгечләр әзерлисең бар. Сакла энергияңне! Фикерләребезнең ни өчен тәңгәл килмәвен югарыда азмы-күпме дәлилләргә тырышып карадым кебек.

Ә менә Рафис Корбанның ("ШК", 27 ноябрь, 1997) "Мирастан баш тарту – муенга элмәк салу түгелме?" дигән зур сораулы мәкаләсен укыгач югалып калдым. Яңалифкә күчүне мин үзем, халыкара системага керү белән беррәттән, мирасыбызга кире кайту дип тә аңлый идем. Автор тагын бер кат уйланырга мәҗбүр итте. Ничекләр итеп югалтабыз икән соң без аны? Кайсы яктан? Кириллицада басылган китаплар рәвешендәме? Шактый вакыт укыячакбыз әле без аларны, Рафис туган. Әйдә, икәүләп шул мирасны ачыклап китик булмаса. Син дә сүрелә төшәрсең, мин дә канәгатьләнермен. Мирас дип Советлар Берлеге чорында язылган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен, марксизм-ленинизм теориясен яки үзебезгә якынрак торганын, "бишле"ләр ала-ала укыганятлаган партия – совет матбугаты теориясе һәм практикасы дигән нәрсәне әйтәсеңдер, бәлки. Киләчәккә димим, боларның бүгенге яшәешебезгә дә бер тиенлек кирәге юк. Инде килеп, язучыларыбызның китаплары турында сүз кузгала икән, безнең өчен бердәнбер уңайсызлык шул дип исәплим, аларны беренче мөмкинлек чыгу белән кабат бастырырга кирәк булачак, әлбәттә. Муенга һич тә элмәк салырга кирәкми икән ич, Рафис!

Мәкаләңдә статистик саннар белән күп уйныйсың. Яңалифкә аларның ни катнашы бар соң? Этрус, иероглиф, рун язмаларын телгә аласың – мин үзем боларын мәгърифәтлегеңне күрсәтү алымы дип кенә саныйм. "Шөкер, СССР территориясендәге барлык төрки халыклар да кириллица нигезендә үз алфавитларын булдыра ул елларда", – диюеңне, моңа шөкерана кылуыңны һич тә аңлый алмыйм. Нидер өстәп сүз әйтәсем дә килми, шуннан үзең аңла инде. Яңалифкә күчүнең зарурлыгын раслаган бер урында профессор Вахит Хаковның латин графикасында уку һәм язу үрнәкләре китабына карата әйтелгән тозсыз һәм мәгънәсез сүзләрең авторны гына түгел, минe дә рәнҗетте.

Менә, ниһаять, әйтәсемне әйтеп бетердем бугай. Кемнәндер өстен чыгу, белдекле булып кылану өчен түгел. Һич юк! Хәзер без кыл өстендә басып торабыз. Уңга-сулга сугылу – әйе, аныбсын муеныңа элмәк салу диярго мөмкин. Җиде генә түгел, җитмеш җиде кат үлчәнде ләбаса яңалиф мәсьәләсе. Ул безнең милләтебезне, телебезне саклап калачак, мөстәкыйльлегебезне ныгытачак, аның киләчәк юлын билгеләячәк. Халыкара орбитага нәкъ менә шушы юл белән ансатрак кереп китәрбез, дип беләм.

"Һаман яратам!" дип яши алар...

1963 елда булса кирәк, Никита Хрущев "космонавтлар гаиләсе"н тудырган иде. Андриан Николаев белән Валентина Терешкованы өйләнештереп, ул бөтен дөньяга әйтергә теләде: менә, күрдегезме, бездә космонавтлар гына түгел, хәтта космонавтлар гаиләсе дә бар, галәмгә без беренче булып очтык, беренче булып калачакбыз.

Илнең иң зур җитәкчесе өмере белән үткән бу туйны халык дөрес аңлады: кемдер – Андриан Николаевны, кемдер – Валентина Терешкованы, ә кемнәрдер аларның элек яратышып йөргән ярларын кызганды...

Ә без менә, һич тә шикләнмичә, әйтә алабыз: бездә "югарыдагылар өмере" буенча түгел, ә бәлки чын күңелдән яратып өйләнешкән-кавышкан, иҗат гаиләсе корган парлар бар. Әнә шундый музыкаль гаиләне коручыларның берсе – танылган җырчыбыз Рабига Сибгатуллина һәм дә танылган баянчы, композитор Фәрит Хатыйпов. Әле яңа ел алдыннан гына алар яңа бер туй – улларының туен үткәрделәр. Ә менә быел гыйнвар аенда Фәрит Хатыйпов та, Рабига Сибгатуллина да түгәрәк бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр. Бу матур гаилә турында, аларның иҗатлары турында гәзитебезнең алдагы саннарында укырсыз. Ә хәзергә "Һаман яратам", "Синең нурың", "Тәрәзәңдә утың бар" кебек популяр җырларның авторы Фәрит Хатыйповның яңа бер җырын тәкъдим итәбез.

● *Рабига Сибгатуллина җырлый. Баянда – Фәрит Хатыйпов.*

Туган тел турында

Фәрит ХАТЫЙПОВ көе | **Нияз АКМАЛ** шигыре

Туган телдә һәрбер хисне
Җөмләгә төреп була.
Әйтергә теләгәнеңне
Әйтеп бетереп була.

Туган телдә тик бер хисне
Җөмләгә төреп булмый:
Аны ничек яратканны
Әйтеп бетереп булмый...,



ТАМАША ЗАППАРЫ ЧАКЫРА

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры
9 гыйнвар – "Кылый Кирам балдагы" (Аманулла).
10 гыйнвар – "Әлепле әртисләре" (Аманулла).
11 гыйнвар (көндез) – "Хушыгыз!" (Т.Миңнуллин).
11 гыйнвар (кич) – "Әлдермештән Әлмәндәр" (Т.Миңнуллин).
12 гыйнвар – "Гөргөри кияүләре" (Т.Миңнуллин).
13 гыйнвар – "Җүләрләр йорты" (З.Хәким).
14 гыйнвар – "Илгизәр + Вера" (Т.Миңнуллин).
15 гыйнвар – "Йөрәк маем" (Т.Миңнуллин).
16 гыйнвар – "Идегәй" (Ю.Сафиуллин).

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры
9-16 гыйнвар – "Гайфи бабай, өйлән давай!!!" (Г.Зәйнашева), Пермьдә гастрольләр.
16 гыйнвар – "Сынган беләзек" (Р.Сәгъди).

"Казан" милли мәдәният үзәге
9-11 гыйнвар – гимназия, мәктәп укучылары өчен Чыршы бәйрәме.

Курчак театры
9-11 гыйнвар – балалар өчен Яңа ел тамашасы.

Цирк
9-16 гыйнвар – Мәскәү циркы артистлары тамашасы.

Зур концерт залы
10 гыйнвар – Вокаль музыка кичәсе. 2 нче абонемент. Композитор Н.Җиһановның вокаль һәм инструменталь иҗаты. Башкаралар Р.Маликов, Л.Маслова, Г.Ибушев, И.Сафин, С.Кадыйрова, Н.Сәгыйрова. Концертны Л.Апакова алып бара.
17 гыйнвар – Татарстан Дәүләт симфоник оркестры концерты. Программада: Г.Свеиридов, К.Вебер, Дж.Гершвин, К.Сен-Санс әсәрләре. Солистлар – Л.Тимофеева (Франция), М.Бурдонкль (Франция). Дирижер Ф.Мансуров.

Фәнзаман БАТТАЛ

БЕРЕНЧЕ

(Дәвамы. Башы 1 нче санда).

* * *

Космоска старт алдыннан Гагарин "поехали!" дип кычкырган. Ә Саттарның тыны да чыкмады: корабка килеп керүгә үк кранлы мичкәгә чылбыр белән бәйләнгән әлүмин кружканы аракы белән тутырды, аны төбенә кадәр эчеп бетергәч, себеркесенә уралган ике чакрымлы сүс бауга башын салып, йокыга китте. Старт кнопкасына басарга тиешле академик, корабның сыңар иллюминаторына ничәмә-ничә мәртәбә тилмереп күз салса да, "смирно" басып торган себеркедән һәм аңа кигереп куелган куян бүректән гайре нәрсә күрмәде. Артыннан ут көлтәсе ургытып, Җир шарын дер селкетеп, кораб чиксезлеккә ыргылды...

Кабат бер сәгатьтән бөтен дөнья астрономнарының, галәм белгечләренең карашы йолдызларга, дөресрәге, шул йолдызлар арасында йөзә башлаган Русия корабына төбәлгән иде. Миллион мәртәбә якынайта торган телескоплардан караганда Саттар утырган кораб абзар артындагы сыман якын. Хәтта иллюминатор тәрәзәсенә очлы тимер белән сыдырып язылган өч һәм биш хәрефле сүзләр дә уч төбендәгедәй ачык күренә. Кораб тапшырачак сигнал-тавышларны тоту өчен әзерләп куелган куәтле рацияләр дә, кем әйтмешли, колакларын торгызган: кораб эчендә чебен очкан тавыш та ишетеләчәк!

Ниһаять, старт бирелгәннән соң сигез сәгать үтүгә, гырлаган, мыгырданган тавышлар килә башлады, аннары зур авызлы, кыска көпшәле туптан аткан сыманрак берничә гөпелдәү яңгырады, бераздан чыпырдап сыеклык аккан тавыш ишетелде. Монысын инде бөтен дөнья аңлады: Саттар, йокыдан торып, баш төзәтү хәстәрен күрә!..

Цивилизацияле илләрдә шушы тавышларның язмасын эфирга чыгаргач, шаркылдап көлүдән планета тетрәп торды. Ләкин көлүне курку, шомланып калу алыштырды – кинәт кенә Ай тотылгандай булды, дөньяга дөм караңгылык иңде, көндезге унда шәһәр урамнарында утлар кабызылды, күпләр, саташып китеп, йокларга яттылар. Бары тик телескопларыннан бер мизгелгә дә аерылмаган астрономнар өчен генә бу караңгылыкның сере якты иде – үзе утырган корабны "Мир" станциясенә тоташтырып өлгергән Саттар, ачык космоска да чыккан һәм себеркесе белән "ут өертә" башлаган иде. Әнә, скафандрының мунча плафонына охшаган пыяла башлыгы эчендә ачулы карашы елтырый, калын кара кашлары бер җыерылып, бер тирбәлеп куя, ә үзе, Минзәлә урамнарын иңләп баргандагы дәрт һәм кодрәт белән бәбәй итәктәй киң себеркесен селтәп-селтәп җибәрә – галәм киңлекләренә кара тузан күтәрелә, моңа кадәр тыныч кына Җир шары тирәсендә әйләнеп йөргән спутниклар, эт, куян, маймыл, селедка скелетлары төрле якка чәчрәп-чәчрәп оча. Шулай да татар космонавтының кәефсезлеге дә сизелеп тора: үз шәһәрен тавышсыз-тынсыз җыештырып яшәгән Саттар селтәнгән саен диярлек сүгенеп җибәрә:

– Һый, яптырррмалахайларррр, космоссс, имешшш!.. Пычрата белгәч, җыештыра да беләләр аны, ашаган табагына азай иткән дуңгызлар. Эх, анагызны!.. Космоска беренче булып менгәннәр, имеш. Иң элек тәһарәт алырга өйрәнергә иде, гүрегездә чучка үкергере нәмәрсәләр!..

Очып килүче лифчик белән арыш капчыгыдай киң ыштанны өлеге җәтмәгә ташлаганда йөзенә җирәнү галәмәте чыкты:

– Ач-ялангач йөрмәдең, ир рәхәте дә күрмәдең, ялгызлыкта җаның чыккыры! Карале син аны, космоска менеп, ыштан чәчеп йөргән бит, йөзе кара булгыры!..

Скафандр эченә тегелгән микрофоннан җирдәге махсус радиостанцияләргә шул ук мизгелдә барып җитүче тавыш галәм белгечләрен аптырашта калдырды. Янәсе: "Ниндидер информацияләр сөйли бу, әмма аңлау мөмкин түгел". Дөньяның төрле почмакларыннан Казанга телеграммалар ява: "SOS! Тиз генә татарча һәм инглизчә белүче тәрҗемәчеләр җибәрегез! Һәр җөмлә өчен минималь хезмәт хакыгызны түлибез".

Ә инде Русиянең космос үзәгеннән таләпләр, куркытулар агыла Саттарның колагына:

– Чо ты там калякаешь, гололобый?! Говори по-человечески! Иначе, там подохнешь, учти!

"Выжжжт!.. выжжжт!.." ишетелеп торган себерке тавышына кушылып, Саттарның тавышы яңгырый:

– Нәрсә, безнең телне өйрәнергә запрет бар идеме әллә?! Безнең мигә ике тел дә сыя, сезнекенә сыймыймыни? Миңгерәүләр, ыштули?! Миңа үз телемдә генә эндәшмисез икән, җавап бирдем булмаячак. Мин – татар космонавты!..

Дистәдән артык спутникны гектарлы җәтмә төбенә аткаргач, Саттар сабыйларча көлеп җибәрде, үзе дә сизмәстән, исендә калган шигырьне укып куйды: "Микикики! Микикики! Капчыктагы бүре башы бит уники!.."

Эчендә сөенеч кебегрәк нәрсә дә кытыкланып куйды. Ярый әле, иренмәгәнмен, дүрт классны бетерергә түземлек тапканмын, өченчедән соң ук ташлаган булсам мәктәпне, бу шигырьне белми калган булыр идем, дип, нәтиҗә ясарга да өлгерде. Ә себеркесе бер мизгелгә дә туктамый, галәмне иңләп-буйлап тузан пырхылдата, шул тузан Җир белән Кояш арасына эленгән кара юрган сыман бик озак таралмый тора. Хикмәт икән монда – җил юк икән!..

Хәлдән таеп станциягә кайтып кергәч, себеркесен әледән-әле ватылуы белән үзенә кадәр очкан космонавтларның теңкәсенә тигән көмпүтергә сөяде дә, телогрейкасын шул көмпүтернең монитор экранына элеп куйды. Үзенә төбәлгән фотоаппарат кебек нәрсәнең объективына куян бүреген кигерде. Минут та үтмәгәндер, стенадагы репродуктордан тавыш яңгырады. Монысы татарча иде инде! Ниндидер кыз эндәшә:

– Саттар әфәнде, мондагылар зарланалар, нишләгәне күренми башлады, диләр. Бүрегегезне телекамерадан алсагыз иде...

– Барысын да күрми торсыннар әле, сеңелем. Космонавтның... теге ... ни... тышка чыгып утырган чагы, дип әйт. Татарларда бөтен нәрсәне дә күрсәтеп бетерергә ярамый, шәригать кушмый, диң... Тамак та ялгап аласы бар әле...

Шуның хаклыгына шик калдырмаска теләгәндәй, Саттар мичкә кранын ачты, тагын бер кружка аракы агызды һәм, бөтен дөньяга ишеттереп, голт-голт итеп эчеп җибәрде:

– Әх, идрит-күдрит, шәп тә инде Минзәлә аракысы!..

* * *

Ярый, Саттар галәмдә оча торсын, ә бу кыйссаның авторы Җиргә төшсен,мондагы хәлләргә күз-колак булсын...

Саттарның галәмгә очуына өч атнадан артык вакыт үткәч, дөньядагы аракы заводларының хуҗалары – күп миллиардлар туплаган капиталистлар баш вата башлаган: кешене шул гомер буена бер лыкма ризыксыз яшәтә, тәүлегенә унбиш-уналты сәгать эшләтә ала торган Минзәлә аракысының хикмәте нәрсәдә? Бары тик үзләре генә белә торган матдәләр кушалармы әллә? Шулай булгач, янәсе, ни өчен бу көнгә кадәр информация кермәгән? Бәлки, алар файдаланган су бик тә үзенчәлекледер? Бик ашыгыч рәвештә бу аракының рецептын сатып алырга кирәк, алай барып чыкмый икән, шпионнар җибәрү дә гөнаһ булмас. Инде дә!..Әйе-әйе, инде дә серенә берничек тә керәп булмаса, ике дә уйлап тормастан, шартлатырга туры килер. Чөнки кайдадыр мондый конкурент бар икән, беттек, бөлдек, дигән сүз...

Ике йөз илдәге меңнәрчә аракы заводларыннан теге яки бу хәйлә белән шпионнар килеп төшкәч, Минзәләнең унбиш мең кешелек халкы бер атна эчендә миллионга җитте. Башчирек та кунакханәдәге бүлмәләрнең җидесенә дә сәндерәләр ясаттылар, тора-бара аскы катлардагы тулай тораклардан студентларны куып чыгарып, андагы бүлмәләрне дә кунакханәгә куштылар. Кайберләрендә люкс шарты да тудырмакчы булдылар әле... Ә монда гади номерны люкска әйләндерүнең мәшәкате зур түгел: өстәлдәге сырлы стаканны рюмкага алыштырдыңмы, теләсә кайсы бүлмә люкс була да куя! Аннан соң инде рәхим ит – бәяне ике мәртәбә артыграк түлә!.. Мондый чакта линиягә тоташмаган телефон, җимерек унитаз, янган телевизор, бүлкәләре ватылган тәрәзәләр, обойлары салынып төшкән стеналар исәпкә керми.

Алданрак килеп өлгергән шпионнар үзләрен бик бәхетле тойдылар: ни дисәң дә түбәдән яңгыр үтми! Шул бүлмәләр өчен конкуренция көчәйгән саен, Минзәләнең зирәк хакимияте кунакханәдә яшәүне тәүлекләп, сәгатьләп кенә түгел, минутлап санау тәртибен кертте.

Торасың килә икән, минутына йөз долларны чыгар да сал – вәссәлам!

Фатирларга урнашкан илчеләр һәм шпионнар өчен дә бәянең иге-чиге күренми башлады. Иртән бер бәя булса, кичкә таба бишалты мәртәбә арта тора. Түләрлек хәлең юк икән – алдыңнан артың хәерлерәк, капиталист абзый! Чит илдән килгән халыкның бер өлеше хәйләле юл сайламакчы булды: кыр-болыннарда, урманнарда төн үткәрүне мәслихәт санады. Ләкин боларның да эзенә тиз төштеләр. Минзәлә җирендә йоклыйсың килә икән, буржуй иптәш, һәр квадрат метр өчен бер пачка долларыңны чыгарып сөйләш! Рубльләреңне шәһәр чүплегенә чыгарып түк. Шулай итмисең икән, районны чүпләвең, пычратуың өчен башың штрафтан чыкмас.

Шулай итеп, Саттарның галәм себерергә китүенә ике ай дигәндә, песи төчкергә хәтле хезмәт хакларын да айлар буе ала алмыйча җәфа чиккән Минзәлә халкының һәркайсы капиталистка әйләнде. Урамнарга чыкмалы да түгел: рәт-рәт булып баручы "Мерседес"лар, "Джип"лар һәм "Линкольн"нарның чуты-хисабы юк. Хәтта моңа кадәр бәдрәфтәй алачыкларда, куышларда торып интеккән алкашлар да икешәр-өчәр катлы коттеджлар сала башладылар. Долларлар ташкынын кая куярга белмәгән хакимият башлыгы Мәскәүнекеннән дә зуррак, затлырак Кремль проектына заказ бирде. Тиз арада Минзәлә елгасының яр читләренә мәрмәрдән тротуарлар салуны кирәк таптылар. Аэропортны яңартып, Вашингтон, Париж, Рио-де-Жанейро, Токио, Багдад шәһәрләренә очу өчен дистәләрчә "Боинг" самолетлары сатып алдылар. Әллә нинди президентлар, корольләр явып кына тора хәзер Минзәләгә! Шуларның барысына да почетлы каравыл оештырмый булмый бит әле... Почетлы икән, димәк, милиционерлар да затлы күренергә тиеш! Һәркайсына алтын погоннар тактылар, кичәге сержантлар, лейтенантлар ким дигәндә майор яки полковник булды, генераллар взводы төзелде, милиция начальнигы, район хакимияте башлыгының махсус указы белән, милиция маршалы дәрәҗәсенә күтәрелде.

Шуннан соң кайбер күңелсезлекләр дә туа башлады Минзәлә районы башкаласында. Икенче көнне үк милиция башлыгына Мәскәүдән эчке эшләр министры шылтырата: янәсе, хәлләрең ни хәл, полковник? Ә мондагы тавыш горур яңгырый:

– Сортыңны белеп сөйләш, генерал! Маршал белән сөйләшкәнеңне онытма! Миңа шалтыратканчы тәһарәт алдыңмы, смирно бастыңмы?

Тегесенең башка сүз әйтерлек чарасы калмый – авызы кибә һәм, коты алынып, трубканы куя. Әмма шул атнада ук аракы заводы директоры эзсез югалып тора. Моны милиция киемендәге ниндидер бандитлар, Мияш урманына алып китеп, өч тәүлек буе җәзалаганнар:

– Чит ил магнатлары белеп өлгергәнче, аракыңның рецептын безгә бир! Мәскәү файдасына сатачакбыз. Ату, сез монда баеп ятканда, Русия дөнья дәүләтләреннән вак-төяк акча теләнеп сансызлана. Рецепт безнең кулга керми икән, матри, кояш белән саубуллашырга туры килмәгәе!

Әллә сер итеп саклана торган рецепт бөтенләй булмаган, әллә директор гадәттән тыш чыдамлык күрсәткән, гел бер сүзне кабатлап торган:

– Юк андый нәрсә, юк! Юк!! Юк!!!

Итәк астыннан гына йөргән хәбәрләргә караганда, аны Американың ЦРУы коткарган. Мәскәү генералы, егермеләп милиционеры юк ителсә дә, артын кыскан – бу вакыйгада катнашу фактын яшерү өчен, шым булуны мәгъкуль күргән: "Ул бандитлар безнеке түгел, безнекеләр Чечняда", – дип акланган.

Илле дә мәгәр бу хәл Минзәлә кешеләрен сизгерлеккә дә өйрәтте: аракы заводы директорына, генераль директор статусы биреп, аңа бер

полк тән сакчысы билгеләделәр.

Чит ил агентлары яшерен лабораторияләрдә Минзәләгә һәм аракы заводына килә торган суның составын тикшергәч, телсез калганнар: бу су микроблардан, бактерияләрдән һәм вируслардан гына тора икән, дигән нәтиҗәгә килгәннәр һәм, яшерен шифр белән, Америкага телеграмма җибәргәннәр: "Безнең фикеребезчә өтер Минзәлә аракысының туклыклы булуы өтер кешеләрдә хезмәт сәләтен саклавы нәкъ менә шул бихисап паразитлар аркасында булырга тиеш нокта Алар сыек ит формасына керәләр өтер кеше организмын туклыклы матдәләр белән тәэмин итеп торалар".

Форсатны кулдан ычкындырмаска күнеккән чит ил магнатларыннан бихисап үтенечләр ява башлый. Һәркайсы Ык суының сатылуына, махсус килешүләр төзүгә өмет баглый. Алардан җибәрелгән вәкилләр, үз илләренең Ык суыннан өлешсез калуыннан котлары очып, Минзәлә башлыгына яңа тәкъдим кертәләр:

– Суны аукционда сату сезгә дә, безгә дә файдалы булачак. Шушы ысул белән халыкара гаделлек принципларын сангa суксагыз, бөтен илләр Татарстан суверенлыгын бердәм танырга әзер торалар. Инде дә телисез икән, Минзәлә республикасы игълан итегез. Аны да, халыкара хокукый дәүләт итеп, Берләшкән Милләтләр Оешмасы составына кертүне хуплаячакбыз. Тарихыгыз да моның өчен уңай шартларны күрсәтеп тора. Сездә, мәсәлән, элекке заманда "Минзәлә иле" исемле гәҗит чыккан. Димәк, Минзәлә дигән дәүләт тә булган!

ТАТАРНЫҢ сәяхәте

(Алдагы гасыр хикәясе)

Беренче аукционга нибары бер кубометр су куелды. Чүкеч белән сугып, башлангыч бәясен әйттеләр:

– Илле доллар!

Чит ил эшмәкәрләре үз бәяләрен кычкырырга ашыктылар:

– Алтмыш!

– Без туксанга алабыз!

– Йөз!

– Йөз егерме!..

Бәя дүрт йөз долларда туктап калды. "Ничауа, монысы да ярый, – дип нәтиҗә ясады хакимият әһелләре. – Миллион кубометр гына сатсак та, җан башына кимендә ун мең доллар өстәләчәк". Ләкин сәүдә әлеге миллион кубометрны сатуга ук туктап калды. Чөнки дөнья галимнәре яңа версия күтәреп чыктылар: "Хикмәт суда түгел! Андагыдан да күбрәк паразитлар тупланган су чыганаклары Африканың кыргый кабиләләре яши торган якларда да табылган. Хикмәт Минзәләнең ашлыгында булырга тиеш!"

Су белән авызлары пешкән дөнья вәкилләре бу юлы сагаебрак эш иттеләр. Минзәләлеләр күпме генә: "Ашлык бит ул су гына түгел! Арышы да, бодае да маңгай тире түгеп үстерелә аның!" – дип авыз суы корытмасыннар, әлләни файда чыкмады, райондагы бөтен ашлыкны җыеп, тоннасын нибары ун мең доллардан җибәрергә мәҗбүр булдылар. Сатылган йөз мең тонна урынына Актаныш, Сарман, Мөслим якларыннан яңа ашлык кайтарттылар. Алардагы ашлык 66 мәртәбә арзанрак булганлыктан, район казнасы зур отыш ясады. Әмма яңа мәшәкать туды. Банк директорының әйтүенә караганда, тупланган долларларны куярга урын калмаган. Гаражлар, утын сарайлары шыгрым тулган яшел валюта белән, ишек алдына да берничә чүмәлә өеп, брезент белән капларга мәҗбүр булганнар. Шуңа күрә, бик тә ашыгыч рәвештә, яңа банк төзергә кирәк икән!

Сәвит чорындагы гадәт буенча өмә оештырып, Минзәлә халкы банктагы долларларны ашлык кабул итү пунктының складларына ташыды. Өмәдә катнашкан ун мең кешенең фидакарьләрчә эшләве нәтиҗәсендә, егерме мең тонна долларны әлеге складларга күчерү өчен ике көн вакыт җитте. Ә инде иске банкны Саттарга бау ишкән, җәтмә үргән сукырлар җәмгыятенә касса итеп бирделәр.

* * *

Космос тизлек ярата.

Космоста һәр нәрсә бездәгедән йөз мәртәбә кызурак хәрәкәт итә.

Менә шуңа күрә космос турында язучылар да каләмнәрен тизрәк уйнатырга, битләп-битләп язардай вакыйгаларны да бер-ике җөмләгә сыйдырып куярга, кайбер хәлләрне, әле генә күргәнегезчә, санап кына, әйтеп кенә үтәргә мәҗбүрләр. Язу өстәлең янында йокымсырап утырасың икән, потың бер тиен – соңга калдың дигән сүз.

Менә мин дә, Минзәләдәге хәлләр белән мавыгып китеп, галәмдәге Саттардан аерылып тордым. Обсерваториягә бу юлы да атнадан артык вакыт үткәч кенә бардым. Ә ан-да-а-а!.. Ә анда, ягъни галәмдә, урыс әйтмешли, кошмар! Бер очы – "Мир" станциясенең койрыгына, икенче очы бил каешына бәйләнгән бауны йә беләгенә урый-урый, йә сүтә-сүтә, әлеге гектарлы җәтмәгә космостагы үтилләрне – берсеннән берсе зуррак, иләмсезрәк спутникларны, корабларны, ракеталарны сөйрәп китерә тора Саттар. Монтый чакларда ул кабартылган каз куыгын яки футбол тубын япа-ялгыз тартып баручы кырмысканы хәтерләтә. Еш кына болай да итә: кайсыдыр ракетага менеп атлана да, себеркесен ишкәктәй тотып, әле – бер, әле икенче якка күчерә-күчерә, галәм океанын ишә башлый. Кайчак җырлап та җибәрә:

Менәмен дә утырамын
"Восток"ның билләренә.
Көн дә тормый кайтыр идем
Сөекле илләремә.
Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Гандәли.
Туган илдә дөнья матур -
Бер минуты әлләни.

Әйтеп торуның да кирәге юктыр, Саттарның галәмдәге эшләре белән таныштырган мизгелләрдә, Русия телевидениесе аны телсез итеп күрсәтә – тавышын ишеттерми һәм, бер карaганда, дөрес тә эшли. Мәсәлән, аның җырындагы Гандәли – Саттар эшли торган йортлар идарәсендә подъездлар юып йөрүче хатын. Үзе генә ишетсә, бик шат булыр иде дә бит галәмнән килгән җырга!.. Әмма иренең дә ишетүе, Саттар белән Гандәли арасындагы яшерен хәлләрне белүе мөмкин. Чөнки Минзәлә ирләре дә, җир йөзендәге бөтен ирләр кебек үк, чит хатыннар янына йөрергә яратсалар да, үз хатыннарының бүтән мыекбайлар куенында ятуын күз алдына да китерергә теләмиләр.

Билгеле инде, Русия телевидениесендә ул серләрне белмиләр, җырның хикмәтен дә аңламыйлар, "татарин опять что-то каля-баля кричит", дип кенә көләләр. Аларның төп максаты бер генә: урыс илен татар җыры, татар сүзе сасытмасын!..

Әлеге дә баягы, Саттарның урысчалатып, кырык катлы итеп сүгенәчәген дә истән чыгармыйлар космос белән тоташкан астрономнар. Менә бу юлы да, җырын түгәрәкләп бетермәстән, бөтен галәм тетрәрлек итеп сүгенә башлады космонавт. Ник дигәндә, каршысына адашкан ракеталарның чираттагысы килеп чыкты.

– Һу, иманыгызны!.. Халыклары эттән ач, беттән ялангач заманда галәмгә тимер-томыр ыргытып, байлык туздырып уйнаганнар бит. "Восток", имеш, "Восход", имеш!.. Кояшыгыз батты бит инде, абзыкайлар! Монысы нинди "Союз" тагын?! Һә-һә, анысы да җимерелде ләбаса "Мир"лар ясый-ясый сугышып яшәгән гомерләрегездә. Ач кешеләрегезнең тамагын туйдырырга кирәк иде башта. Авызларын ачсалар, күтләре күренә бит инде!..

Биленә кыстырылган шешәсен алып, мөшкәсеннән генә берничә мәртәбә күз яшедәй үтә күренмәле сыеклык йоткач, шаркылдап көлде дә, тутык ашап бетергән "Восток"ка әле яңа гына килеп җиткән черек "Восход"ны себеркесе белән тартып китерде. Аны койрыкка тагып куюы булды, икесен дә җәтмәгә таба юнәлтте.

Укучы ничек уйлый торгандыр, мин үзем аның сүгенүләрен дә, җырлап, сөйләнеп йөрүләрен дә гаепләмим. Аның күңелен аңлау өчен үзеңнең дә иксез-чиксез галәмдә япа-ялгыз йөреп каравың кирәктер...

* * *

... Минзәлә заводы аракысының бәясе космик тизлек белән арта башлагач, мондагы төзелешләрнең колачы адәм ышанмаслык төс алды.

Кремль инде әзер диярлек. Аның ишек алдына тугыз гөмбәзле, ике йөз метр биеклектәге чиркәүне алтын белән тышлау эшләре дә тәгәлләнеп бара. Татарларның да хәтере калмасын, дип, авылларның берсеннән мунча бурасы сатып алып кайттылар. Анысын мәчет итмәкчеләр. Инде өстенә куелачак калай манарасы да әзер икән. Кремль капкасын чыктыңмы, үз күзләреңә үзең ышанмыйсың: түбәләре болытка чумган биек йортлар, банк биналары, патша сараедай рестораннар, меңәр-меңәр бүлмәле кунакханәләр тезелеп тора. Хәтта гасыр башында ярминкәгә килеп йөргән чит ил сәүдәгәрләре өчен эшләп торган Камали бардагы урынына, заманча итеп, әр-яңа "кети-мети" йорты да салырга онытмаганнар. Элекке ике катлы бина урынына йөз дә ике катлы итеп салынган бу бинаны да алтынга төргәннәр, Мәскәү якларыннан бер эшелон кыз алып кайтып, "изге эшкә" җиккәннәр.

Ак, кызыл, кара мәрмәр җәйгән киң проспектларны шампунь белән юа торган техника кайтартканнар. Әйтергә онытып торам икән, хәтта унбиш ел буе ремонтка ябылган Минзәлә дәүләт драма театрын да, төзәтеп бетереп, кабат ачу тантанасы үткәргәннәр... Казанга барып кайтучылар, Казан турында сүз чыккан саен, борын җыерып, чырайларын сыталар. Янәсе, искә төшереп торма әле шуны.

Кыскасы, "Минзәлә кешесе!" дигән сүз һәркайда горур яңгырый. Әфтәритләренең чамасы юк. Кайсы гына калага барып чыксалар да: "Мин Саттар Гаттаров шәһәреннән!" – дип кенә җиффәрәләр. Шул сүзне әйтүләре була, оркестрлар уйный башлый, ачылмас ишекләр ачыла, табыннар әзерләнә. Хәтта Минзәләнең бетле күзле бичлары һәм бомжлары да Чаллы, Түбән Кама мэрларының түрендә, күкрәк киереп, коньяк, ром, виски чөмерә...

Шәһәргә читтән килеп, архитектор булып эшли башлаган бер адәм әр-яңа фикер күтәреп чыккан – шәһәр уртасына Саттар Гаттаров һәйкәлен салырга кирәк, дип, шундагы гәзиткә дә язып өлгергән. "Ул һәйкәлне төзү өчен шәһәребезгә Саттар Гаттаров аркасында кергән байлыкның миллионнан бер өлеше дә китмәячәк", дип исбатлаган. Бу мәкалә үз ягында туып-үскән олы шәхесләрен хөрмәт итә белмәүче Минзәлә халкында нәфрәт тудырган. Барысы да митингка чыгып, әлеге архитекторны шәһәрдән кудыру актына кул куйганнар. Бары тик хакимият башлыгының Минзәлә кешесе булмавы аркасында гына үз сүзләрен гамәлгә ашыра алмаганнар. Башлык бу мәсьәләне хәл итү өчен тагын да арзанлырак, җиңелрәк вариант тапкан – иске хакимият бинасы каршында кукраеп торучы Ленин һәйкәлен үзгәртеп төзергә әмер биргән.

Архитекторлар һәм сынчылар ул әмерне көнендә үк гамәлгә дә ашырып куйдылар: Ленинның алга сузылган кулын өскә – галәм юнәлешенә каерып күтәрделәр дә, икенче кулына цементтан коелган себерке тоттырдылар. Әлбәттә инде, башын салдырып алып, әр-яңа баш та ялгадылар. Карашын күккә төбәгән Саттар Гаттаровны Минзәләнең бөтен алкашлары да танырлык булды. Алар, космонавтның постамент тирәсенә бушаган шешәләрен китереп куеп, хөрмәт белдерделәр. Әмма баш төзәтерлек акча таба алмагач, үзләре үк җыеп алып, кабат савыт-саба ларегына илтеп тапшырдылар.

* * *

Саттар станциягә караңгы төшкәч кенә кайтып керде. Аягын сөйрәрлек тә хәле калмаган иде. Телогрейкасын җәйде дә идәнгә ауды. Хәтта "хәләл ризыгын" да яткан көе генә чөмерде. "Бетә, Аллага шөкер, эш бетә!" – дип сөенде ул, үзалдына елмаеп. Шунда ук шомланып та куйды: "Аракы да бетеп бара..."

Галәмдәге иске-москы хәзер корабка тагылган иске җәтмәдә инде!

Бары тик орбита буйлап әйләнүче меңнәрчә шешәләр генә калды. Юри ахырга калдырды ул аларны: кадерен белеп, төмен белеп җыю өчен! Их, менә шуларны аерым капчыкларга тутырып, Минзәләгә алып кайтсаң иде дә, шешәдәш дуслар белән илтеп тапшырсаң иде! Күпме аракы тиячәк бит аларга! Мүре! Ну, сөенер иде дуслар! Ул аракы беткәнче кулда гына йөртерләр иде Саттарны. Гандәли тозлы кыяр белән селедка ярата башлаган иде Саттар белән кавыша башлагач, – аңа да күчтәнәчлек калыр әле, бәлкем...

(Ахыры бар).



Танылган тәнкыйтьче һәм язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мансур Вәлигә 1 гыйнварда 50 яшь тулды. Ул унлап китап авторы. Бүгенге көндә "Казан утлары" журналы редакциясендә эшли. Без аны түгәрәк бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз, яңадан-яңа иҗат уңышларына ирешүен телибез. Бүген Мансур Вәли – безнең кунагыбыз.

Мансур ВӘЛИ:

Бездә хәзер бер-береңне иптәшләрчә төзәтү гамәле онытылып бара

– Мансур әфәнде, бүгенге татар әдәбиятындагы хәлләрне Сез кыскача гына ничек бәяләр идегез?

– Күз тимәсен: шигърият белән драматургиябез әйбәт кенә үсештә, публицистиканың матур-матур үрнәкләре күренгәләп тора. Әмма прозада һәм әдәби тәнкыйтьтә эшләр начар.

– Чынлап та, бүгенге прозадан бик күпләр зарлана. Ә менә шундый хәл килеп туының сәбәпләре нидә икән соң?

– 1997 ел дәвамында без "Казан утлары" журналында бүгенге проза турында сөйләшү үткәргән идек. Анда катнашучыларның һәм үземнең фикерне дә бергә кушып әйтсәк, мондый нәтиҗә килеп чыга: өлкән яшьтәге, тәҗрибәле прозаикларның дөнья куюы, исәннәренең бик-бик сирәк язуы, прозада каләм хакының бик-бик түбән булуы, һәм гомумән бүгенге тормышта рухи-әхлакый мәсьәләләргә игътибар бирелмәү... Менә бу соңгысы безнең бүгенге барлык проблемаларның үзәк тамырын тәшкил итә шикелле. Аны күрергә, аңа зур игътибар бирергә теләмәсәк, безнең әле алда тагын да зуррак фаҗигаләргә юлыгуыбыз мөмкин. Ачыграк итеп әйтсәк, адәмнәрнең торган саен көчлерәк темпта ерткычка әверелү процессы бара. Әгәр дә без үзебезнең республикада рухиятнең ни икәнен аңларга өйрәнмәсәк – тиз арада бик начар җимешләр җыя башлаячакбыз!

– Шул ук вакытта бүгенге әдәбиятта матур күренешләр дә бардыр ич инде...

– Әйе, хәзер безнең әдәбиятны, гәзит-журналларны чагыштырмача ирекле дияргә мөмкин. Ләкин барыбер иң-иң үткен мәкаләләр безнең хөкүмәттән акча алмаган басмаларда дөнья күрә. Ә хөкүмәт акчасына яшәгәннәре исә нигездә һаман элекке юлдан бара дияргә була.

– Ә менә әдәбиятның үзенә ирек нәрсә алып килде дип әйтергә була?

– Милли тойгыларны ачыктан-ачык язу мөмкинлеге бирелде. Монысын беләбез. Шәхес ирегенә дә юл ачылды дип әйтергә була... Ләкин, шул ук вакытта, бу ирек белән безгә йөгәнсезлек тә кереп бара шикелле. Бигрәк тә яшь буын прозаиклар иҗатында күзгә ташлана ул. Нәрсә турында әйтмәкче булам мин? Әдәбиятта теләсәң нәрсә турында язарга мөмкин. Әмма иҗатчының кешелекле, гуманлы максаты булырга тиеш. Тормышның шәрә яисә пычрак яклары турында язу үзмаксат булмаска тиеш! Ә безнең беришне яшьләр иҗатында кайчагында ул үзмаксат сыман килеп чыга. Ягъни алар бары тик әнә шул "әкәмәт нәрсә"не күрсәтеп, шуннан тәм табу өчен генә язалар кебек.

– Моңа мисаллар китермисезме?

– Үзебезнең әдәбияттан мисал китереп тормыйм. Анысы аның гыйбрәт булыр иде инде. Ә менә башка әдәбиятлардан, үрнәк алу өчен, мисал китерергә мөмкин. Француз әдәбиятында Мопассан бар, урыс әдәбиятында Бунин бар. Алар мәхәббәт турында күп язалар һәм шактый мавыктыргыч, дулкынландыргыч итеп язалар. Шактый ачык, курыкмыйча язалар. Ләкин алар иҗатында мәхәббәт күренешләре кеше язмышлары һәм кичерешләре белән тыгыз үрелеп бара, әнә шул язмышларның бер органик өлеше булып бара. Ир белән хатын-кыз якынлыгы тасвирланса да, тулаем әсәр тукымасында ул иң алгы планга чыкмый, төп максатка әверелми. Аларда тормышны тирәннән кичереп баручы олы иҗатчы йөрәге, күнеле һәр җөмләдә сизелеп тора... Ә безнең яшь иҗатчылар исә язганда персонажларның күңеленә эчкәре кереп тормыйча, әлеге "кызыклы" күренешләрне генә алгы планга чыгарырга яраталар.

– "Замана балалары" дип карап, аларга карата әдәби тәнкыйть тә сүз әйтми бит әле...

– Әйе, анысы да бар. Бездә хәзер бер-береңне иптәшләрчә төзәтү гамәле онытылып бара.

– Әдәби тәнкыйть дигәннән, безнең бу тармагыбыз нишләп бөтенләй юкка чыкты соң әле ул?

– Алай ук дип әйтмәс идем мин. Мәсәлән, язучыларыбызның төп журналы булган "Казан утлары"н гына алсак та, үткән ел дәвамында анда шактый күп һәм кызыклы гына әдәби тәнкыйть мәкаләләре дөнья күрде. Рифат Сверигин, Фәрит Бәширов, Кояш Тимбикова, Лена Шагыйрьҗан язмалары – алар, һич икеләнүсез әйтергә мөмкин, иң җитди таләпләргә дә җавап бирә ала торган әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Әле тагын Рафаил Сибатның шагыйрь Рәдиф Гаташ турындагы бик кызыклы һәм күләмле мәкаләсен әзерлибез.

– Шулай да, соңгы елларда әдәби тәнкыйтькә яңа кадрлар килми, ахрысы ... Сезнең сыман, башта ук күренекле язучы Фатих Хөснигә "Ачык хат" багышлап – әнә шулай истә калырдай итеп – әдәби тәнкыйтькә килүчеләр күренми бугай хәзер...

– Иҗатка һәркем үзенчә килә бит инде ул. Соңгы елларда безнең әдәби тәнкыйтькә килүче яңа кадрлар да бөтенләй үк юк дип әйтә алмыйбыздыр. Моңа кадәр публицистик мәкаләләр язган Рәфыйк Шәрәфиев бу елларда матур гына тәнкыйть мәкаләләре дә бирде. Аның бүгенге прозага багышланган һәм Мәгъсум Хуҗин иҗатын яктырткан язмалары бигрәк тә аерылып тора. Рәшит Фәтхерахманов дигән авторыбыз да Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты турында һәм тулаем иҗат процессы хакында кызыклы язмалар бастырды. Руфия Гыйләҗетдинова (хәзерге фамилиясе Хәмидуллина) да әдәби әсәрне бик белеп, бик җентекләп тикшерү сәләтенә ия.

– Ә менә әдәби тәнкыйтьне чын-чынлап җанландыру, Тукайлар-Әмирханнар чорындагыча итеп җанландыру өчен нәрсә эшләргә кирәк, сезнеңчә?

– Иң беренчедән, чын мәгънәсендә бәйсез басма булырга тиеш. Аның башында кыю һәм көчле рухи дөньяга ия зур шәхес торырга тиеш. Әнә шул шәхес кызыклы һәм кирәкле язмаларга авторны кызыксындыра алырдай каләм хакы түләргә тиеш. Ә хәзерге сыман, күләм буенча гына, механик рәвештә генә бүлеп утырырга түгел! Аннан соң бер үк санда яки янәшә килгән саннарда бер үк авторның язмаларын басудан курыкмаска кирәк. Әдәбият тарихыннан ук билгеле бит инде: талантлы автор ул еш яза, һәмдә мәсен кызыклы итеп яза. Без аңа юлны иркен итеп ачудан курыкмыйк. Югыйсә, кайсыбер басмалар моннан бик тә курка. Аның язмалары редакцияләрдә озак гомерләр ятарга мәҗбүр була. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләр өчен мондый хәл бигрәк тә сиздерә.

– Әллә әнә шуңа күрәме, үзегез дә соңгы арада прозага кереп барасыз?

– Бу мәсьәләдә әлегә нинди дә булса нәтиҗә ясый алмыйм. Ә сез әйткән новеллалар – алар күңелдә йөргән хисләрне, тойгыларны белдерәсе һәм ниндидер дәрәҗәдә яшәтеп калдырасы килүдәндер дип уйлыйм. Кайберәүләргә шигырь мәйданы гына таррак тоела да, алар прозага кереп китә бит әле... Аннары шагыйрьләрнең дә, прозаикларның да әдәби тәнкыйть мәкаләсе язулары кебек бик матур күренеш бар... Бу шулай булырга тиеш тә! Иҗат кешесе үз күңелен ни дулкынландырса – шул хакта рухланып язарга тиеш. Мисал өчен, талантлы шагыйребез Лена Шагыйрьҗанның тормыш проблемалары турындагы язмаларын да, әдәби иҗат хакындагы мәкаләләрен дә тыныч кына уку мөмкинмени?! Талантлы каләм иясенең уй-тойгылары бит алар! Гариф ага Ахунов, Туфан ага Миңнуллин һәм башка бик күпләрнең дә язмалары әнә шундый дип беләм. Бүтән каләм ияләре дә моннан курыкмаска тиеш дип саныйм. Укучыга әйтер сүзең, мәгънәле, гыйбрәтле фикерләрең бар икән – нигә аларны яшереп яткырырга?!

– Шулай итсәк, милли матбугатыбыз да җанланыбрак китәр иде бәлки. Шулай бит?

– Әлбәттә! Гомумән, әле бездә, безнең уйлау-фикерләү рәвешебездә коллык, катып калганлык билгеләре бик еш чагыла. Без үзебезнең җаныбыз, рухыбызны иркен һәм ирекле яшәешкә чыгарудан куркабыз. Элек озак еллар буена яшәгән кысалар хәзер безне рухи яктан богаулап, кысып тора. Хәзергә безнең цензура үзебездә, үз эчебездә, үз җаныбызда бик көчле утыра.

– Кысалар димәктән, тәрҗемә турында да сөйләшеп алыйк әле. Элегрәк, ягъни совет чорында, бездә бу мәсьәләгә зур әһәмият бирелә иде. Дистәләгән әсәрләр чит телләргә тәрҗемә кылына, басылып чыга иде. Дөнья әдәбиятын үзебезнең телгә тәрҗемә итү эше дә әйбәт кенә бара иде. Югыйсә, без бит укучыбызны үз казаныбызда гына кайнатырга тиеш түгел. Менә бу хәзерге, ирек заманасы, аны туктатып калдырды бит әле...

– Тәрҗемәче кешегә һәм бүтән күпләргә минем фикерем бик сәер тоелачагын да яхшы беләм, ләкин үз фикеремне әйтәм. Совет чорында чит телгә тәрҗемә кылынырга тырышучылар – алар нигездә татар халкы, татар укучылары тарафыннан бик үк якын кабул ителмәгән язучылар булды, дип уйлыйм. Алар үзләренең татар халкы күңеле, аның җаны белән бигүк якын түгеллеген, үзләренең аңа бигүк үз түгеллеген тоеп – милләт белән үзләре арасында чын рухи якынлык, чын-чыннан бер-береңне үз итү хисе булмауны тоеп – әнә шуның аркасында, шуның нәтиҗәсендә үзләренә җылы эзләп, игътибар эзләп читкә юл тоттылар, дип уйлыйм мин. Ә менә чын-чыннан татарның үзенеке булган, аның белән күңел, җан якынлыгы, язмыш уртаклыгы һәм үзенең шәхси язмышының татар милләте язмышы белән ахыргача уртаклыгын, аларның үзара аерылмаслыгын тойган әдипләр алай эшләмәде, дип саныйм. Мәсәлән, Әмирхан ага Еникиның, Нурихан ага Фәттахның, Мөхәммәт ага Мәһдиевнең һәм күпләгән милли җанлы, милли рухлы язучы, шагыйрьләрнең тәрҗемә ителүгә исе китмәде бит. Ни өчен? Чөнки алар татар халкын, татар милләтен үзенең Анасы дип санады! Ә Ана кеше ул, үзегез беләсез, берәү генә була!

– Алайса, без гомумән тәрҗемә эшен юкка чыгаруга, аны кирәксенмәүгә килеп терәләбез түгелме соң?!

– Алай ук түгелдер! Милләтнең иң зур, иң талантлы, иң чын әдипләре тәрҗемә ителсен. Лаеклы итеп, алар талантына тәңгәл дәрәҗәдә итеп. Мондый максатка безнең хөкүмәт, безнең Язучылар берлеге акча да тапсын! Ләкин мин тәрҗемә ителүне үзмаксат дип санауга каршы. Югыйсә, бездә кайберәүләр татарча язарга, иҗат итәргә өйрәнмәгән килеш "тәрҗемә итегез!" дип чаба башлаган иде бит. Шул ук Еникиләрне, Фәттахларны, Мәһдиләрне узып чаба башлаганнар иде алар!

– Кайберәүләр бүген тулаем әдәбиятның (милли әдәбиятның гына түгел) язмышын бик пессимистик рухта билгели. Ә сез моңа ничек карыйсыз?

– Мин үзем болай оптимист кеше. Киләчәкне гел матур итеп күрергә телим. Ләкин, шул ук вакытта, тулаем җир шарындагы тормышта начар тенденцияләрнең нык көчәя баруын күрәм, табигатьнең бөтен җирдә юк ителә баруын күрәм – адәм баласы үзенең бары тик табигать исән булганда гына яши алганлыгын оныта. Русия илендә кыргый көчләргә бигрәк тә нык ирек куела, табигатьне һәм кеше шәхесен җимерү эше бирелә бигрәк та кызу тизлектә алып барыла...

Менә шундый шартларда безгә Татарстанда гуманистик принципларга нигезләнгән үзебезнең идеологиябезне булдырырга бик кирәк иде дә бит... Ул була калса – бөтен зыялыларны, халыкны һәм җитәкчеләрне бер максатка туплый алыр иде. Тормышны төзергә, матурайтырга, ныгытырга ярдәм итәр иде. Бөтен республика өчен рухи нигез булыр иде ул. Иҗатчылар өчен бигрәк тә.

Әмма ни кызганыч: күпләр өчен идеология бары тик куркыныч нәрсә булып кына истә калган, ахрысы. Көнбатыш илләрендә андый әйбер – идеология – күренмәү дә шикләндерә ахрысы безнең җитәкчеләрне. Ә бит безнең халыклар – татары да, урысы да дигәндәй – кече яшьтән үк күңел, җан тәрбиясенә бик мохтаҗ. Хәтта әле олыгайгач та мохтаҗ аңа кеше! Чөнки ул – таш түгел, тимер түгел! Кеше бары тик акча законы белән генә яши алмый. Аның эчендә акчага гына буйсынмый торган "җан", "күңел" дигән изге хәзинә бар.

– 50 яшь тулган көннәрдә үзегезне ничегрәк хис итәсез?

– Ул турыда әллә ни уйлаган да юк. Һаман яшьләрчә булырга тырышып йөрим шунда...

Әңгәмәне **Саимә ИБРАҺИМОВА** үткәрде.

● Яшьтәшләр. Сулдан уңга – Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин һәм Мансур Вәли (70 нче еллар ахыры).



Батулла баганасы

Ялгызлык

Бер тапкыр Сара ханым Садыйк үз фатирында гәзит бөктәре белән бердәнбер чебенне куып йөри икән. Чебен суктырмый, кача, оча китә.

– Йөрмә көз җиткәч, бызылдап йөрмә! Үләргә вакыт сиңа да, миңа да. Бар, яшәгән гомереңә канәгать бул, денсез! – дип Сара ханым чебенне куа торгач, үзе өлсерәп беткән, ди. Шул вакыт чебен ачык тәрәзәдән очып чыгып китә.

– Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңел кошы, – дип, Сара ханым чебен артыннан карап кала. – Жәл, тагын ялгыз калдым! – дия дә янә пианино капкачын ача.

Остаз

1956 ел.

Зәй төбәгенең Бишавыл урта мәктәбендә Василий Андрей углы Зингаров атлы гаҗәеп истигъдадлы бер укытучы эшләгән.

Аны бөек математиклар, мөһәндисләр генә түгел, язучылар Батулла, Хәйдәр, Мөдәррис Әгъләмнәр, артист Николай Дунайлар да үзләренең остазы саныйлар.

Бишавыл мәктәбендә Әмирхан Еникинең "Саз чәчәге" әсәре буенча укучылар арасында (укытучылар катнашы белән, әлбәттә) фикер алышу уздыралар. Фикер алышудан соң укучылар дәресханәләргә тарала, укулар башлана. Укытучы Василий Зингаров 10 нчы сыйныфка килеп керә дә астрономия буенча дәрес башлап җибәрә:

– Мөнәвир Садыйк! – ди остаз. – Сөйлә, нәрсә беләсең син йолдызлар турында?

Мөнәвир тыныч кына торып баса.

– Василий Андреич, – ди ул. – Йолдызлар бит алар карап торганда барысы да бер. Аларны ничек аерып бетерәсең инде, күп бит алар.

– Бик дөрес әйтәсең, энем! – ди остаз. – Менә мин синең фикер алышудагы сөйләгәнеңне тыңлап утырдым. Син Алексей Толстой белән Лев Толстойны, Әмирхан Еники белән Фатих Әмирханны бутыйсың икән. Җирдәге йолдызларны бутаган кешегә күктәге йолдызларны аеру каян килсен инде! Утыр – ике-ле!

Кем алына?

Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гомәр Бәшир 1955 елда партиянең өлкә комитеты беренче секретаре Зиннәт Моратовка әйтә:

– Галимҗан Ибраһимовны аклау буенча эш башларга иде, – ди.

– Анысы синең эш түгел, – ди Моратов. – Син башларга тиеш түгел аны! Ибраһимовның хатыны, балалары, туганнары бардыр. Һич югында башка берәр ватандаш кеше башлап йөрергә тиеш!

Бәшир бу эшне Әмирхан Еникигә йөкли. Бик озак уйлаганнан соң Еники риза була һәм ҮКга һәм прокурорга гариза яза.

Озакламый Галимҗан Ибраһимов аклана.

Көлсәң – көл, көлмәсәң – ела!

Тату гына туктату
(фельетон урынына)

Йә, нишлибез, җәмәгать? Дәвам итәбезме? Әллә соң туктыйбызтукталабызмы? Тукталу, дигәннән, әнә, минем күрше Галәветдин туктаткан... Ул үзе ДАИда эшли, милиция сержанты. Туктатырга бөтен мөмкинлеге бар.

– Туктап тор! – дигән ул, кулындагы артыш таягын болгап. – Син нәрсә, агай-эне, җил сул яктан искәндә уңга борыласың?! Күзең чыкканмы әллә?! Штраф синнән, фәлән-фәсмәтән!..

Менә шулай итеп, Галәветдин машина хуҗасы Әлмиевтән "штраф" кысып калган. Ә Әлмиев, үзегез беләсез, бик тәртипле кеше. Эчми-тартмый, урлашмый-дәгъвалашмый, ул Казандагы иң югары уку йортларының берсендә профессор. Профессор булуына ышанмыйсыз икән, һич югында – фәннәр кандидаты.

Әлмиевнең, әлбәттә, Галәветдингә бик ачуы килде. "Ярар, карарбыз!.." – диде ул эченнән генә. Һәм карады да. Имтихан вакытында студентка әйтте: "Син нәрсә, фәлән-фәсмәтән, җил сул якка каерганда уң якка каерасың?!" – диде. Ни генә булмасын, студентның әтисе Көлиев фәннәр кандидатына "штраф" түләде. Студент шуннан соң гына әйбәт билге алды. Ә Көлиев, беләсегез килсә, атаклы ук булмаса да, шактый ук оста теш табибы иде. Менә шул теш табибы янына беркөн, ах-вах итеп, ДАИ хезмәткәре Галәветдин килеп керде. Юлда машина туктатып тора торгач, теше үтереп сызлый башлаган. "Кәнфитне күп ашагансың, ни, фәлән-фәсмәтән", – дип тиргәде аны Көлиев һәм...

...Галәветдиннән алган "штраф"ын кесәсенә салып куйды...

Галәветдин дә, Әлмиев тә, Көлиев тә сизми-белми калды: йә, әйтегез, кемнең кесәсенә кем "штраф" салды?..

Ә шулай да, нишлибез, туктатабызмы, әллә дәвам итәбезме?..

Нияз АКМАЛ.

Сала саен мең дә бер мәзәк

Кемнең җырлавы шәбрәк?

Моннан 20 ел элек Балык Бистәсе районына җирле радиога эшкә яшь журналист Нияз Акмалов кайта.

Яңа ел төнендә Балык Бистәсе җирле радио тапшырулар челтәреннән кемнеңдер сузып-сузып җырлаган тавышы ишетелә.

– Кара, безнең Акмаловның тавышы шәп икән! – ди район гәзите мөхәррире Харис Әшрәфҗанов, – Әллә "кәккән" инде җүнсез?..

Район милициясе начальнигы Илгиз Хәмидуллин әйтә:

– Тавышы шәп,ну-да ләкин туктатырга кирәк, – ди.Шуннан соң, милиция сержанты Ибраһим Надыршинга әмер бирә:

– Ибрай, бар, алып мен! – ди.

Ибрай нәрсә алып менәргә икәнен аңламый, Ниязны алырга радиога төшеп китә. Бер заман радиодан ике кешенең җырлаганы ишетелә.

– Кара,безнең Ибрай да шәп җырлый икән бит! – ди Хәмидуллин.

– Әйдә, Харис, өченче секретарьга "чыгыйк" әле, туктатсын,– ди.

Җырны туктатырга өчәүләп төшеп китәләр болар. Бераздан җирле радиодан биш кешенең сузып-сузып җырлаган тавышы ишетелә...

Ташла тәмәкеңне, бажай!

Шулай бер көн миңа кунакка авылдан гаиләсе белән бажай килеп төште. Хәл-әхвәл сорашкач-күрешкәч, хатыннар табын әзерләп, өстәл янына утырыштык. Сүз иярә сүз чыгып, (хатын-кызның шул бит инде, ирең эчәме-тартамы шуны сораштыра), хатын бажайга минем тәмәке тартуымнан зарланып:

-И, җизни, син тартмыйсың бит, безнекен дә ташларга өйрәт әле шул тәмәкене, – ди.

Бажай сүзгә кушыла:

– Юк, тартмыйм шул. Ләкин "салгач", пыскыткалыйм шул бераз "шәйтан таягын", анысы бар, – ди.

Рюмкаларга "зәм-зәм суы" бүлүемнән туктап:

– Бажай, – мин әйтәм. – Ничек саласың, еш эчәргә туры киләме соң? – дим.

– Үзең беләсең бит инде,-ди бажай, – мин дуңгыз фермасында эшлим бит. Әнә шул дуңгыз тагарагына төшә торган азык, "чартер-бартер" ясаганнан соң, минем "тагаракка" (ишарәләп, авызын күрсәтә)"буль-буль" итә. Шулай итеп, бер "салган" саен бер "кара көйдереп" тартып алам инде.

– Ташла тәмәкеңне, бажай! – дидем мин, авыр сулап. – Алай булгач, бик күпкә китә бит ул синең тартуың...

Илһам ФӘЙЗРАХМАНОВ.
Балык Бистәсе районы.

Рафаил САФИН

Муен, Баш һәм Бүрек
(мәсәл)

Үзеннән канәгать булып
Бер баш яши дөньяда.
"Мин бит сиңа хуҗа!" – диеп
Бүрек бәйләнә аңа.
Таныргa теләми Бүрек
Муенның баш икәнен, -
Белми әле ул Муенның
Башны борып йөрткәнен.
"Синең хуҗаң – мин!" – ди Бүрек,
Башка суккандай итә.
Әйтерсең лә, шул рәвешле
Муенны борып йөртә.
Бу галәмәт һич кенә дә
Аңлашылмый Муенга, -
Башта ул Бүрекнең сүзен
Алган иде уенга.
Аннан соң, хәтере калып,
Шактый ук кызып китте:
Башны боргалап, Бүрекне
Шундук акылга кертте...

Кемгә чалбар, кемгә оек

Шәриф абыйның балдызы, Ленинград кызы Сабира, җизнәсе һәм апасына ияреп, авылга кунакка кайта. Беренче көнне танышып сөйләшкәндә үк аның ачык күңелле, җитез һәм җор телле булуын яраттылар әти белән әни.

Йокыдан соң иртән Сабира өйалды баскычына чыгып баса, ишегалдын себереп йөргән әтине күрә, аның белән ягымлы исәнләшә. Шулчак аңа бер нәрсә сәер һәм кызык булып күренә: кодасы түшәктә киеп яткан күлмәге белән ак ыштаннан.

– Кода – ди ул наян көлеп, – әллә мин кибеткә йөгеримме? Чалбарың юк, ахры. Алып бирим үзеңә.

Әти, бер мизгел уңайсызланып калган кебек булса да, андый төрттереп әйткән сүзләргә биреше торган кеше түгел. Җавапны да кесәсез ыштаннан эзләгәне юк.

– Рәхмәт инде, кодача, барып йөрмә, чалбарларым бар. Малайлар җибәреп торалар. Күрәсеңдер, өстемә кигән әйберләр тәнемне яхшы каплаган. Шәрә җирем юк. Ә менә кибеткә миңа барырга туры килер. Оеклар белән баш яулыгы сатып алырга акчаң җитмәгәндер шул, – ди ул, шырык-шырык көлеп.

Моны ишетүгә кунак кыз капыл борылып өйгә кереп китә дә, тиз генә ефәк оеклар киеп һәм башына аллы-гөлле яулык бәйләп ишегалдына чыга. Кулында ирләр чалбары.

– Мә, хөрмәтле кодам, син дә чалбарыңны киеп җибәр алайса. Бир әле, ишегалдын мин себереп бетерим.

Шуннан бирле кодасы, аннары кайнатасы булган карт алдында Сабира оексыз һәм яулыксыз күренмәде. Әти дә йокыдан уяну белән чалбар кияргә онытмый торган булды.

Камил ФАСЕЕВ.

Җавабы табылмаган сораулар

- *Ә шулай да соңгы могиканны кем үтергән?*
- *Фәлсәфә ташының авырлыгы күпме?*
- *Ничә бодай бөртегеннән көшел барлыкка килә?*
- *Буш кесәдә уйнаган җил кайсы юнәлештән исә?*
- *Деноминациядән соң "миллионерлар"ның саны ничә миллионга кимиячәк?*

ТУРГАЙ

Всадник

Лошадь пахнет вкусно полем
и дорогой, и рекой.
Я б хотел ее пришпорить,
оседлать...
– Ишь, ты какой! –
конюх мне сказал косматый. –
К мамке дуй!
О-от, скакунец!

Сам-то ходит косолапо,
хоть гарцует на коне.

Рөстәм КУТУЙ

Матур иде бүре баласы...

Рөстәм КУТУЙ – бик тә җитди, бик тә үзенчәлекле шагыйрь. Әле "теге" заманда, Мәскәү шагыйрьләре башка милләт телендә чыккан әсәрләрне бик үк "өнәп" бетермәгән чакларда ук, урыс телендә һәйбәт әсәрләр язып, ул бик күпләрне татар әдәбиятын хөрмәт итәргә өйрәтте. Нәкъ менә шуңа күрә дә, һәм дә аның сүзе нәкъ үзенчә калсын дип, без Рөстәм Кутуй шигырьләрен ул язган телдә бирергә булдык.

Без аны җитди шагыйрь, дидек. Ә җитди шагыйрь балалар өчен язмый кала алмый. Кем белә, бәлки Рөстәм Кутуй әтисенең – Ватан сугышында чит-ят туфракларда ятып калган Гадел Кутуйның – балалар өчен язган әсәрләрен үз балачагында укып та күңеленә сеңдергәндер... Әйдәгез, бүген без "Тургай"да Рөстәм КУТУЙ шигырьләрен укыйк.

Волк

Принесли из леса волчонка.
Получился пес мировой.
Но – тоскует, тоскует о чем-то –
устремляется к звездам вой.

Зимней ночью, долгой-долгой,
грозная цепь не гремит.
Может, вспомнил – был он волком,
а назад уж путь закрыт.

Вот и плачет, замирая, –
не откликнется ли кто
из покинутого края?
Слышно очень далеко!

– Мать зовет! – хозяин скажет.
Выйдет тихо на крыльцо.
Сыплет ночь холодной сажей,
колкой сыплет ночь пыльцой.

Вздрогнет конь. Копытом стукнет.
Раскачает поле вздох.
Но ответно не аукнет
стужей скованной простор.

Снег блестит. Луна блистает.
Мир прислушался. Молчит.
Войпротяжен. Есть в нем тайна.
Перекрещены лучи.

Домовой

Домовой живет за печкой.
То сверчок он, то паук,
свет погаснет – станет свечкой,
ляжет тенью на полу,
звякнет ложечкою в чашке,
стукнет черной кочергой...

Мол, я – сторож настоящий.
Я из дома ни ногой!
Ты езжай, конечно, в город.
Школьных дел –
бумажный ворох.
Барабашка – мой приятель –
перепутал все тетради,
узелкам и счета нет...
Передай ему привет
от меня, от Домового,
старожила делового!

Воспоминание

Осень. Ветер
листья крутит-вертит.
Вспоминаю я о лете.

На озере – лебеди:
Одна – в камышах на гнезде,
другой – на открытой воде.

Вдалеке от людей
я увидел двух лебедей.

А вокруг
травы, луга.
И моя тень легка.
Ни звука из тростника.

Марина и малина

Где малина – там крапива.
Обжигает, как огонь.
Руки, щеки опалила.
Даже ягодки не тронь!

Очень девочка Марина
обожает есть малину.
Коленки заголила –
чуть забор не повалила!

Крапива жалится,
нипочем не сжалится.
Заноза на занозе –
одни слезы.

Гуляла цаплею,
царапины зацапали.
Поясок. Лента.
Жаркое лето.

А в чужом саду
все малинка на виду.
Потихоньку дразнится:
ай, плутишка! ай, проказница!
съешь меня! да съешь меня! –
колокольчики над ухом
серебристые звенят.

Хоть в речку лезь:
чешется тут, чешется здесь!

Ох, и горькая малина,
приманила-заманила.
Наревелась всласть Марина,
попрыгунья-балерина!
Сидит за баней,
укрыта лопухами,
с малиновыми губами.
– Буду есть теперь рябинку! –
шепчет девочка Маринка.

Радость

Девочкам – секреты,
мальчикам – страшилки.
Разжимайся, пружинка.
В разгаре лето.

Собьются в кучку
и прыскают в кулачки.
Не молчи, не молчи, не молчи!
В одиночку скучно.

Озеро, речка,
аллюр, галоп.
Живите вечно.
Не морщите лоб.

А секреты сладки,
горячи страшилки.
Живите без оглядки
от вершины к вершине.

Собирайте ягоды,
раскалывайте орехи,
хвастуны и ябеды –
Человеки!

Заноза

Плакса Наиль
палец занозил.
И заныл!
– Умираю, о-е-ей,
мне отрежут пальчик мой!

Стали тут на палец дуть,
йодом мазать осторожно
и иголкою чуть-чуть...

Побежали за мороженым.
Уложили на постель.
Ну, конечно, ахи-охи,
Да, дела настолько плохи!

Калəм! Кальбеңдә ни сер бар?

Сагыну гамәле

Җәйге таңнарда чык төшә торган бер сихри мизгел була. Тәүлектәге егерме дүрт сәгатьнең иң риясыз, иң керсез, иң садә мизгеле. Берничә секундлык чык төшү мизгеле ул тәүлекнең юксыну, сагыну гамәле. Караңгылык белән яктылык, салкынлык белән җылылык, сүз белән гамәл, иман белән имансызлык, гаделлек белән гаделсезлек, хак һәм нахак арасында бара торган көрәш, изгелекне һәрдаим сагыну гамәле. Әйтерсең, Аллаһы тәгалә бу изге су – салкын чыкта шатлыгы белән кайгылы, кайгысы белән шатлыклы Җиһанның йөзен юа һәм хәятне тәсдыйклый. Миргазиян Юнысның иҗаты татар тормышында нәкъ менә шул чык төшү мизгеле – сагыну гамәле ул.

Бу иҗат, һичшиксез, XX гасырның икенче яртысының гына түгел, мең еллык тарихы булган татар әдәбиятының сирәктән-сирәк күренеше. Бер караганда, иҗаты белән кабатланмас Миргазиян Юныс татарның Толстое да, Достоевские да, Чеховы да, Бунины да түгел. Икенче караганда, әйе, татар тормышының базларыннан торып фикер йөрткәндә, ул Буниннардан биш башка өстен дә кебек. Туктагыз әле, татарның кайсы язучысыннан без "татар Достоевские" булуын таләп иттек һәм итә ала идек? Шул ук вакытта сорау да куябыз: ә була ала идеме һәм бармы бүгенге урыста Миргазиян Юныс? Була алмый иде һәм ул бүген дә юк. Алпавыт, дворян утарларында тәмле шәраб эчеп, миллионлаган коллар исәбенә Пушкин булу, әлбәттә, җиңелрәктер. Кара урманнарда лашман тарткан, шахталарда тачка өстерәгән, урам себергән, тәкерек ялаган һәм бөек урыс иҗатчылары өчен иген иккән, мал-туар асраган, үзенең миллияти иҗатын эш арасында, чыра яктысында, күз яше дәрьясында гына бар итә алган мескен татар баласыннан без татар Достоевские булуны таләп итә алмый идек. Татарның Достоевскийларга тиң, урыны-урыны белән алардан да югары Исхакыйлар буынын Октябрь инкыйлабы чека базларына тыкты һәм чылбырны өзде. Татар әдәбиятының шуннан соңгы чоры советлар сеңдергән сәяси һәм милли үшәнлеккә батты, әдәбиятыбызның мондый үшәнлеккә батарга теләмәгән батырларын шул ук советлар режимы юкка чыгара, һәлак итә килде. Әгәр без барлык татар совет әдәбиятын, шигърияцен, драматургиясен, тәнкыйтен бүгенге мәгънәсезлегебезнең сәбәпләре биеклегеннән, бүгенге күзлектән, бүгенге заруриятән чыгып карасак, бу әдәбиятны халык, милләт әдәбияты итеп түгел, ә халыкны, милләт кадәр милләтне ясалма, ялган ватандарлык, иҗтимагый җебегәнлек, аморфлык, сәяси үшәнлек сазлыгына җайлап батыру әдәбияты дип карарга мәҗбүр булыр идек. Бу күренеш безнең барлык вафат һәм исән булган классикларыбызга да хас. Чөнки аларның иҗади ирке һәм сәяси күз күреме Мәскәү тарафыннан сөннәтләнгән, яшәү шартлары алыначак һәм алынмаячак бүләкләр, фатирлар, төрле өстенлекләр белән чикләнгән иде. Мине дөрес аңлагыз, минем Миргазиян Юнысны һич кенә дә классикларыбызга каршы куясым килми, һәм ул гадел дә булмас иде. Һәрхәлдә, без "үшәнлек" әдәбияты дип атасак та, Галимҗан Ибраһимовның "Табигать балалары", Фатих Хөснинең "Йөзек кашы", Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыять", "Рәшә"ләре һәм башкалар тәрбияләде бит безнең сирәк каләмдәшебез Миргазиян Юнысны!

Милли хәрәкәт дулкынында без XX гасырның 90 нчы еллары башында "Мәскәү кәмиссиәсе" шартларыннан котылырга тырышып караган идек. Үшәнлегебез аркасында бу мөкатдәс бурыч тормышка ашмый калды. Шулай итеп, безнең бүгенге тормышыбыз, кызганычка, тагын да "Мәскәүдән кәмиссиә килде" шартларында үтә. Нишлисең, шул кирәк безгә, дип сыкранмыйча булмый.

Совет басымының иң өшәке елларында да урыс һәм дөнья әдәбиятының прогрессив витаминнары белән азыкланып торган Миргазиян Юныс татар әдәбиятында үзенең сирәк каләмдәшләре белән гыйсъянчылык агымын тудыруга йөз тота һәм аны саклап кала алды. Бу "алдынгы савымчылар һәм шәһәр төзүчеләр" әдәбияты түгел иде, әлбәттә. Бу исә аның иҗатының татар булган манкорт татар белән гомере буе аяусыз рәвештә көрәште, аны бу түбәнлектән коткару өчен бихисап көч куйды, кан түкте һәм нәтиҗәдә тазалыгын югалтты. Әдип йөрәгенең тере диафрагмасын тимер диафрагмага алыштырып та милләтенә тугры калды һәм үзенең иң җитди әсәрләрен язды.

Кыскасы, иң куандырганы, аптыратканы , хәтта сискәндергәне шул: моннан 55 ел элек авылдан чабата белән чыгып киткән Исергәп яшүсмере безгә, үзен татар язучысы, татар шагыйре, татар әдибе дип исәпләгән әдипләргә һәм барлык татар халкына, шул ук халыкның иң саф, таушалмаган, талмаган, дөрес, анык, аһәңле телен алып кайтып бирде. Ул "зәңгәр утраулар артындагы Занзибарда" булган икән. Ул үшәнлек, куркаклык, холуйлык теле түгел. Ул



безгә, яшьрәк буын язучыларга биргән беренче сабагы иде. Һәм әлеге сабакны ул безгә Казанда яшәп, Язучылар берлегенең Бауман урамындагы бүлмәләреннән торып түгел, ә чит кыйтгалар – тигезлеген югалткан диңгезләр, тау-тау дулкыннар, чит кабиләләр, чит кавемнәр арасында эшләгән һәм яшәгән килеш бирде. Димәк, татар булып калу гына түгел, иң бөек батырлык – аның яңа әдәбиятын тудыру өчен шартлар бары тик Татарстан, Татарстан Язучылар берлегенең бүлмәләрендә гәп сату белән генә чикләнми, ә хәтта киресенчә икән – әгәренки син үзең, Дәрдмәнд әйтмешли, "чын татар" булсаң. Әйе, нәкъ киресенчә, татарның мондый гыйсъянчы, пакь, камил телле әдәбиятын ул Татарстаннан читтәге материкларда тудырды. Каян алган бу кадәр эчке һәм тышкы кодрәтне гади "Исергәп малае"? Милләтенең аһ-зарларын, сулыш нечкәлекләрен, ком тулган кан юлларының буылуын, милләтнең бәйләнеш, тел һәм хиссияти кадерләрен ничек кенәләр итеп онытмаган ул читят тарафларда? Һәм соңгы сорау: ничек кенәләр итеп тугры кала алган үз милләтенә бу диңгезчеләр номенклатурасының иң югары катламнарына үрли алган татар? Җавап бик тә гади һәм кыска: Тукай саклаган аны. Исхакый үзе саклаган. Мөселман өммәте, Ислам дине саклаган. Әти-әнисенең изге, тәрбияле рухы, димәк, татарның революциягә хәтле тупланып кала алган мирасы саклаган. "И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле..." Ничек онытырга мөмкин? "Галибанә яктырып, ал таң ата..." Ничек онытырга мөмкин, әгәренки син татар булсаң? Ә ни өчен белми, белсә дә, тиз оныта моны бүгенге татар баласы? Җавап шулай ук кыска һәм гади: чөнки тиешле мохит юк, борынгы тәрбияне алган ата-ана юк, исламчылык юк. Менә ни өчен онытмаган Миргазиян Юныс Тукайның галибанә аткан таңнарын зәңгәр дулкыннар артындагы Занзибарларда. "Шәмделләрдә генә утлар яна..." дип көйләгән ул шашкан дулкыннарга. Һәм шуннан илһам тапкан. Совет дәүләтчелеге татарны "чын татар" һәм "паспортлы татар" – урыс татарына бүлде. Нәтиҗәдә татарның чын татары 0,01 процент күләмендәге юка катлам – фольга булып кына торып калды. Миргазиян Юныс бары тик паспорты буенча гына күрәшчеләр, гыйсъянчылар теле. Хәнҗәр кебек үткен. Хәтфә кебек йомшак. Ошбу батыр телнең хуҗасы булган батыр йөрәге аны Әлмәт язучылар оешмасы һәм аның акыллы һәм тырыш җитәкчесе шагыйрь Разим Вәлиуллин ярдәме белән бөтенләйгә Әлмәткә алып кайтты. Мәскәүләрне ташлап. Соңгы 50 ел эчендә иленнән чыгып тайган миллионнарча татарлар нигә кайтмыйлар икән дә, кайтсалар, нәрсәләр алып кайттылар икән? Телне беләләрме, балалары, хатыннары – гаиләләре татармы? Кыйблалары татар-мөселманмы?

Үткән ел "Казан утлары" журналында аның "Соңгы сулыш" дигән яңа әсәре дөнья күрде. Мин журналның һәр санын түземсезлек белән көтеп алдым һәм бер тында укып чыктым. Әсәр мине тетрәндерде. Анда безгә, татар язучыларына, өйрәнерлек нәрсәләр тулып ята. Күрә генә белергә кирәк. Әмма күрә белмибез. Шул ук "Казан утлары" журналы алып барган "Бүгенге проза турындагы сөйләшү"дә катнашкан язучыларыбыз нишләптер 1965-97 еллар арасында, ягъни 32 еллык чор эчендә шактый ачышлар ясаган Миргазиян Юнысны, башка язучыларны күрмәмешкә салышалар, үзләренең су буе кадәр озын язмаларында чуерташ сыман шомарган бер үк исемнәрне кабатлау, кайбер очракта үзләренә эш урыны, фатир, премия бирдерткән даирәләрне мактау белән мәшгульләр. Бу җәһәттән Кояш Тимбикова, Нәҗибә Сафина, Әхсән Баян, Шәрәф Әхмәдулла, Мансур Шаһимәрдән, Рашат Низамиевларның чыгышлары сәер тәэсир калдыра. "Соңгы чор татар әдәбиятын укып бара микән алар?" дигән урынлы сорау туа шушы язмалар белән танышканда.

Миргазиян Юныс бу әсәрендә үзен әдәбиятка заман сулышын, шигъриятнең югары дулкынын – публицистик алкымның җанын өрә алган язучы итеп күрсәтте. "Соңгы сулыш" – батырлык, шәхеснең шәхес булып калуы турында тыйнактан тыйнак язма ул. Язучы һәр образны, детальне, фикерне публицистик яктан ачыну белән сугара белә. Куану белән янәшәдә әрнеш. Әрнеш белән янәшәдә куаныч. Без "урынсыз" дип исәпләргә өйрәнгән урыннарда бик тә, бик тә урынлы һәм, әйтергә кирәк, җиһаный гомумиләштерүләр ясый. Бу гомумиләштерүләр бик ипле итеп туган җиренә, туган халкына барып тоташа. Менә берничә генә мисал:

"Күзләремне чатырдатып йомам. Миңа йокы кирәк. Иртәгә хәлиткеч көн. Миңа ял кирәк. Тынычлану кирәк. Ә галәмне салкын котып төне биләп алган. Үткән көннәр, бүгенгелек, безнең киләчәкләр – барысы да караңгылыкка томаланып югалган. Ә музыка туктаусыз рәвештә шом агызып тора. Һаман йокларга тырышам. Шушы тырышу качыра йокымны. Ниһаять, йокыга кул селтим, уйлар давылына ташланам... Тукта әле... Мин бит утыз елга якын туган туфрагыма кайтып, бабаларым сулаган һаваны сулап, алар эчкән суны эчеп яшәү турында хыялландым. Хыялымны Мәскәү җимерде. Ул әләктереп алды минем якамнан. Һәм җибәрмәде. "Тотса Мәскәүләр якаң..." дип Тукаебыз юкка гына әйтмәгән икән". Менә йөрәгенә операция ясатырга дип хастаханәгә яткан адәм халәте: лирик герой шулкадәр нечкәргән ки, ул хәтта әңгәмәдәшенең өч кенә аваздан торган сүзеннән дә глобаль нәтиҗәләр ясый. "Мине биш кешелек палатага урнаштырдылар. Җыештыручы хатын урын җәйгәндә әйтергә өлгерде:

– Бу караватта сезгә кадәр яткан кеше шундый әйбәт иде.

"Иде". Менә шушы өч хәрефтән торган сүз ул әйбәт кешенең кайда икәнлеген ачыклады".

Менә тагын бер өзек.

"Хирургия кабинетының ишегенә таба борылганда "каталка" бер генә мизгелгә туктагандай итте. Нәкъ шул чакта мин тәрәзәнең өске өлгесеннән җептәй нечкә ботакка эленгән ике сары яфракны күреп алдым. Коела алмыйча калган ике ятим яфрак. Көзге җил аларны әкрен генә селкетә. Сары яфракларның миңа кул болгап саубуллашулары иде бу. Шул ике нәни телгән теләкләр өнкөемнең васыятедәй күңелемнең иң түренә кереп урнашты: "Курыкма, бар әле синең гомерең... Шикләнмә, бар... Ышан. Бирешмә, яме". Мин ым белән булса да яфрак-фәрештәләргә җавап бирдем: "Сау булыгыз, яфраклар. Уяна алмасам, миннән бәхиллек. Туган җиремә, минем Кара ярыма, туганнарыма сәлам тапшырыгыз. Кайгырмасыннар. Үкенерлек түгел, яшәдем мин..."

Без бу кадерле сүзләрне әдәбиятыбызның кабер ташына түгел, ә кадер ташына язарга бурычлыбыз. Миргазиян Юныс кешеләр арасында сирәк очрый торган пәйгамбәрләр нәселеннән. Бу пәйгамбәрлек аның иманы белән тәэмин ителгән. Рәхмәт сиңа, Миргазиян абзый. Чын күңелдән рәхмәт. Син һәрвакыттагыча сагыну гамәлендә.

Айдар ХӘЛИМ.

● *Күренекле язучы Миргазиян Юныс.*
Ә.ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

Котлы булсын нардуган!

Башка бик күп халыклардагы кебек, татар халкында да кышның яңа ел көннəре төрле тылсымлы йолалар, күрəзəлек уеннары белəн билгеле. Нардуган йолалары шулар арасында иң кызыклылардан санала. Урта Идел буенда яши торган күршелəребез: чуашлар, удмуртлар, марилар, мордвалар да аны бəйрəм иткəннəр.

Татар халкы яшəгəн төрле төбəклəрдə, җирле сөйлəшлəрдə Яңа ел, нардуган йолаларының бик күп борынгы үрнəклəре һəм аларга караган сүзлəр сакланып килə. Белгəнегезчə, татар халкы гомер буе башка халыклар белəн бик нык аралашып яшəгəн, бəйрəмнəрне дə бергə-бергə, күңелле итеп үткəргəн. Шуңа күрə кайбер йолаларның эчтəлегендə һəм йола сүзлəрендə күрше халыклар белəн уртаклыклар күп. Бу аеруча татар халкының республикадан читтə яшəгəн төбəклəрендə нык сизелə.

Түбəндə татар халкының төрле этнографик төркемнəреннəн язып алынган, яңа ел һəм нардуган йолаларына караган сүзлəр һəм сөйлəмнəр китерелə.

Яңа елны котлама (котларга) керү (нократ татарлары, ягъни Киров өлкəсенең Слободской Нократ авылында һəм Удмуртиянең Балезино, Юкамен районнарында яшəүчелəр).

Яңа ел көннəрендə балалар "җиңел аяк" белəн, махсус такмаклар əйтеп, өйдəн-өйгə кереп йөрилəр.

– Яңа елны котлап балалар керəлəр. Кайсын чакырып кертəбез, яки берəр балага: "Миңа кер əле", – дип əйтеп куясың. Капка ачык тора. Керəлəр дə:

Яңа елыгыз котлы булсын,
Ашлыгыгыз яхшы үссен,
Башагыгыз өстенə
башак үссен,
Сыерыгыз сөтле булсын,
Тана бозауласын,

– дилəр.

– Гыйнварда балалар, Яңа ел котлыйбыз, дип йөреп кайталар. Кем конфет, кем чиклəвек бирə.

– Яңа ел белəн котларга керүчелəргə май исе чыгарып торабыз. Май исе чыксын дип, төнлə торып тəбикмəк пешерə башлыйбыз.

Нардуган турында керəшеннəр болай дип искə алалар:

– Нардуган уникe көн буладырые. Ул унике көн эчендə искечə Яңа ел керəдерие.

Нардуган өе – яшьлəрнең өй хуҗасы белəн килешеп, бергə җыелып күңел ача торган урыны.

– Нардуганда бер өйгə барып өй хуҗасына: "Безгə нардуган өе бир əле сатып", – дибез. Күкəй, май алып килəбез, нардуган өен сатып алабыз, шунда биешəбез, такмак əйтешəбез, йөзек салабыз.

Нардуганчы – нардуган уеннарында катнашучы.

– Бездəн олыраклар нардуганчы булып киенеп чыга торганнарые. Кайда кунак кызы бар, шул өйлəргə керə торганнарые.

Нардуган көннəрендə кеше танымаслык итеп киенеп, өйдəн-өйгə кереп йөрүне ***бабай булып йөрү, бабайчы вакыты*** дип тə əйткəннəр.

– Авыз ачкач була бабайчы вакыты. Анда төрлəнеп чыгалар, ягъни төрлечə кием киенеп. Туннарын əйлəндереп киялəр, чегəн булып киенəлəр, битлəрен корымга буйыйлар.

Кама Тамагы районында яшəүче татарлашкан, ягъни татар телендə сөйлəшə торган мордваларда (аларны мордва-каратайлар дип тə атыйлар), урыс телендəге крещение сүзеннəн үзгəртелгəн ***керəшəнə*** сүзе кулланыла. ***Керəшəнə прəннеге*** – кош формасында пешерелгəн прəннеклəр. Аларны сандугач дип тə атыйлар.

– Керəшəнəдə камырдан керəшəнə прəннеге "сандугач"лар пешерəлəр. Төче камырны басып, сандугачның башын, койрыгын ясыйлар, йөземнəн күз куялар да табага тезəлəр. Аны балаларга өлəшəлəр. Кунакка да алып баралар.

Керəшəнə чабу – яңа ел көннəрендə атларга утырып, урам əйлəнеп йөрүне шулай əйтəлəр.

– Керəшəнə көннəрендə атларны бизилəр. Бер урамнан гына чабарга дилəр. Халык киенешеп шуны карарга чыга.

Рязань өлкəсендəге Бастан авылында нардуган турында болай сөйлилəр:

– Яшьлəр җыелышып нардван (нардуган) уйныйлар. Өстəл артына утыралар. Җырлап-җырлап йөзеклəр салалар:

– Нардваныгыз нард булсын,
Эче тулы төш булсын.
Нардван җырын кем җырласа -
Шул бик бəхетле булсын.

Нардуган көннəрендə иң күңеллесе – ***йөзек салу, балдак салу*** йоласы. Аны элегрəк егетлəр-кызлар көтеп алганнар, авылдагы бер өйнең хуҗабикəсе белəн алдан сөйлəшеп, килешеп куйганнар. Кич белəн яшьлəр шунда җыелышалар, гаилəдəге баш бала белəн ***төпчек баланы*** бəкедəн су алып кайтырга җибəрəлəр. Бəкедəн суны алганда балта белəн кояш уңаена таба сызыклап алалар. Кайтканда сөйлəшмичə, артыңа əйлəнеп карамыйча кайтырга кирəк. Əлеге суны тылсымлы, серле көчкə ия дип ышанганнар. Йөзек салганда, гадəттə, егетлəр башлап йөргəннəр:

Əрле дə бирле борыла-сыгыла
Кызлар йөри килəп сарырга.
Кызлар йөри килəп сарырга,
Егетлəр йөри йөзек салырга.

Чилəктəге суга һəркем үзенең йөзеген ниятлəп сала. Һəм кемгə нинди җыру чыга икəн дип түземсезлек белəн көтеп тора.

Нагайбəк керəшеннəре (Чилəбе өлкəсендə яшəүче керəшеннəр) сөйли:

– Унөченче көнне кич йөзек салу булыр ие, җыелыр ие халык. Төпчек бала белəн баш бала су алып килерлəр ие. Төпчек бала болгатырга утырыр ие. Сала бирəлəр, җыруны əйтə бирəлəр. Анда əйтерлəр ие, начар җыру җырларга тырышмагыз, ару җыру җырларга тырышыгыз, дип. Балдакны өч тапкыр салалар. Аннан ары аның суын алып чыгып, кояшка каршы түгəлəр.

Нардуган көннəрендə йөзек салып күрəзəлек иткəндə əйтелə торган нардуган җырларын ***нардуган такмакларын*** əйтүдəн башлыйлар:

Нардуганым нарына
Бакма кеше ярына.
Кеше яры – яр булмас,
Үз ярыңа тиң булмас.

Нардуганым – нар булсын,
Эче-тышы нур булсын.
Нардуган башы кемгə тияр
Ул бик бəхетле булсын.

Нардуганда ***сынамыш җыруларын*** да җырлыйлар. Менə сугыш вакытында шундый җырулар чыккан:

Кара каеш биллəргə буш -
Сатин күлмəклəргə иш.
Инде, җаный, мин китəмен,
Кала куеннарың буш.

Яхшы җырулар да чыга:

Югарочтан берəү килə,
Өслəренə кигəн күк җилəн.
Күк җилəннəрен җилфердəтеп
Сагынып кайта күп җирдəн.

Ак келəтнең ишеге
Таңга таба ачыла.
Талигалы бəндəлəргə
Күк кабагы ачыла.

Нардуган уеннарына катнашып өйдəн-өйгə кереп йөрү, күрəзəлек итү һ.б. ***нардуган чабу*** дип атала.

Питрəч районы Янсуар авылында болай дип сөйлəделəр:

– Нырсуарына утырмага киттем. Нардуганда чабам да чабам, орчыкны эрлəргə бер дə ара тими бит. "Кодача, тəрəшлəреңне дугага бəйлəп җибəрəм, чапма", – ди яшь кода. "И-и, җибəрсəң җибəрерсең, чабам əле чабарлык чакта", – дим.

– Нардуган вакытында ирем киенеп чыгасы булды. Тун киде, толып киде, кереп китте күршелəргə. Күрше тышка чыккан булган, капкадан ул кергəн уңайга, куркып чигенə башлаган. Шунда бер сыер ята икəн, сыер өстенə ауган. Бу сыер сикерə дə тора, күршем дə сыерга атланып тора, ди. Ирем əкрен генə көлгəн дə чыгып киткəн. Иртəгесен бу күршем кергəн: "Менə ай җактысы җакты, əкəмəт күрдем бит əле мин, ышанасыңмы, җукмы, – ди. – Баштанаяк актан киенгəн, – ди. – Җөрəгем җарылды да кереп Марҗый җанына постым гына бит", – ди.

Яңа елда, ягъни нардуган көннəрендə кызларны, беренче чиратта, үзлəренең язмышлары, кемгə кияүгə чыгулары кызыксындырган. Шуңа бəйле рəвештə алар төрле ырымнар белəн күрəзəлек иткəннəр.

Капка аша итек ыргытканнар. Итекнең башы кайсы якка төшүенə карап, шул тарафка кияүгə барырбыз, дип юраганнар.

Кыз кеше урамга йөгереп чыга. Беренче булып карт кеше очраса – картка китəм, яшь кеше очраса – яшькə китəм, дип юраган.

Кызлар кибəн янына барып, авызлары белəн аннан башак тартканнар. Тулы башак чыкса – бай кешегə, икмəкле-тозлы кешегə барам, дип юраганнар. Башак урынына салам гына чыкса, кияү ярлы бəндə буласы, имеш.

Нардуган көннəрендə кызлар төнлə белəн абзарга, сарык аягы тотарга чыгалар. Дөм караңгыда кайсы да булса берсен элəктереп, үзлəренең тамгаларын бəйлəп куйганнар. Иртəгесен карагач, яшь сарык элəккəн булса, яшькə китүгə, карт сарык элəккəн булса, картка китүгə юраганнар. Кайвакыт көлке ясау өчен, өй хуҗалары сарык янына бозау да ябып куя торган булганнар. Кыз бала сарык урынына бозау тотса, кияве бозау шикелле үшəн булыр, дип фараз ителгəн.

Кемнең дə булса берəүнең тəрəзə төбенə килеп тыңлап торалар. Ул тынга бару дип атала. "Китү" дигəн сүзлəр чыкса, быел кияүгə китəм икəн, диелгəн. Кыңгырау тавышы килгəн якка карап та кайсы якка кияүгə китəсен чамалаганнар.

Нардуган йоласы, борынгыдан килгəн йола буларак, христиан дине белəн дə, Ислам дине белəн дə бəйле түгел. Мəсəлəн, керəшеннəрнең нардуган уеннарын дин əһеллəре, поплар тыярга тырышканнар, нардуганны "шайтан уены" дип атаганнар. "Сез чумылган кешелəр, сезгə болай йөрү килешми", – дигəннəр. Керəшеннəрнең үз араларыннан чыккан шагыйрь Яков Емельянов болай дип язган:

Җаман эшне нардуганны
Ич тə искə алмагыз.
Шайтан туе нардуганга
Кусалар да бармагыз.

Раштуа көннəрендə татар-мишəрлəр махсус йола азыклары пешерəлəр. Мəсəлəн, Пенза өлкəсе Каменски районы Кикин авылында кызлар ***чигелдеклəр*** (вак бавырсаклар) пешереп күрəзəлек иткəннəр. Аны кызлар көндезен үк пешереп куйганнар.

– Раштуа бəйрəмендə кызлар чигелдек пешерəлəр, аны бик тозлы итəлəр. Шуңа ашагач эчəсе килсен, дип. Чигелдеклəрне ашыйлар да, баш очларына шырпыдан кое ясап йокларга яталар. Сөйлəшергə ярамый. Төшеңдə шул коедан бер егет су алып бирə, яки ат эчертергə килə, шул киявең була, ди.

– Раштуада чигелдеклəр пешерəлəр, терлеклəргə, куйларга (сарыкларга) да бирəлəр. Икешəр бəрəн китерсен, дилəр.

Төче күмəч – ***пипи*** пешерəлəр:

– Ахирəт кызым əйтə, раштуада күмəчлəр, пипилəр пешерəлəр икəн,ди. Мин дə пешерəм, дип əйтəм. Җиз илəктəн илəгəн бодай оны бар, келəңгеч (көнбагыш) – киндераш мае бар, су да салмыйм, камыр басам. Бер җиде-сигез таба пешердем. Ашап туйгысыз, авызда уала. Баш очына куйдык берəр пипине. Кемдə булса төштə күренə, янəсе.

Рязань өлкəсендə яшəүче Касыйм татарларында тагын шундый үзенчəлекле йола турында сөйлəделəр. Яңа ел көнне өй саен көтүче кереп йөри. Ул бүлмəлəргə солы һəм бодай сибеп җибəрə.

"Хуҗаларга Алла исəнлек бирсен, куйларыгыз күп булсын, икешəрне бəрəнлəсен, сыерыгыз тана бозауласын, биягез колынласын, киленегез ул-кыз түрəсен (китерсен)", – дип, телəклəр тели.

Нардуган көннəрендə эшлəргə ярамый торган, тыелган эшлəр дə булган. Əйтик, ямау ямарга ярамаган. Аны бозган очракта, сарыклар аклы-каралы була, имеш. Авылда аклы-каралы бəрəннəр күп булганда шаяртып: "И Ходаем, бу Яңа елда ямау ямаган икəн", – дигəннəр.

Яңа елда йон эрлəсəң, куйларга əйлəнчек була, имеш.

Ə нардуган көннəрендə, күршең бусагасына атлаганда телəнə торган телəклəр түбəндəгелəр:

Нардуган, нардуган,
Нардуган, хуҗалар.
Котлы мөбарəк булсын,
Тормыш түгəрəк булсын,
Мал-туарларыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннəрегез уңсын,
Күкəй кебек тук булсын,
Нардуган, нардуган!

Тылсым ишеклəрен ачып, хуш килəсең, Яңа ел, нардуган!

Флера БАЯЗИТОВА,
филология фəннəре кандидаты.

Дәрдмәнднең соңгы айлары

Соңгы вакытта көндәлек матбугатта (аерым алганда, "Вечерняя Казань" гәзитендә) татар әдәбияты классигы, кабатланмас мәшһүр шагыйрь Дәрдмәнднең ачтан үлгәнлегенә ишарә ясаган язмалар күренгәли башлады. Октябрь революциясенә кадәр алтын приискалары тоткан әдип чыннан да шундый афәт корбаны булганмы? Гомумән, Дәрдмәнд гомеренең соңгы айлары ничек узган. Бүген тәкъдим ителә торган мәкаләнең авторы шушы һәм башка сорауларга җавап табарга омтыла.

Мәгълүм ки, Ырынбур шәһәрен большевиклар беренче мәртәбә 1918 елның гыйнвар азакларында "аклар"дан азат итәләр. Һәм монда кичекмәстән Совет власте урнаштырыла башлый. Элгәреге хакимият оешмалары ябыла, җитәкчеләре кулга алына яисә куып таратыла. Элек чыгып килгән күп санлы гәзит-журналлар да җан тәслим кылалар, шул исәптән Рәмиевләрнең "Вакыт" типографиясендә, шулар ярдәме белән үк "Яңа вакыт" исемендә яшәп килгән гәзит тә ябыла. Типография исә яңа властька тапшырыла. Рәмиевләр аны ике атналык эш хакы һәм шул вакытка җитәрдәй башка кирәк-ярак белән тәэмин итеп калдыралар. (Истәлекләрдә расланганча, бу эшне, гаиләнең өлкән кешесе буларак, Дәрдмәнд үзе кияве Ярулла Вәли белән бергә башкара). Бу вакытта инде алтын чыгару ятмалары да яңа оешкан төрле сәяси йөзле яңа власть тарафыннан тартып алынган була. Рәмиевләр карамагындагы приискаларның иң күп өлешен – егерме биштән ашканын – 1917 елның соңгы көннәрендә игълан ителгән "мөстәкыйль Башкортстан мохтарияты" үз милке дип белдерә. Юлык авылында урнашкан, барлык исәп-хисапны берләштергән төп "контора" белән алтын тупланган зур таш келәт һәм нигез йорт та шул мохтарият карамагында кала. Ырынбур төбәгенең төньягындагы һәм Чиләбе тирәләрендәге иң бай приискалар исә әлегә аклар кулында булып, алар белән элемтәләр тәмам өзелә. Анда казып алынып та, тиешле урынга илтеп тапшырылмаган хәзинәнең язмышын тәгаен белүче булмый диярлек. Ул хәзинәләрнең дә гаскәр тоту хаҗәтенә дип талануы турындагы аяныч хәбәрләр генә әледән-әле ишетелгәләп тора.

Бу эшләрнең киңәшеп-барлашып эшләнмәвенә Дәрдмәнднең бераз хәтере кала, билгеле. Бөтенбашкорт корылтае Ырынбурда барган һәм әлеге хәлиткеч карар кабул ителгән көннәрдә шагыйрь каладан беркая да китмәгән була. Корылтайда катнашкан Галимҗан Ибраһимов анда булган хәлләрне тәфсилләп бәян иткәч, шагыйрь үз рәнҗешен аңа һәм әдипне озата килгән ерак кардәше Исмәгыйль Рәмиевкә белдермичә тыелып кала алмый, әлбәттә. Башкорт зыялылары һәм аксакалларының күпчелеге белән элек-электән аралашкан кеше бит ул. Аларның бүгенге сәяси башлыгы Зәки Вәлидигә дә үз вакытында һәм матди, һәм рухи яктан булышып, теләктәшлек кылып килде, аның җитди уңышларына сөенүче бер җан булды. Һәм менә шул кешеләр аңа да кагылышы булган карарларын кабул итәр алдыннан бер киңәшеп, уйлашып алуны кирәк тапмаганнар. Шул хәлгә ничек үртәлмәскә мөмкин инде...

Менә шундый җан әрнүле көннәр әле узып та өлгермиләр, элекке тормышкөнкүрешне тамырдан үзгәртүне максат итүче көчләр калада үз хөкемнәрен урнаштыралар. Ирексездән күңелне төшенке уйлар били.

Зәгыйфь кырмыскамын мин, юлда яткан,
Түгел балкорты мин, чагып елаткан.
Ни зур бу дәүләт кем, шөкер итәм күп -
Минем беркемгә җәбер итәр көчем юк, -

дип яза шагыйрь ул көннәрдә.

Күп киңәшү-сөйләшүләрдән соң шагыйрь гаиләсе мондый карарга килә: Мөхүпҗамал абыстай белән Дәрдмәнд юллар өзелгәнче үк Орски каласына китеп торачак, аннары аларны Искәндәр белән Шәрифзадә дә, куып тиздән туачак бәбечләре белән, җитәчәкләр. Ә инде төп йортка күз-колак булып Зәйнәп белән Ярулла калачак. Олы кызлары Өммегөлсем белән кияүләре Гариф та үз өйләрендә, Ырынбурда калырга тиеш булалар.

Орски шәһәрендә алар Мөхүпҗамал абыстайның ир туганнары, брадәрән Борнаевларның сәүдә йортына кайтып төпләнәләр. Шәһәрнең үзәк урамындагы бу йортның икенче катында аларга аерым бүлмәләр бирелә. Шушында ук абыстайның кече туганы Мәхмүтҗан да гаиләсе белән яши. (1964-1966 елларда миңа Борнаевларның 1910 елда туган олы улы Рәшит ага белән бер-ике мәртәбә очрашып сөйләшергә насыйп булды). Беренче сөенечләре булган Бәшир улларын кочып, Искәндәрләр җәй башында бу шәһәргә дә кайтып төшә. Алар шәһәрнең Урал елгасынарак сыенган икенче бер урамда яшәүче Борнаевларның өлкәне – Габдуллаҗан өенә тукталалар. (Әлеге йорт хәзер дә саклана, ә менә Дәрдмәнд гаиләсе ике кыш чыккан үзәк урамдагы зур өй 1984 елда сүтелде).

1920 елның көзендә шагыйрь гаиләсе "аерылып" чыга – вак сәүдәгәр Мусиннар якындагы бер авылда кибет ачып, шунда яши башлыйлар һәм берничә кышка дип үз өйләрен кадерле кунакларга калдырып китәләр. Урамга буйлап салынган, ул заманда такта түбәле булган бу агач өй хәзер дә исән. Биредәге көмеш сулы Урал елгасына һәм халык бик яратып ял итә торган зур аланлы матур әрәмәлеккә бер урам аша гына тора.

Дәрдмәнднең ул елларда ни-нәрсәләр эшләвен, ничек яшәвен кайбер истәлекләрдән чамаларга була. Рәшит ага "ул бабай һәм кучер"нең җәйге матур көннәрдә Урал елгасына балыкка йөрүләрен хәтерли. Суның түбән агымында, шәһәрдән биш-алты чакрымда әле алтмышынчы елларда да балыкчылар мактап телгә ала торган "Ущелье" дип аталган бик тыныч, матур бер урын бар иде. Анда Урал елгасын ике тарафтан да текә тау кыялары кысып, бик хәтәр тарлавык хасил итә. (Шул тарлавыкта язгы бозның бөялүе сәбәпле 1924, 1942, 1957 елларда бик тә яман су ташу күренешләре була, иске шәһәрнең өчтән ике өлеше, шул исәптән шагыйрь соңгы кышын чыккан һәм җәен җәйләгән әлеге агач өй дә су астында кала). Шушы тарлавыктан котылып бераз киткәч тә елга берничә тармакка аерыла, җәелеп, тын гына ага башлый. Шул "күлләр"нең тымызык култыкларында җәй дәвамында төнбоеклар чәчәк атып утыра. Шагыйрь әнә шул тын почмакка балык тотарга йөргән, шәһәрнең ыгы-зыгысыннан, дөнья мәшәкатьләреннән шунда җанына ял тапкандыр, күрәсең. Ул шулай ук каладан утыз чакрымнар урнашкан, башлыча Мирхәйдәр Фәйзинең ишле агалары һәм туганнан туганнарының утары булган Җүнәй авылында һәм шуның янәшәсеннән агучы Гөберлә суы буйларында да ял иткәләгән. Шагыйрьнең 1919 елның җәй урталарында Җүнәйдә берара яшәп алуын, шулай итеп Орски шәһәре өчен аклар белән кызыллар арасында барган каты бәрелешләрдән китеп торуын көндәлегендә М.Фәйзи дә теркәп калдырган.

Сигез-тугыз яшьлек Рәшитнең хәтеренә сеңеп калган тагын бер хатирә: кайбер көннәрдә шагыйрь бабай, имештер, ишегалдында "тавыклар белән французча сөйләшеп йөри". Утсыз төтен булмый, дип әйтәбез бит. Димәк, бу очракта да тормышның бер чагылышы сакланган булуы ихтимал. Мәгәр, бер генә истәлектә, шагыйрьгә багышланган бер генә хезмәттә дә Дәрдмәнднең урысчадан кала тагын нинди телләрне үзләштергәнлеге әйтелми. Төркиядә ике ел яшәү дәверендә аның төрекчәне үзләштергән булуы шик тудырмый. Шул ук заманда Төркиядә гамәли икенче тел саналган французчаны белгәнме соң ул? Әлегә җавап юк. Шулай ук кайсы елларда нинди илләрдә йөреп кайтканлыгы хакында да белмибез диярлек. Сакланып калган фотоларга таянып фикер йөрткәндә, ул 1914 елның җәй айларында Бельгиягә, Италиягә сәфәр чыккан. Дөресрәге, бу очракта ул кызы Зәйнәп, агасының кызы Камилә һәм аның кияве Садри Максуди белән бергә сәяхәт кыла. Сәяхәтләренең максаты да бар: улы Гариф (1896-1971) белән агасының улы Мидхәт-Әхәтне Льеж шәһәрендәге техник югары уку йортына озата бару һәм Германиядә Тау академиясен шул язда тәмамлаган улы Искәндәр (1886-1943) белән очрашу. Дүрт-биш ел әүвәл Искәндәрне дә Германиягә үзе үк озатып куйганмы, әллә соң башка берәрсенә йөкләгән булганмы бу вазифаны – монысы әле ачыкланмаган.

1960-70 елларда Орски шәһәрендә очрашып-сөйләшкән Шакирә апа Мостафинаның атасы Борнаев сәүдәгәрләренең ышанычлысы, ягъни сәүдә йомышларын үтәүчесе булган. Әти-әнисе сөйләгәннәргә таянып, ул апа шагыйрьнең шәһәр халкы белән күп аралашмавын, мәҗлесләргә бармаска тырышканлыгын бәян итә.

Илдә түнтәреш башланган елда гимназия тәмамлаган Хәлимә апа Фәйзуллина (Мәскәү) ире – комиссар Габдулла Дәүләтшинның 1920-1921 елларда Орскида татарча "Ирек йолдызы" гәзитен чыгаруга багышланган истәлегендә Дәрдмәндне дә телгә алган иде. Комиссар Дәүләтшинның ул елларда төп эш урыны, ягъни эш бинасы элекке Шәрык клубы бинасында була. Кайбер көннәрдә анда Мөхәммәтзакир ага да килә, Габдулла белән алар озаклап дөнья хәлләре турында гәп коралар иде, ди Хәлимә апа. Ул гәзиттә әдәби почмак та була, анда парчалар, шигырьләр дә басыла. Шәһәр музеенда сакланган бер санда (7 июнь, 1921 ел) "Ирек йолдызы"нда шагыйрь Т.Ченәкәйнең "Көз" дигән шигыре басылганы мәгълүм. Әмма Хәлимә апа Дәрдмәнднең шигырьләре ул гәзиттә басылу-басылмавын хәтерләми иде.

● "Дәрдмәнд". А.АБЗГИЛЬДИН эше.

Әлеге Шәрык клубын унынчы елларда оештыручы һәм ачлык афәте башланганчы эшләтеп килүчеләрнең берсе Дәрдмәнднең кече баҗасы, "Дәрелмөгаллимин" мәдрәсәсен тотучы Сары Әхмәтҗан дигән кеше була. (Аның мәшһүр артистыбыз Галия апа Нигъмәтуллинага да якын туган булганлыгын әйттеләр). Орскида яшәү чорында Дәрдмәнднең шул кеше белән еш аралашуын, аны үзенә фикердәш итүен әйтүчеләр күп. Әмма берәр истәлек-хатирә белән шуны раслаучыны очратырга туры килмәде. Нишләптер Хәким ага Сәлимҗановның үзе һәм җәмәгате Галия апа белән дә ул хакта очрашып сөйләшү миңа насыйп булмады.

Гражданнар сугышы Орски төбәгендә бик сузыла, ул фәкать 1920 елда гына тына. Шәһәрдә берничә мәртәбә хакимият алмашына: ике-өч ай аклар хакимлек итсә, калган өч-дүрт айда кызыллар баш булып торалар. Шагыйрьнең улы Җәгъфәр дә (1893-1976) шул бәрелешләрдә катнаша, 1919 елның март ахырында гына "кызыл"га чыккан Муса Мортазинның полк һәм бригадасы белән "дошман" көчләрне Ырынбур гөбернәсеннән куып җибәрешә...

(Ахыры 18 нче биттә).

Дәрдмәнднең соңгы айлары

(Ахыры. Башы 17 нче биттә).

1921 ел, ачлык елы. Орски тирәсендә яшәүче барлык мөселманнар өстеннән милли комиссар итеп билгеләнгән Габдулла Дәүләтшин тәкъдиме беләндерме, шәһәрнең абруйлы кешеләреннән ачыгучыларга ярдәм итәргә йөкләмә алган кешеләр берлеге төзелә. Кайберәүләр әйтүенчә, аның башында Мөхәммәтзакир Рәмиев-Дәрдмәнд торган. Һич югы, ул шул "комитет"нең абруйлы әгъзасы булгандыр, мөгаен. Шул елларда большевиклар тарафдары булган, башлыча потребкооперация эшен оештырып җибәрү белән шөгыльләнгән икенче бер Дәүләтшин: ул "бабай"ның безгә булышып йөрүен генә беләм, дип әйткән иде. Әлегә архивларда ул чорга караган документның табылганы юк. Чөнки, әйткәнемчә, шәһәрне еш кына су баса торган була. Архив хезмәткәрләре аеруча 1924 елгы "потоп"тан соң документларның юкка чыгуын раслыйлар.

1921 елның көзендә Дәрдмәнд Ырынбурда булып кайта, шуннан соң өч-дүрт көн узмастан якты дөнья белән саубуллаша. Кайберәүләр әлеге авыр сәяхәтнең шул ачларга ярдәм итү комитеты эше белән бәйле дип исәплиләр. Мин дә шундый фикердәмен. Әмма бу вакыйгага тагын бер фаҗига килеп өстәлә әле: шагыйрьнең олы кызы Өммегөлсем кинәт авырып китә. Ул атналарда шәһәрдә тиф вә ваба кебек авыруларның көчәйгән чагы була. Шунлыктан Өммегөлсемнең терелүсенә өмет калмый. Бу хәбәрне миңа 1993 елның кышында Мәскәүдә булганда Өммегөлсемнең кызы Кафия апа белән Искәндәрнең улы Бәшир ага сөйләделәр. Дәрдмәндне шул уңайдан махсус чакырып китергәннәрме, әллә соң ул бу вакытка очраклы рәвештә генә туры килгәнме – әлегә мәгълүм түгел. Кафия апаның (1915 елгы) сөйләвеннән шунысы ачык: Өммегөлсем белән соңгы саубуллашу көннәрендә шагыйрь Ырынбурда булган. Гариф киявенең дә өметсез авыру икәнлеген аңлагач, болар гаиләсендәге дүрт кыз баланың язмышын хәл итүне дә үз өстенә алган. (Гариф Камалов бер елдан соң вафат була).

Шушы сәфәрдән кайтканда инде Дәрдмәнд үзен начар хис итә башлый һәм кайткач та үлеп китә. Ырынбурга ул ничегрәк киенеп, кайчанрак килгән булгандыр. Ә менә аннан кайту көннәренең салкын булуы, шулай ук вагоннарның әле җылытылмавы мәгълүм. Актүбә белән Орски арасындагы йөз илле чакрымлы ат юлы да көзге сәяхәт өчен бик җайсыз була, әлбәттә. Күпләр сугыш калдырган йогышлы чирләр белән интеккән бер вакытта олы яшьтәге кешегә андый хафалы юлда йөрү бер дә файдага булмагандыр. Шул өметсез чирләрнең берәрсен йоктырмаган, ө гап-гади салкын тию яисә грипп ише авыру гына эләктергән кешенең дә андый авыр сәяхәттән соң тиз генә сихәтләнә алмавы ихтимал иде. Дәрдмәнд тә сихәтләнә алмый.

Мәгәр, кайберәүләр: шагыйрь Дәрдмәнд ачтан үлгән икән, димәкчеләр. Мин күргән, сөйләшкән кешеләрнең берсенең дә мондый фикерне белдергәне булмады әлегә. Рәмиевләр үзләре дә, алар кайтып төпләнгән Орски сәүдәгәрләре Борнаевлар да алай ук ярлы да, киләчәк өчен хәстәрлексез дә яшәмәгәннәр. Анысына шик юк. Ә менә ул елларда яман чиргә әверелгән төрле йогышлы авыруларның киң таралганлыгын барыбыз да беләбездер.

P.S. "Шәһри Казан" гәзитендә (15 декабрь, 1994), мин Рәмиевләр шәҗәрәсен урнаштырган идем, шуңа өстәүләр, төзәтмәләр булмасмы дип көткән идем. Әлегә хәбәр бирүче булмады. Бәлки, бүгенге язмам белән танышкан кешеләрдә Рәмиевләргә, шәхсән Дәрдмәндкә бәйле истәлек-хатирәләр сакланадыр. Кем дә булса, бәлкем, бүген бәян ителгән фактларга карата фикер әйтергә ниятләр. Рәхим итегез! "Мәдәни җомга" гәзите ашамы, турыдан-туры , күзгә-күз карап гәпләшәбезме – мин андый сөйләшүләргә һәрвакыт әзермен.

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.

Тарәзәндә утың бар

Чәчәк вальсы

Татар композиторлары арасында хатын-кызларыбыз әллә ни күп түгел. Шуңа күрә дә алар безгә бик кадерле, бик газиз. Менә Яңа елның беренче мизгелләрендә шундый сирәк кешеләрнең берсе – яраткан композиторыбыз Резидә ӘХИЯРОВА белән әңгәмә корып утырабыз.

– ***Бүген шундый матур төн, Яңа ел төне. Иҗат кешеләренә илһам, гадәттә, төнлә килә. Син төнне яратасыңмы, Резидә?***

– Минем өчен төн һәрвакыт серле булып тоела: Төнлә бар нәрсә дә матуррак күренә. Менә, мәсәлән, урам. Ап-ак карлар яугач, күк йөзенә сибелешеп йолдызлар, ай чыккач, ул тылсымлы, әкияти төс ала. Күз алдына матур-матур күренешләр килә. Хыялланып шул йолдызларга багасың, галәмдәге башка планеталар турында уйлыйсың, анда да бездәге шикелле үк тормыш кайныймы, әллә бераз башкачарак микән дип, хыялга чумасың. Төн ул тормышны бизәп җибәрә. Ул сине шушы әкияти рухы белән әсир итә. Яратам төнне. Җәй көне елга, яисә диңгез суына, анда чагылып йөзгән йолдызларга карап юанам, күз алдында төрле гаҗәеп образлар туа. Гомумән, табигатьне,галәм киңлеген, иксез-чиксез күк йөзен, урман, елгаларны яратам. Ә кышын... Менә бүгенгедәй бәйрәм төнендә, шәһәр мәйданнары чыршылар, төрле төсләр белән җем-җем итеп торган утлар белән бизәлгән төндә әйтерсең лә балачагыңа әйләнеп кайткандай буласың, әкияти дөньяга кереп, шунда биһушланып йөрисең. Күңел нидер көтә. Могҗиза булуына ышана.

– ***Ә музыканы син кайчан язасың?***

– Мин илһамның күктән иңгәнен көтеп тормыйм. Кирәк чакта кулыма каләм алам да, эшкә тотынам. Күңелемдә җыелып килгән хәзинәләрне кәгазь битенә күчерәм. Илһам миңа эшләгән чакта үзе килә.

– ***Без Үгезбозау белән хушлашабыз. Әнә ул үзе дә бер читтәрәк башын иеп тора. Аның белән аерылышу моңсу түгелме?***

– Үткән ел минем өчен уңышлы булды. Бу Үгезбозау бик сөйкемле, киң күңелле булып чыкты. Мөгаен, ул миңа үз куәтен биргәндер. Күп яздым, күп эшләдем. Аңа кадәр бер-ике ел сүлпәнрәк эшләгән булсам (моны илдә барган үзгәрешләр, социализмнан капитализмга күчү белән аңлатып буладыр), Үгез исә мине яңадан тулы канлы иҗат юлына кайтарды, иҗат бәхете бирде. Бу елларда бер мин генә түгел, башка иҗат кешеләре дә сәясәт китереп чыгарган әлеге халәттән котыла, үз асылына кайта башлады. Шушы чорда мин бер нәрсәне аңладым. Без – профессионаллар эшләмәсәк, бушлык туа, ә ул бушлыкны үзешчәннәр тутыра. Шуңа күрә катгый карарга килдем: ни генә булса да, иҗат кешесе,бернигә дә карамыйча эшләргә, иҗат итәргә, үз юлыннан тайпылмаска тиеш.

– ***Син бик күп яңа җырлар, романслар, симфоник әсәрләрең белән тыңлаучыларны сөендереп тордың. II Бөтендөнья татар конгрессында да синең музыкаң яңгыравына бик куандык. Әле күптән түгел Композиторлар берлегенең XXV пленумы бик уңышлы үтте. Аны ачу концертында синең "Тарих сәхифәләре" исемле вокаль-симфоник әсәреңне дә тыңлаучылар дәррәү алкышлады, чәчәкләргә күмде. Балаларны да онытмадың. Күптән түгел Г.Камал театрында Илдар Хәйруллин куйган "Карак песи" спектакленең премьерасы да гөрләп үтте, балаларга Яңа елга күчтәнәч булды. Мартта булачак "Аурупа-Азия" фестиваленә камера әсәре язуыңны да сер итеп кенә әйтеп буладыр.***

– Әйе, бик күп эшләргә туры килде. Әйтәм бит, бер-ике ай пианино артыннан тормадым. Торырга ымсынып карасам да, мине янә уен коралы артына утырттылар. Арып, алҗып беткәнемне әнием белән ирем генә белә. Ә шулай да моңсуланмыйк әле. Үгез 12 елдан янә әйләнеп кайтыр. Без ул вакытта инде олыгаербыз, тормыш тәҗрибәсе тупларбыз.

– ***Резидә, ә син юлбарысны яратасыңмы?***

– Үлеп яратам! (Көлә). Чөнки минем ирем юлбарыс бит. Юлбарыс җәнлекләрнең патшасы. Матур, мәгърур һәм акыл иясе. Үгездән көчлерәк булсын иде ул. Әмма тормышыбыз Юлбарыс кием кебек буй-буй булмасын иде. Мин, гомумән, сары, кызгылт-сары төсләрне, кояшны яратам. Мөмкин булса, мин ул Юлбарысны сары, яки кызгылт-сары төскә манып идем. Халкыбызга, республикабызга күбрәк кояш,яктылык, шатлык һәм бәхет теләр идем. Озын сүзнең кыскасы, мин анардан курыкмыйм, колач җәеп каршы алам. Хуш киләсең, Юлбарыс! Ул безне тешләмәс, хуҗаларына ташланмас, дим.

– ***Резидә, күр әле, Кыш бабай белән Кар кызы безне тәбрикләргә киләләр түгелме? Кыш бабай касәләргә шампан шәрабе коя. Әйдә, бер тост әйт инде.***

– Дөресен генә әйткәндә, мин шәраблəр белән әллә ни мавыкмыйм. Ирем дә эчми. Яңа ел хөрмәтенә генә иренемне чылатып алыйм инде. Гомумән, Яңа ел чыршы, ылыс, әфлисун исе, шыгырдап торган ап-ак кар һәм чемердәп торган шампан шәрабе белән ямьле. Алар яшәешкә бәйрәм төсе бирә.

– ***Син өеңдә чыршы куясыңмы?***

– Чыршыны бик яратам. Минем ясалма чыршым бар. Кызым кечкенә чакта ук алган идем. Коелмый да, чын чыршыларны да әрәм итәсе юк. Исе килсен өчен, урамнан чыршы ботаклары алып керәм. Мин аны уенчыклар белән бизим дә, ул 8 Март бәйрәменә хәтле тора...

– ***Бәйрәм бүләксез булмый инде...***

–Бүләкләрне бик яратам. Бүләк алырга да, бирергә дә яратам.Минем бер кызыл капчыгым бар. Мин аңа үз кулым белән Кыш бабай сурәте дә чигеп куйган идем. Яңа ел алдыннан эреле-ваклы, әллә ни кыйммәт булмаган бүләкләрне тутырам да чыршы төбенә куям. Анда әнигә дә, кызыма да, иремә дә бүләк була. Әлбәттә, үземне дә онытмыйм.

– ***Резидә, мин сине һәрвакыт пианино артында итеп күрәм, күз алдыма китерәм. Бүген дә ул, әнә, чыршы янында тора. Безне бер матур көй белән сөендер инде.***

– Яхшы! Мин сезгә былтыр язган вальсымны уйныйм, чөнки ул бүгенге бәйрәм рухына бик туры килә. Аның шигырен Ренат Харис язган. Җырны халкыбызның сөекле җырчысы Зилә Сөнгатуллина башкара. Без аны "Чәчәк вальсы" дип атадык. Рәхим итеп тыңлагыз!

Күк йөзеннән йомшак кар бөртекләренә охшаган ап-ак чәчәкләр сибелеп, чәчләребезгә, керфекләребезгә кунды. Чыршы тирәсендәге бар халык шушы күркәм аһәңнәргә ияреп, вальс әйләнә башлады.

Әңгәмәне
Фирдәвес ӘҺЛИЯ
үткәрде.

• Композитор Резидә ӘХИЯРОВА.

Дания БАҺАВЕТДИНОВА

Музей хезмәткәре язмалары

Һәр шәхес һәм язучының яшәү мохитендә кулланылышта булган әйберләре аның биографиясенә карата нинди-дер мәгънә бирә ала. Төрле киемсалым, язу әсбаплары һ.б. әйберләрдә күпчелек очракта язучы тормышының башка документлар белән расланмаган нечкәлекләре, иҗатларына кагылышлы вакыйгалар ачыклана төшә. Шуңа күрә, язучылардан материаллар алганда, шәхси әйберләр җыюга без нык игътибар итәбез. Беренче чиратта, аларның эш кораллары саналган кара савытын, бүтән төрле язу әсбапларын җыябыз. Музей фондында мондый әйберләр шактый күп тупланды.

Соңыннан аларны документаль яктан эшкәрткәндә, бер закончалык ачылды. Мәсәлән, кара савытларын алыйк. Алар инде күп, ләкин бер-берсенә һич тә охшамаганнар. Язучыларның иҗатлары кебек үк, алар да бер-берсеннән күзгә күренеп аерылып торалар. Җыелган сәгатьләр, шушы мәгънәдә, тагы да кызыклырактыр кебек. Алар арасында – Ш.Мәрҗанинның эш бүлмәсендә торган стена сәгате дә бар. Аның уклары галим Болгар һәм Казан тарихы турындагы хезмәтләрен язганда узган вакытларны санап торганнар бит. Яисә – Җаек шәһәрендә К.Мотыйгый нәширлегендә чыгарылган “Фикер” гәзите редакциясендә эленеп торган стена сәгате. Г.Тукай да үзенең эш сәгатьләрен шуңа карап билгеләгән.

Язучы Г.Коләхмәтовның укытучылык хезмәтенә ун ел тулу уңаеннан иптәшләре бүләк иткән өстәл сәгате. Анда Ф.Әмирхан, Х.Ямашевның хатыны Хәдичә һ.б. исемнәр чокып язылган.

Драматург К.Тинчуринга 25 еллык иҗат юбилее уңае белән татар театры артистлары бүләк иткән, агач аякларга куелып эшләнгән сәгать янында тагын күп төрле кул сәгатьләре шулай ук күп нәрсәләр хакында сөйләп тора.

Шагыйрь Сибгат Хәким тапшырган сәгать – үзе бер тарих. Аны безгә Сибгат абый үзе язган истәлек белән бергә тапшырды. Истәлеккә Язучылар берлеге ясаткан махсус конвертка салып: “Музейга – Даниягә” – С.Х.” – дип язып, әдәби бүлекне җыештыручы ханымга калдырган. Истәлек үзе менә шуннан гыйбарәт.

“1940 елның 31 декабре. Яңа елны каршылый торган көн. Минем туй шул кичне булды. Тукай урамы, мехчылар клубына каршы ишегалдындагы йортның берсендә булды ул туй. Хәтерлим, буранлы көн иде. Килүче кунакларны капка төбенә чыгып, үзем каршыладым. Башта гадәттәгечә елмаеп, буран эченнән шат йөзле Гадел Кутуй килеп чыкты. Аннан Әминә белән Муса Җәлил, Хәсән Туфан күренде. Бу туйда Җ.Фәйзи, Г.Кашшаф һәм Ш.Мануур да бар иде. Бөек Ватан сугышы алды туе. Бу язучыларның күбесе белән соңгы тапкыр очрашканмын. Әйтерсең, сугышка шул туйдан таралдык.

Бу сәгатьне миңа туйда Кутуй бүләк иткән иде. Ул сәгатьне мин сугышка үзем белән алдым. Төрле шәһәрләрдә, төрле фронтларда булдым. Кутуй истәлеге күп нәрсәне искә төшерде: Казанны, Тукай клубындагы кичәләрне, аның белән бергә уздырылган очрашуларны, яшьлекне, туйны сагындырып искә төшерде. Бу сәгать шул көннәрне фронт кырларында гел хәтерләтеп тора иде. Ләкин ул бервакыт туктап калды. Аның кинәт туктавы мине шөбһәгә дә салды, фронт бит. Шул чакта миңа ничектер ике көнгә генә Казанга кереп чыгарга туры килде. Сәгатьне Казанда калдырдым, аерылдым, яшьлектән аерылу шикелле тоелды. Кем белә, әллә кайтам, әллә юк. Мин бороылып кайттым, сәгать хуҗасы Гадел Кутуйга Казанны яңадан күрергә насыйп булмады.

Сибгат Хәким.
16 январь, 1980 ел”.

Сибгат абыйның бу сәгатькә багышлап язылган шигыре бар. “Туй истәлеге” дип аталган шигырен ул 1940 елда яза. Без аны экскурсияләр үткәргәндә, тулысы белән укыйбыз.

Дусларым биргән сәгать тә
Искереп, тузып бара.
Уйланам аңа карыйм да:
Гомерем узып бара.

Истәлек биргән булып сез
Артыгын зурлагансыз.
Мин җуләр яңа төшендем,
Яшьлегем урлагансыз...

Уенчык күргән сабый күк,
Мин дә бер катлы тиле.
Беренче сөю язымны
Бирегез, дуслар, кире!

Ямь-яшел үзәннәремне
Сагынып өзелә күңел.
Елмаеп кызлар үтәрләр -
Тик инде безгә түгел.

Тик шигырь татар телендә булганлыктан, урыс тамашачыларын аның белән таныштыра алмый идек. Бер көнне Сибгат абый, әдәбият бүлегенә кергәч, аңа шул хакта әйттек. Озак вакыт үтмәде, ул безгә шигырьнең урысчасын китереп китте. Югарыда телгә алынган конверт эчендә иде әсәр. Аны, “Свадебный подарок” дип атап, шагыйрьнең улы Рөстәм тәрҗемә иткән.

Күрүебезчә, Сибгат абый сәгатькә бәйле истәлеген бик җентекле язган. Ләкин, безнеңчә, бер нәрсәгә игътибар итмәгән. Сәгать уклары вакытның иң югары ноктасында – уникедә тукталган. Әйтерсең, алар сугыш елларында татар язучылары кылган батырлыкларның иң югары биеклеккә җитүен күрсәтеп торалар. Гүяки, шуннан да биегрәк күтәрелү мөмкин дә түгел...

Әдәбият бүлеге тормышында язучыларның актив катнашуын әйттек инде. Төрле мәсьәләләрне хәл иткәндә генә түгел, ә болай гына, узып барышлый, безнең хәлне белергә дә керәләр иде. Шулай гына килеп чыксалар да, аларның безгә мораль яктан файдалары тия, бүлекнең дәрәҗәсе күтәрелеп китә иде.

Безнең янга иң еш килгән язучы ул, мөгаен, Сибгат ага Хәким булгандыр. Безнең гыйльми советның вәкиле буларак та, аның күрсәткән хезмәтләре зур иде. Музей белгечләренә генә таныш формада язылган тематик планнарны күпме укырга һәм фикер әйтергә туры килде аңа. Кырлайдагы Тукай музееның планнарын тикшерүгә багышланган гыйльми совет җыелышларында ясаган чыгышлары гына ни тора!

Тукайга багышланган беренче музей булганлыктан, бөтен кеше зур кызыксыну белән җаваплылык тоеп эш итә. Чыгышларда буш сүзләр юк. Планга кергән һәр сурәт яки документ өстәмә дәлилләү таләп итә. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре, “Тукай һәм аны пропагандалаучы хатын-кызлар” дигән рубрикада бирелгән “М.Фәүзиева – Тукай турында беренче кандидатлык диссертациясе яклаган галим” дигән формулировка белән ризасызлык белдереп: “1940 еллардагы диссертацияләрнең сыйфат дәрәҗәләре инде ташка үлчәрлек кенә калды”, – дигән фикер әйттеләр.

Җавапсыз калмыйбыз. “Теләсә ничек булсын, беренче булып бу эшкә хатын-кыз алынган бит”, – дибез. Юк, галимнәр бирешми. Шуңа күрә сүзне Сибгат абый ала. Гадәттәгечә, тыныч тавыш белән:

– Музей хезмәткәрләре бик зур, әһәмиятле проблемалар күтәрәләр бит, – дип сөйләп китә. – Хатын-кызлар Тукай тормышында зур урын тоталар. Шигырьләрен генә алыйк – әнисенә багышланганнарын, лирик шигырьләрен, хәтта сатирик әсәрләрен. Алар башка шигырьләреннән аерылып торалар. Шунысы кызыклы, Тукайны урысчага һәм башка телләргә дә хатын-кыз шагыйрьләр әйбәтрәк тәрҗемә итә.

Бу чыгыштан соң барыбыз – галимнәр дә, без дә, ниһаять, тынычланабыз.

1980 елның 17 февралендә Сибгат абыйны, Муса Җәлилнең туган көнен билгеләп үткән көнне, “Моабит дәфтәрләре”нең төп нөсхәләрен сейфтан алып чыгу тантанасында катнашырга чакырдык. Карышмады, килде. Галия Кайбицкая белән “Моабит дәфтәрләре” куелган витрина янында почетлы каравылда торды. Укучылар белән очрашып, Муса Җәлил эзләре буйлап Германиягә барулары хакында сөйләде, үзенең шул турыда язган шигырьләрен укыды. Күп итеп фотосурәткә төшердек үзен.

Экспозицияләр залында кешеләр азайгач, Сибгат абыйны шунда калдырып, эш бүлмәсенә кердек. Ниятебез үзебезчә аны чәй эчертеп җибәрү иде. Кызлар өстәлне әзерләп куйганын күргәч, Сибгат абыйны бүлмәгә чакырырга дип яңадан чыктым. Ләкин ул мин киткәндә калган урынында юк иде. Бүлек буенча эзләп киттем.

Мин аның Бөек Ватан сугышы чорына караган залда – Фатих Кәримнең шинеле, солдат итекләре, фронт блокнотлары һәм башка күп әйберләре, документлары куелган шкаф-витрина каршында басып торганын күрдем. Ул минем залга кергәнне сизмәде бугай. Бөтен торышы, йөзе үткәннәргә, Ф.Кәрим язмышы белән бәйле көннәргә киткән иде.

Тиз генә фотографка йөгердем. Бәхеткә, фотограф үз урында иде. “Олег Константинович, тизрәк, тарихи кадрны югалтабыз!” – дидем. Без килгәндә, Сибгат абый шул мин күргән кыяфәттә басып тора иде әле. Фотога төшердек.

Сибгат абыйны әдәбият бүлегендә тагын бер тапкыр бөтенләй икенче кыяфәттә дә күрергә туры килде.

Җәйге кызу көннәрнең берсе. Бүлекнең (беренче каттагы) эш бүлмәсе кояш чыккан якка караганлыктан, иртән без эшкә килгәнче үк, эсселәнеп өлгерә. Килгәч тә беренче эшебез итеп, җигелгән ат белән керерлек тәрәзәләрне ачып, бүлмәне җилләтәбез.

Биек тәрәзәнең өске өлешен икегә бүлеп, аркылы такта кагып куелган. Анда – тәрәзә янында – төрле савытларга утыртылган гөлләр үсә, күбрәге – үрмәле гөлләр. Икенче эшебез – аларга су сибү. Бер көнне шул эшләр белән матавыкланганнан соң, бушаган савытларга су тутырып куярга дип, бик аз вакытка гына бүлмәдән чыккан идек, керсәк, бүлмә уртасында Сибгат абый басып тора. Ачык тәрәзәдән кергән диярсең. Өстендә – кыска җиңле күлмәк. Кояшта каралып янган битләре тулыланып, үзе яшәреп киткән.

– Сибгат абый, әллә тәрәзәдән генә кердегезме? – дидек барыбыз да бер тавыштан.

Музей ишекләренең килүчеләр өчен сәгать унда гына ачылганын истә тотып түгел, ә аның бөтен кыяфәте тәрәзәләрдән генә сикереп төшә ала торган яшьләрне хәтерләткәнгә күрә шулай сораганбыздыр.

– Юк, ишектән, – диде ул, көлеп.

Ишек төбендә торучы каравылчы Сибгат абыйны танып керткән икән. Димәк ки, Сибгат Хәким музейдә инде чит түгел, үз кешегә әверелгән....

– Сибгат абый, әллә көньяктан кайттыгызмы шулай каралып? – дип, сокланудан туктамадык.

– Юк, туган авылымда булдым. Өлгереп килгән арыш басуларында йөрдем, чишмә сулары эчтем. Берничә генә көн әле килүемә, – дип җавап җавапладаы шагыйрь, чак кына уңайсызлангандай итеп.

– Менә бит туган якның сихри тәэсире ничек үзгәртә кешене! – дип, әле беребез, әле икенчебез кабатлый торды.

Сибгат абый үзе дә, сүзгә каршы килмичә, бүлмә уртасында елмаеп басып торды. Ул безнең күңелләрдә хәзер дә шул кыяфәтендә саклана...

Җырдашлар-моңдашлар (С.Садыйкова һәм С.Хәким).
Наил КУРАМШИН фотосы.

Бомба белән Мәскәүгә...

Кузнецки шәһәрендә милициянең патруль машинасын бер кеше туктата. Дипломатын күрсәтә, аннан ике тимерчыбык күренеп тора. Бу кеше милициядән Мәскәүгә барырга транспорт таләп итә. Милиция хезмәткәрләрен машинадан чыгарып, үзе кереп утыра. Максаты – Мәскәүгә барып, "гамәлдәге режим"ны бәреп төшерү. Югары милиция хезмәткәрләре дә килеп, террористны сөгать буе "тәрбиялиләр" һәм аның бик үк сәламәт түгеллеген белеп алалар. Дипломатын читкәрәк куеп, автоматтан аталар. Көтелгән шартлау булмый, ә "террорист" акылга таманнар хастаханәсе пациенты булып чыга. Ул дипломатына бер шешә квас куеп, шешә муенына тимерчыбык бәйләп "шантаж" ясамакчы булган икән.

("КП").

Чиркәүнең үз медале бар

Ярославль өлкәсе эчке эшләр идарәсе начальнигы Александр Воробьев 3 дәрәҗә Изге Даниил медале белән бүләкләнде. Бу медаль милиция полковнигына чиркәүгә урланган иконаларны кире кайтару эшенә зур өлеш керткәне өчен бирелде. Ул иконалар өчен җинаятьчеләргә зур табыш вәгъдә ителгән булган. Чиркәүгә кире кайтарылган реликвияләр арасында XYI-XYII гасырларда ук язылган иконалар да булып, алары Ярославльдәге Никола чиркәвеннән урлап чыккан булганнар.

("СР").

Күңелсез саннар

■ 2010 елга кадәр Русия халкының 6 миллионга кимүе көтелә. Балалар, яшүсмерләр белән чагыштырганда, өлкән яшьтәгеләрнең саны 5 миллионга артыграк булачак.

■ Русиядә күпчелек кешеләр яман шештән, кан әйләнеше һәм эндокрин системалары авыруларыннан үлә.

■ 1997 елда бер яшькәчә балаларның меңнән унҗидесе үлде.

■ 1997 елда 100 мең кешенең 272се агуланудан (аракы), тәрле имгәнүләр һәм юл фаҗигаләре нәтиҗәсендә үлгән.

■ 1997 елда аракы белән агуланудан 23 мең, 1996 елда 17 мең кеше үлде, аларның күпчелеге – ирләр.

■ 1997 елда 23 мең кеше үтерелгән, 40 мең кеше мордар киткән.

■ Бүгенге 16 яшьтәгеләрнең яртысы гына 60 яшькә кадәр яши алачак.

■ 1996 елда Русиядә үлүчеләр саны туучылардан 2 мәртәбә артыграк.

■ 1996 елда Русиядә 2,7 миллион аборт ясалган. Бу сан туган балалар санынннан 2 тапкыр артык. Абортларның 2 мене 15 яшькәчә булган кыз балаларга ясалган. Аларның яртысы кабат балага узудан мәхрүм.

■ 1991-1996 елларда һәр ел саен теркәлә торган өйләнешүчеләр саны 453 меңгә кимегән. Өйләнешүчеләрдән 1000 парга 649 аерылышучы туры килә. Аларның өчтән бере – 5 ел да бергә яши алмаучылар.

Юрий Лужковның яраткан шөгыле

Үзен оста дәүләт эшлеклесе итеп таныткан, Мәскәүдәге яңа төзелешләр, биналар нигезенә язулы капсулалар куйдыру белән мавыккан Мәскәү мэры Юрий Лужков эштән бушаган һәм ял көннәрендә умартачылык белән мәшгуль. Менә 10 ел инде ул үз дачасында 12 умарта тота, ел саен үз гаиләсен юкә һәм чәчәк балы белән тәэмин итә. Җәй саен ул үз умарталарыннан 100 кг бал ала.

("ОГ").

Әни кешегә... 11 яшь

Гиннесс рекордлар китабына тагын бер язма өстәлде: Англиядә 11 яшьлек бер кыз бала әни булды. Кызыйның гайре табигый хәле дәрес вакытында һуштан язып егылгач кына беленә. Аңа кадәр өйдәгеләр дә, сыйныфташлары да берни дә сизенмиләр. Табиблар кызның йөккә узган булуын әйтәләр. Вакыты җиткәч, бәби дөньяга килә. Операция катлаулы була, ләкин бәби дә,яшь әни дә исән калалар. Бәбинең әтисе кем икәнлеге әлегәчә сер булып кала.

("КП").

Владислав Третьяк кышны ярата

Чөнки ул карда шуучы машинада йөрү белән мавыга. Мәшһүр хоккейчы бу шөгыльендә шактый уңышларга ирешкән. Аны Санкт-Петербург, Уренгой шәһәрләренә кар машинасы ярышларына катнашырга чакыралар. Ләкин Владислав Третьяк "мин кар машинасында үз рәхәтем өчен генә йөрим", – дип баш тарта. Аны кар ярып баручы машинаның шашкын тизлеге кызыктыра.

("МЭ").

Үлеп терелгән кыз

Бу хәл Брест тирәсендәге бер авылда була. Авыл укытучылары Марченколар гаиләсендә җитеп килүче 17 яшьлек Анюта йокы авыруы ("сонная болезнь") белән авырый һәм табиблар күзәтүе астында яши. Ул ике көн рәттән, ә бер тапкыр атна буе уянмыйча йоклый. Соңгы йоклап китүеннән соң кыз уянмый, табиб аның үлүен әйтә. Кызны күмәләр. Күмәр алдыннан әнисе кызына алтын балдагын кидерә. Күмү вакытында зиратта шәһәрдән кайткан ике "шалопай" да була. Болар төнлә килеп кыз кулындагы алтын балдакны алмакчы булалар, каберне ачалар, кыз бармагындагы балдакны салдырмакчы булалар, балдак чыкмый гына. Берсе, пәке алып, бармакны кисә башлый. Кыз шунда уянып китә, "аh" дип кычкырып җибәрә. Каракшлар куркып кача. Кыз каберлектән чыгып, төнлә үз йортларының тәрәзәсен кага. Әнисе, уянып, тәрәзәдән карасаа – күмелгән кызы басып тора. Ана һуштан яза. Соңыннан барысы да җайлана тагы.

("ДиО").

Картта егетләр йөрәге

Кара төндә ике карак талау нияте белән 86 яшьлек пенсионерның тәрәзәсен ватып өенә керәләр. Элекке хәрби куркып калмый, ау мылтыгын алып, бандитларга атып җибәрә. Каракларның берсе шундук үлә, икенчесе яралана. Карт оста мәргән булып чыга. Тулада чыга торган "Тула хәбәрләре" гәзите язуынча, батыр пенсионерны үзен яклау чикләрен бозганы өчен милиция кулга ала. Нинди чик икән соң ул, бәлки, картның җинаятьчеләр корбаны булуыдыр, дип яза гәзит.

● Лужков кепкасы Казан бүреген сайлый.

("Культура").

Торт эчендә... граната

"Лукойл" фирмасының Чиләбе бүлеге директоры урынбасары фатирының ишек төбенә билгесез кешеләр тортлы тартма куеп китәләр. Тортның эченә граната яшерелгән була. "Бүләк"не күреп алып, милиция хезмәткәрләре аны зарарсызландыралар. Торт эчендәге язуда "Лукойл" фирмасының бер җитәкчесенә янау сүзләре була. Милиция җинаятьчене эзли.

("Труд").

Татар энциклопедиясе битләреннән

АЛПАРОВ Гыйбад Хәбибулла улы (1888-1936), тел белгече. 1910-21 елларда Башкортстанда педагогик эштә. 1921-24 елларда Урта Азиядә казакъ, төркмән, үзбәк имлясын төзүдә катнаша. 1926 елдан ТАССРның Мәгариф Халык Комиссариаты һәм Казан педагогия институтында. Хезмәтләре: татар һәм төркмән теле дәреслекләре. Татар телен фәнни яктан тикшерүче беренче галим. 1932 елдан профессор.

АЛПАРОВ Үзбәк Гыйбад улы (1914 елда туган), төзүче инженер. 1964-1985 елларда "Татгражданпроект" институты директоры. 1960 елда Үзәк стадион, 1961 елда Үзәк универмаг, 1978 елда Яшьләр үзәге проектларын төзүдә җитәкчелек итә. 1968 елдан ТАССРның атказанган төзүчесе, 1972 елда цирк проекты өчен Дәүләт бүләге, 1975 елда РСФСРның атказанган төзүчесе дигән исем бирелә.

АППАКОВА Дәрҗия Сәйфулла кызы (1898-1948), язучы. 1938 елда "Кечкенә Бануның тарихы" повесте, 1943 елда "Тапкыр егет" пьесасы, 1946 елда "Бишек җыры", 1953 елда "Хикәяләр һәм пьесалар", 1957 елда "Сайланма әсәрләр"е басылып чыга.

АПРЕСОВ Владимир Григорьевич (1915-1982), пианист, педагог. 1945-66 елларда Казан консерваториясендә укыта, 1947-64 елларда укыту һәм фәнни эшләр буенча проректор, 1946-48, 1952-53, 1955-62 елларда фортепьяно кафедрасы мөдире. 1957 елдан ТАССРның, 1972 елдан РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе. 1980 елдан профессор, 1980-82 елларда консерваториядә укыта.

АРАШЕВА Нәфыйга Мөхәммәтгали кызы (1902-1943), актриса. 1916 елда "Сәйяр" труппасында, 1920 елда Татар академия театрында эшли. К.Тинчуринның "Зәңгәр шәл", "Җилкәнсезләр" музыкаль драмаларында Хәдичә, Рокыя, М.Горькийның "Мещане" әсәрендә Бессеменова рольләрен башкара.

АРАТ Рәшит РӘХМӘТИ (Рәхмәтуллин Габдрәшит Гыйсмәтулла улы) (1900-1964), төрки телләр белгече, 1920 елдан Харбинда, 1922 елдан Берлин шәһәрендә, 1933 елдан Төркиядә, профессор, Истанбул университетында эшли, 1951 елдан Истанбул университеты каршындагы төрки институт директоры, Истанбулда 1970 нче елларда языла башлаган "Ислам энциклопедиясе" мөхәррире. Төрки халыклар тарихы, теле, әдәбияты белгече, XI гасыр төрки әдәбияты истәлеге "Кутаргу Билик" әсәренә фәнни күзәтү ясаучы.

АРСЛАНОВ Айрат Гәрәй улы (1928 елда туган), нәфис сүз остасы, актер, 1948 елдан Татарстан радиосы дикторы. 1956-61 елларда Татар академия театры артисты. 1961-65 елларда Казан телестудиясендә диктор, 1965 елдан филармония артисты. 1957, 1974 елларда Бөтенрусия нәфис сүз осталары конкурсында лауреат исеменә лаек була. 1969 елда ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә. 1979 елдан ТАССРның халык артисты. 1985 елдан Татар дәүләт филармониясенең режиссеры. 1987 елдан РСФСРның халык артисты. Ф.Борнашның "Таһир-Зөһрә", Т.Гыйззәтнең "Ташкыннар", Н.Исәнбәтнең "Муса" драмаларында Таһир, Мирвәли, Алиш рольләрен башкара. Нәфис сүз остасы буларак Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Х.Туфан, С.Хәким һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрен пропагандалый.

Атналык мәнзара

Дүшәмбе

12 ГЫЙНВАР

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан".
17.35 Балалар өчен "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Үзе бер җыр". А.Гарифуллина.
19.45, 21.45 Яңалыклар.
20.00 Романслар кичәсе.
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "Ирек мәйданы".
21.30 "Һәркем өчен хоккей".
22.25 "Карт-бланш".
22.55 "Париж-Гранада-Дакар-98".

"ЭФИР"

6.00, 10.25, 11.30, 2.50 Музыкага чикләр юк.
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.50 Информацион-күңел ачу программасы: "Уян һәм җырла!".
8.45 "ГНЕВ".
10.40 "ВАВИЛОН-5".
11.45 "Даруханә".
12.00, 15.00 "ТСН-6".
12.10 "ВЕЧНОСТЬ".
14.30 Тамаша залы.
15.10 "БЕЛЫЙ ВЗРЫВ".
16.30 Мультфильм: "Беляночка и Розочка".
17.00, 19.30, 22.00, 3.20 "Шәһәр" информацион программасы.
17.15 И.Демидов шоуы: "Күзәтү".
18.20 "ВАВИЛОН-5".
19.10 Мультфильм: "Ванюша и космический пират".
20.00 "ОХОТНИКИ ЗА ПРИВИДЕНИЯМИ-2".
22.30 Юл патруле.
22.50 "БЕЗ ЕДИНОЙ УЛИКИ".
0.50 Спорт атнасы.
1.20 "ОСП" студиясе.
2.00 Бенни Хилл шоуы.
2.20 "Атна һәлакәтләре".
3.00 Мультфильмнар.
3.40 Нәфис фильм.
5.25 "Республика".

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар.
9.15 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
10.00 "Могҗизалар кыры".
11.00 "Сәламәтлек".
11.30 "Бу көйне беләсеңме?"
12.15 "Бергә".
13.05 "ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС".
14.50 Киноафиша.
15.20 Мультсериал: "Насекомусы".
15.45 "Марафон-15".
16.05 "Йолдызлар сәгате".
16.40 "ПОХИЩЕННЫЙ".
17.10 "...16га кадәргеләр һәм өлкәнрәкләр".
17.30 "Дөнья тирәли".
18.20 Сериал: "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
19.05 "Җавап тотар чак".
19.30 Телеуен: "Бу көйне беләсеңме?"
20.00 "Без".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр".
21.00 "Вакыт".
21.40 "ПОЛТЕРГЕЙСТ".
22.45 Страдивари. "Криминальное соло".
23.30 "АМАРКОРД".

"РУСИЯ"

7.00 Мультфильм: "Приключения Пинокко".
7.15 "Уян!".
7.30, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.30 Хәбәрләр.
8.00, 0.25 Кизү бүлеге.
8.15 Почта аша әйберләр.
8.30 Акчалар.
8.45 Графоман.
8.55 Православие календаре.
9.00 "Аншлаг" һәм Ко.
10.05 "САНТА-БАРБАРА".
11.30 "ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО".
12.30 РТР телеканалында "Йолдызлар".
13.25 Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты. Австралиядән тапшыру.
14.30 "РУКИ УБИЙЦЫ".
16.25 "БЕЛЛИ КИППЕР". "ВИДЕОДНЕВНИК".
16.20 Мультфильм: "Что случилось с крокодилом".
17.35 Кроссворд.
18.05 "ПЛЕМБУМ, ИЛИ ОПАСНАЯ ИГРА".
20.30 "Нечкәлекләр".
20.45 "САНТА-БАРБАРА".
21.50 "Довгань шоу". "Волшебный лабиринт".
22.20 "ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО".
23.55 Милли мөнфәгать.
0.40 Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты.
1.00 Автошоу.

"КУЛЬТУРА"

8.00, 0.20 Музыкаль экспромт.
8.15, 14.00, 20.30, 0.00 Мәдәният яңалыклары.
8.35 "Повести Белкина"ны укыганда.
9.30 Кечкенә сатирик җыентык. С.Альтов.
10.00, 12.00, 16.00, 18.00 Яңалыклар.
10.05 "Яшәү рәвеше".
10.30 Телесуфлер.
10.45 "Язмыш һәм рольләр". Ф.Раневская һәм А.Анджапаридзе турында Н.Крымова программасы.
12.05 Аталы кешеләрнең портретлары.
12.45 "ХАНУМА".
14.20 "ХАНУМА". (Дәвамы).
15.30 Авиация дөньясы. "Сынаучы".
16.05 "ЧЕЛЛЕНДЖЕРС".
16.30 "Вакыт буенча сәяхәт". "Урыс патшалары". А.Панченко программасы.
17.15 Видеошигърият. А.Ахматова.
17.25 Балалар өчен күңел ачу программасы: "Лукоморье".
17.45 "Кибермәдәният".
18.05 "2003 ел". Санкт-Петербургның 300 еллыгына.
